Рәниф Шәрипов

# Азатлык кљне

Поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

**Азатлык кљне**
Поэма

Балкыш
30 нчы август, ягъни сүз урлау
Русия
Бастырылу
Ќђлил џђйкђле
Карачкылар
Рђислђр
Тљнге юл

**Балкыш**
Арканлы ат казыгына уралыр.
*Татар халык мәкале*

Нигә язам моны? Нигә язам?
Җавабым юк. Белмим үзем дә.
Нидер миңа һаман тынгы бирми.
Файдасыз күк әйтер сүзем дә.
Нигә язам моны? Йөрәк куша...
Бу кузгалу юкка идеме?
Балкып узды нидер. Аңламадык.
Онытыла инде исеме.
Юл күрсәтеп узды якты балкыш,
Өмет бирде коллык иленә.
Аңламадык. Ә бит мондый өмет
Тик бер генә тапкыр бирелә.
Онытылыр диеп уйладылар...
Онытыла. Дөрес уйлыйлар.
Чөнки коллар, хуҗаларга ярап,
Берсен берсе ашап туймыйлар.
Күтәрелеп бер карадык күккә,
Үзебез дә бераз шүрләдек.
Тукыдылар «уты хәтәр!» диеп,
Хак асылын гына күрмәдек.
Аңлашыла, кулга корал тотып,
Кан коюдан Алла сакласын!
Ләкин «хуҗа», «болар тынды» диеп,
Йортыбызны тагын ватмасын.
«Бетте болар» диеп, тыныч кына
Таламасын җирне, милләтне.
Барысын да күреп торабыз без,
Мондый «хуҗа» безгә кирәкми.
Бетмәдек без, бераз тындык кына,
Күзәтәбез «яшәү» рәвешен.
Әнә кемдер губерналар бүлә,
Тыя белми тиле нәфесен.
Инде тагын нәрсә көтәргә соң?
Тыныч кына карап торыйкмы?
Башны түбән иеп, «хуҗа»лардан
Әллә рәхим-шәфкать сорыйкмы?
Мин дә аңлыйм, Аллам саклый күрсен
Кан коештан, ызгыш-талаштан.
Ләкин нишлик? Өзеп ашыйлар бит

Дәүләт, милләт дигән агачтан.
Онытылыр диеп уйладылар
Мәскәүдәге олы түрәләр.
Булганы да ярап торыр иде,
Анысын да артык күрәләр.
Онытылыр диеп уйладылар...
Онытыла янар таулар да.
Аста ут янганын белә торып,
Ярыймы соң шулай шауларга?
Онытылыр диеп уйладылар,
Ялладылар татар каләмен.
Телгәлиләр, ертып өзгәлиләр
Дәүләтемнең канлы әләмен.
Тынгы тапмыйм. Юкка язам кебек.
Файдасы юк. Кулда сынык ук.
Мал чәчелгән җирдә бәрәкәт юк,
Тел яшергән илдә өмет юк.
Яшәп булыр иде күпләр кебек,
Тук мәчедәй йоклап, сыйпалып.
Тик итәген җыеп йөрми икән,
Кем көненә калыр бу халык?
Гасыры шул, континентлар саен,
Бетә коллык, үтә ул вакыт.
Табып кара, кемнәр яши икән,
Койрык болгап, чылбыр чыңлатып.
Ни булса да, язып калыйм әле.
Бу кабыну юкка идеме?
Балкып торды мәйдан. Онытмагыз.
Мәңгелеккә калсын исеме.
Балкыш булып, бер күренде безгә
Дәүләт нуры әллә кайдагы.
Юлда булыйк. Юл үтелә, барсаң.
Көтә безне Ирек мәйданы...

**30 нчы август, ягъни Сүз урлау**

Борынгыдан дәүләт тоткан горур халык...
*Туфан Миңнуллин*

Ахры, ашыгып өзгәнбез,
Өлгермәгән әле җимеш.
Утызынчы август җитсә,
«Җөмһүрият көне», имеш.
Каян килгән безгә бу чир?
Әллә пешкәнгәме авыз?
Бүре өркеткән көтүдәй,
Почмак саен елышабыз.
Бәйсезлек сүзен әйтергә
Әллә тыйдылармы инде?
Утызынчы август көнне
Бәйсез, азат Дәүләт җиңде!
Кыямәт көне буладыр,
Килер җавап тотар көннәр.
Хыянәт көне бар хәзер...
Җавап тотар икән кемнәр?
Сүзе булса да калсын тик,
Үзе юк инде, күрәбез.
Аш суынган инде күптән,
Ә без һаман да өрәбез.
Кызыл түгел, яшел түгел,
Татар киләчәге – соры.
Хыянәт көненнән башлап,
Кузгалыр кыямәт чоры.
Килер ул, озак көттермәс
Татарның кыямәт көне.
Ә бүген әле бары тик
Оятсыз хыянәт көне.
Ояты бар – күрә дөнья,
Кыен ашап күпкә түзгән
Батыр бу халыкның коты
Төшкән ботына бер сүздән.
Илаһи, татлы Азатлык... –
Гасырлар буена түзеп,
Миллионлы зур халыкның
Өзеп әйткән соңгы сүзе!
Уйнамагыз Тарих белән!
Бутамагыз сүз мәгънәсен!

Бу оят, бу хыянәтне
Үтәр дисезме әллә сез?
Сүзе калсын, һич югында,
Үзе ятсын кысып тешен.
Яңа буын үсеп килә,
Өмет булсын алар өчен.
Бары тик Азатлык көне!
Җөмһүрият көне башка.
Хәтерләрдә шулай калсын,
Чокып куйган кебек ташка.

Әллә ашыгып өзгәнбез,
Бик ачы булды бу җимеш.
Утызынчы август көне
«Җөмһүрият көне», имеш.
Аннан соң шәһәр көнеме?
Урам көне булыр аннан...
Бәдрәф көне булып җиткәч,
Юдырырлар тартып баудан...

**Русия**

«...Русия – безнең ватаныбыз. Ә ватанны яратмас өчен йә бик тә дивана, йә явыз булырга кирәктер...»
*Мостай Кәрим*

Аксакалны рәнҗетәсем килми,
Тик күңелдә бер шик уяна –
Яраталмыйм Мәскәү тарафларын,
Йә усал мин, йә бер дивана.
Аксакалны аңлыйм, бу Ил өчен
Җанын биргән, канын түккән ул,
Бу Ил тарихына береккән ул,
Бу Ил белән гомер иткән ул.
Хакы да бар, үзен түрдә йөрткән
Үз Иленә тугры калырга.
Тик кирәкме, «явыз, дивана» дип,
Агу сибү тере тамырга?
Кемнең дә бит бар үз Хакыйкате.
Килешмәскә минем хакым бар.
Үтерелеп, инде бишенче йөз
Егылып яткан газиз халкым бар.
Ярар инде, яратмадым, ди, мин,
Түзеп яшәр идек янәшә,
Ауропалар кебек тәүбә кылып,
Кимсетмичә генә яшәсә.
Ил белән ил, тел белән тел бутап,
Болганчык су булып ташыдык.
Кемдер балык тотты. Кемдер бүлде.
Кемдер су болгатты, ашыгып.
Болгаттылар күбрәк «безнеке»ләр,
Бутап телнең сүзен, хәрефен.
Мәскәүләрдән торып өйрәттеләр
Мәскәүләрчә язу дәресен.
Түрә булып түрдә йөргәннәргә
Илең ни дә синең, телең ни.
Торган җирдә «Туган җирем!» дисәң,
Тешләтерләр шулай телеңне.
Ә юлбашчы» яңа, каты куллы,
Яңа «бердәм» дәүләт төзелә.
Тик, кыршауны ныграк кыскан саен,
Чолганышта кала үзе дә.
Яңа, азат илләр нәфрәтеннән

Коткаралмас хәзер мең тәүбә.
Ахыр чиктә шайтан хәтәр түгел,
Ерак кына булсын Мәскәүдән.
Оятыннан башын түбән иеп,
Тәүбә кылып, гафу үтенеп
Чыгып китсә иде... Ләкин һаман,
Һаман йодрык болгый сүгенеп.
Әллә явыз, әллә дивана мин,
Аксакалдан гафу үтенәм.
Ахыргача дөресен языйм дисәм,
Мин ышанмыйм аның сүзенә.
Беркемгә дә инде ачылмас ул
Ахыргача ачы Хакыйкать.
Яраталмый Әдип золым илен,
Ялгышадыр, бәлки, Табигать.
Хакым бармы-юкмы бу сүзләргә?
Кем әле мин? Җавап икеле...
Минем сүздән башка бу Хакыйкать
Тулы булмас иде шикелле.
Бу Ил белән мин дә гомер иттем,
Минем дә бит бу Ил сагында
Саулыгым да, яшьлегем дә калды,
Бозлы, җилле диңгез ягында.
Әйе, дөрес, чагыштырып булмый
Сугыш белән тыныч хезмәтне.
Боз булганчы вахта тотканыңны
Сөйләп тору монда кирәкми.
Бу Ил белән мин дә гомер иттем,
Күрдем: кеше – монда йомычка.
Кеше гомеренең бәясе бар
Яраганда гына йомышка.
Тагын күрдем: халкым яшәсен дип
Ни кылсаң да, бу Ил күпсенә.
Бер гомернең кадере юк Илдә,
Халык гомере дә чүп кенә.
Аксакалдан гафу үтенәм мин,
Икеләнәм кайчак үзем дә.
Табигатьнең ачы ялгышыдай,
Хакыйкатем калсын сүземдә:
«Өченче көн җепшек кар ява...»
Бишенче йөз әрни ул яра...
Онытырга иде... Үчебез юк...

Кемдер һаман аңа тоз сала...

**Бастырылу**

Казан әле, Казан уянмаган...
*Сибгат Хәким*

Йоклый Казан. Урам тулы
Үле тынлык һәм сабырлык.
Еллар үткән саен, аның
Тынын кыса бер авырлык.
Бер карасаң, тыныч кына
Йоклый кебек бу ак кала.
Ә кайчак җан бирә кебек,
Кайчак ыңгырашып ала.
Бастырылу диләр бездә
Бу газаплы саташуны.
Уяу ноктала‍р табылса,
Йокы тагын вата шуны.
Бастырылу диләр аны,
Һава җитми, тын кысыла.
Төшме, өнме? Төнме, көнме?
Чыгып булмый һич очына.
Уяныргa кирәк! Тизрәк!
Җаннар белән кем уйнамас?
Селкенергә – гәүдәң каткан,
Кычкырасың – чыкмый аваз.
Төш икәнлеген аңлыйсың,
Чыгып җитеп булмый өнгә.
Гүя син фәкыйрь өстенә
Җен, албасты, пәри менгән.
Кычкырасың: «Уятыгыз!»
Тик авазың ишетелми.
Йоклый дөнья. Үле тынлык.
Бу хәлеңне беркем белми.
Аваз чыгып китә кайчак,
Шәт, ишетеп, ташламаслар...
Ләкин, кая карасаң да,
Чит тел анда, чит авазлар.
Бастырылган халык саны
Илдә бары бер түгелдер.
Албастының чын исеме
Беркемгә дә сер түгелдер.

Ялгышасыз. Исме аның
Мәскәү түгел. Урыс түгел.
Телен, денен, җанын саткан,
Иң хәтәре – татар бүген.

Рөхсәт булыр уяныргa,
Үләргә бер мизгел калгач.
Тик, үзеңчә бәхилләшеп,
Сүз әйтерлек кеше калмас.

Йоклый Казан. Таң беленә.
Ә чыпчыклар: «Чырык! Чырык!»
Кемдер уяу – төн буена
Җырлап йөри, авыз ерып.

**Җәлил һәйкәле**
*Ялган Ватан өчен корбан – савап,*
*Үзебез өчен гөнаһ микәнни?*
*Айдар Хәлим*

Гасырлар алмашкан елларда,
Йә, Казан, турысын әйт әле –
Азатлык рухына охшаган
Җәлилнең иргылу һәйкәле.
Әйт, Казан, бу кырыс елларда
Какшамас мантыйкка буйсынып,
Баш имәс халыкка охшаган
Җәлилнең килеше, буй-сыны.
Азатлык һәйкәле булырга
Бар аның хокукы, дәлиле.
Августның утызы кебек бит
Казанның мәңгелек Җәлиле.
Гасырлар шомарта ташларны...
Өркегән, җайлашкан, тук халык,
Хөррият дигән сүз хакына
Кузгалмас, җәя һәм ук алып.
Була ул җәясез, уксыз да
Тоташ, нык булырга тау кебек.
Туры сүз, саф, ачык йөз белән
Ireккә чыгарга, бау өзеп.
Сүз әйтеп җиңәрлек кеше юк.
Башыңны күтәреп карасаң –
Сыерчык оясын биләгән
Чыпчыклар пыр тузып талаша.
Кемнең дә, Илнең дә, Чорның да
Буладыр яхшысы, яманы.
Үтәр бу дигән бер өмет бар,
Ә бүген чыпчыклар заманы.
Баш кисеп, дөньядан юк иткәч
Бер көндә унике татарны,
Димәк, чит залимнәр аңлаган
Андагы яшерен хәтәрне.
Азатлык рухына охшаган
Җәлилнең иргылу һәйкәле.
Безнең дә хәлебез шундый бит,
Йә, Казан, курыкмый әйт әле.
Башимәс халыкка охшаган
Җәлилнең килеше, буй-сыны.

Асылда яшибез һаман да,
Какшамас Мәскәүгә буйсынып.
Азатлык турында уйларга
Бар аның хокукы, дәлиле.
Чынлыкның сурәте, күрәсең,
Казанның мәңгелек Җәлиле.
Бозык эш, язык уй, чир басты
Кайчандыр саф бу ак каланы.
Хәмерле, фәхешле дөньяда
Кем дә бер буялмый каламы?
Тәүбә ит, дога кыл, чистарын,
Үксеп бер идәндә тәгәрә.
Татарны коткарыр бары тик,
Бары тик Аллаһы Тәгалә.
Киң сулыш алырга җибәрми
Богаулар һәм тимер муенса.
Әйтегез, мөмкинме бу илдә
Яшәргә Шәригать буенча?
Уңда да, сулда да ярлар юк,
Ерткычлык, бозыклык муеннан.
Кайчан да булса бер булырмы
Котылып бу пәри туеннан?
Болганып таркала ханлыкның
Суештан котылган уллары.
Баулары беләккә уела –
Чишегез Җәлилнең кулларын!
Болганчык ташкын су баса бит
Татарның котылу юлларын.
Нишләргә кирәген белер ул,
Чишегез бары тик кулларын!
Әле соң түгел бит, су әле
Менмәде муеннан югары.
Сулышы бар, йөзеп чыгар ул,
Чишегез бары тик кулларын!
Чишегез кулларын колларның!
Чорларның бу әле яманы.
Кузгалыр берзаман бөркетләр,
Үтәр бу чыпчыклар заманы.
Коткарыр барлык бу дөньяны,
Барны юк, ә юкны бар итеп,
Бары тик Аллаһы Тәгалә,
Аллаһы Тәгалә бары тик...

**Карачкылар**

«...Русия фильмнарында... татар йә явыз, кансыз бер җан иясе, йә аңгырарак... урам себерүче...»
*Рамил Гарифуллин, психолог*

Кемдер егәр, кемдер һөнәр белән,
Осталыгы белән булса да,
Эше белән, рухи көче белән,
Максатына таба юл сала.
Мәрхәмәте белән сөендерә,
Мәхәббәте белән көйдерә,
Тырышлыгы белән сокландыра,
Уңганлыгы белән сөйдерә.
Күр, зиһенең булса, нәтиҗә кыл,
Дөньяда бит күпме гыйбрәт бар, –
Хезмәт белән дан казанып, балда,
Майда йөзгән күпме милләт бар.
Бу сыйфатлар бик чамалы икән,
Инде тагын нинди юл кала?
Илләр басып, кәеф-сафа корсаң,
Эшкә һәвәслек бит югала.
Әгәр холкың бик һавалы икән,
Чит урамнар буйлап киң атлап,
Күкрәгеңдә күлмәк ертып кына,
Кемлегеңне булмый исбатлап.
Татар кебек карачкылар кирәк,
Башларына басып йөрергә.
Акыллы зат булып күренергә,
Юләр кирәк, урам себергән.
«Түбән» затлар янәшә юк икән,
«Бөеклек»не күреп буламы?
Татар ярый тик бер генә эшкә –
Себерергә урыс урамын.
Кино бара: чиркәү тирәсендә
Кысык күзле баскын вәхшиләр,
Саф татарча сөйләп, урысларны
Суеп, асып, кисеп мәш килә.
Дәшмәс идем. Тиле дигән саен,
Сикерә бит, күрми, аңламый.
Бүген дә бит бу «мәкерле татар»
Кемне генә «сатмый», «алдамый».
Дәшмәс идем. Сикерә бит, күрми.

Бу ялганның шулдыр күләме:
Власовның армиясе хакын
Шул унике татар түләде.
Рейхстагка кызыл байракны да
Иң беренче татар күтәрде.
Оялмыйлар. Үзгәртми дә беркем
Тарихтагы ялган сүзләрне.
Бу юлларны язу –түбәнлектер.
Акланулар монда артыктыр.
Үзен үзе күрә белмәгәннең
Күңел күзгеләре ватыктыр.
Өметләнмим кемдер үзгәрер дип.
Бу алдашу озак-озындыр.
Дәвасы юк, сулар һавасы юк,
Бу – «Бөеклек» дигән бозымдыр.
Өметләнмим кемдер уяныр дип.
Без үзебез башта уяныйк.
Күпме ятыйк ишек чыптасында,
Кара төскә көн дә буялып.
Көн дә безгә аяк сөртәләр дә,
Көн дә бездә кара тап кала.
Шунсы кызык: бу кыланыш әле
Мәдәният диеп атала.

...Ник йөгерә халык? Кемнән кача?
Ә без бәйдә... Инде нишләсе?
Без бәйләнгән бауның бер очында
Көйрәп ята дары мичкәсе...

**Рәисләр**
Власть – кешеләрне гарипләндерә торган иң йогышлы чир.
*Эрих Мария Ремарк, немец язучысы*

Эшләр бетеп, җиттеме кич,
Үз өендә улый Рәис.
Әллә җырлый, әллә елый,
Әллә үз язмышын уйлый.
Ялгыз авыл, ялгыз каен,
Хуҗасыз йорт адым саен.
Ялгыз йортта ялгыз адәм
Киләчәккә җырлый матәм.
Киләчәк юк. Эшләр харап.
Улый Рәис айга карап.
Үзе генә тын кичләрдә
Белми хәзер ни эшләргә.
Юкса моңлы тавыш белән
Сәхнәләрдән җырлый белә.
Шомлы аваз, шомлы заман,
Өметсезлек алда һаман.
Ак бүренең ерак улы
Айга карап көн дә улый.

Ялгыз авыл, ялгыз каен,
Ватты кяфер тормыш җаен.
Уңыбыз юк, сулыбыз юк,
Киләчәккә юлыбыз юк.
Китәчәк бар, киләчәк юк,
Юкса әҗәт бирәчәк юк.
Мең газаплы авыл юлы
Каргыш, сагыш белән тулы.
Үз язмышын үзе каргап,
Ярты авыл китеп барган.

Ватык юллар буйлап, кайчак,
Башкаладан рәис кайта.
Сабантуйда биеп ала,
Батырларга бүләк сала.
Китеп бара сүз уйнатып,
Авыл кала сазга батып.
Аяк асты – үле авыл,
Гүя узган кара давыл.

Аяк асты – кабер, зират.
Гомеребез – шуңа чират.
Аяк асты – сөяк, мәет,
Җырларыбыз шуңа бәет.
Сөякләрдә биегәндә
Ниләр уйлый соң бу бәндә?
Ике чакрым гына ара,
Күрми рәис. Узып бара.
Авыл юлы – сулыш юлы,
Яшәү өчен сугыш юлы.
Тын алырлык юл арасы,
Ике чакрым җир барасы.
Газиз Әнкәй – Туган Җир бар,
Әнкәбезне буган чир бар.
Тын алалмый интегә ул,
Тураялмый бил бөгә ул.
Чүп кенә чир – сазга баткан,
Ике чакрым сузылып яткан.
Уңыбыз юк, сулыбыз юк,
Ике чакрым юлыбыз юк.
Китәчәк бар, киләчәк юк,
Юкса әҗәт бирәчәк юк.
Күп кирәкми, юк багасы –
Ике чакрым юл саласы.
Безнең авыл – затлы авыл,
Күпме рәис биргән табып.
Юлдан читтә ул урнашкан,
Рәисләре чиктән ашкан.
Кечкенә ул. Юк аңа иш.
Йорт аралаш рәис… рәис…
Татар түрәләре кадәр
Юктыр бездә башка хәтәр.
Гамь аларда дөнья хәтле,
Күрмиләр «вак» мәшәкатьне.
Авылдашларын гынамы –
Танымый хәтта туганын.
Купшы күркә өммәтендә,
Күрми хәтта сөннәтен дә.
Тырышса да андый түрә,
Үз буксәсен генә күрә.
Юлыбыз юк, юлыбыз юк,
Таянырлык улыбыз юк.
Ике чакрым гына ара,

Күпме рәис узып бара.
Ялгыз авыл, ялгыз каен,
Хуҗасыз йорт адым саен.
Эшләр бетеп, җиттеме кич,
Үз өендә улый Рәис.
Ак бүренең ерак улы
Айга карап көн дә елый…

Һәр авыл ул – дөнья хәтле.
Үлеме «вак» мәшәкатьме?

**Төнге юл, ягъни Соңгы сүз**

Без бәхет эзләмибез, без бәхетсезлектән качабыз...

Ике генә чакрым калган иде,
Туктап калдык юлда ватылып.
Караңгы төн, болытлы төн иде,
Тирә-якта юк бер яктылык.
Иптәш җәяү китте ярдәм эзләп.
Сакта калдым. Уйлыйм барысын.
Ә бит бу юл – авылыбыз йөзе!
Кем төзәтер ташлап бар эшен?
Күптән йоклый авыл. Ул арыган.
Төнге тамашалар карамый.
Өлгермәдек. Үтеп өлгермәдек
Ике генә чакрым араны.
Йөз чакрымны үттек җырлап кына,
Ике чакрым – елап үтәсе.
Авылыңның юлы шундый икән,
Башка эшең синең – чүп кәсеп.
Тормыш кырыс. Ике чакрым өчен
Беркемгә дә булмас ташлама.
Бу дөньяда барлык бөек эшләр
Авыл юлларыннан башлана.
Ике чакрым ватык авыл юлы,
Иман дигән олы чут аша,
Ахыр чиктә, шулай бер чутласаң,
Азатлыкка барып тоташа.
Тагын уйлыйм. Пычрак суга төшкән
Асылташлар кире калыкмый.
Нигә шулай һаман батабыз без?
Рәисләрме шундый? Халыкмы?
...Күзгә төртсәң күренмәслек төндә
Мин утырам, уйлыйм барысын.
Чит бер түрә юл түшәмәс безгә,
Безнең өчен ташлап бар эшен.

Караңгы төн. Кемдер тагын улый.
Әллә Рәис, әллә бүреләр.
Алда бары авыл башындагы
Зират күләгәсе күренә...

**Азатлык көле**
*Поэма. Икенче кисәк*

Тәүбә
Бу – безнең җир
Аң йокысы
Кардәшләр
Кайтаваз
Ике күрше
Шәйнур
Ак Бүре
Йолдызлар
Төнге сүз

**Тәүбә**

Рим папасы Иоанн Павел II урта гасырларда инквизиция кылган җинаятьләр өчен гафу үтенде**.**

*«Азатлык» радиосы. 16. 06. 2004*

«Сугыштан соң тәүбә кылып, затлы, имин тормыш төзегән Германия башка тоталитар илләр өчен менә дигән үрнәк...»

*Интернет-форум*

Өмет сүнә. Җылы җилләр тына.
Килеп кердек урыс кышына.
Муендагы дүрт гасырлык элмәк
Көннән көнгә ныграк кысыла.
Кайный халык мегаполисларда,
Аралаша, чаба тыз да быз.
Тамырларны өзә чор давылы,
Яңа милләт туа кыйбласыз.
Яңа Тарих, яңа юллар ачып,
Егерменче гасыр узса да,
Яңа Иван, яңа Шаһгалиләр
Яраларга һаман тоз сала.
Яра тирән. Төзәлерлек түгел.
Ул әкренләп безне бетерә.
Иркен сулыш алып, бер селкенсәң,
Каланчадан усал эт өрә.
Кемдер бәхет эзләп, кем үпкәләп,
Кем үрмәләп киткән өскәрәк.
Читләр буса безне бер сәбәптән,
«Безнекеләр» таба мең сәбәп.
Таза-таза ир-егетләр йөри,
Патша кызы кебек үпкәләп,
Хуҗаларның алкышына батып,
Газиз туган җирен типкәләп.
Чит казанда кайнап, каешланып,
Дәрәҗәгә, данга ирешеп,
Кардәшләре, туганнары өчен
Эшли алар һаман киресен.
Бармы тагын шундый мәгънәсезлек,
Тәрәккыят үсеш юлында, –
Үз халкыңның каберенә басып,
Нотык сөйләү дуслык турында?
Нинди дуслык, нинди хокук монда?

Булса да ул булыр өч көнлек.

Аларның бит һәрбер җөмләсеннән
Аңкып тора бозык өстенлек.
Аермаслык булып береккәнбез,
Бармы безнең башка чарабыз?
Шулкадәрле «дус» без – хәзер аңа
Хәтта хәреф сорап барабыз!
Үз абруең үзең вакламаска
Әзрәк зиһен бардыр лабаса!
Бөекме ил, латин хәрефеннән
Бөеклеге чатный башласа?
Вакыт узган, барысы да булган,
Бер-беребездән кая без китик?
Тигез, имин, затлы тормыш корып,
Бөек була илләр бары тик.
Башка юл юк. Вакыт шуңа илтә.
Ә вакытка булмый карышып.
Ләкин бүген күсәк тоткан илдән
Качу ягын карый барысы.
Күсәгеннән аның, кан аралаш,
Аңкып тора кыргый өстенлек.
Бар өстенлек шул күсәктә генә,
Асылында – бушлык, мескенлек.

Күзәтәм дә купшы сөйләм телен,
Кара, коңгырт төсләр алмашын,
Шуны күрәм: тигезлеккә монда
Бернинди буш өмет калмасын.
Шуны аңлыйм: тәүбә юлын монда
Каплый ялган тарих сөреме.
Тагын уйлыйм: әллә бу кирелек
Берәр чирнең күмәк төреме?
Тәүбә кылу – акыл бөеклеге,
Эчке якты куәт билгесе.
Дистә еллар аша бәреп чыккан
Газаплы аң, вөҗдан җимеше.
Юкса күпме каргыш бу кырларда,
Күпме кан-яшь аккан, коелган.
Гаепсезләр күпме кимсетелгән,
Гөнаһсыз җан күпме кыелган.
Затлы тормыш корган илләрне дә
Аямыйдыр вөҗдан газабы.

Имин дөнья гамьсез күренсә дә,
Тәүбә аның, тәүбә азагы.

Ил язмышын уйлап чаң сугарга,
Көл астында тимер кызганда,
Әй, якташлар, нинди вөҗдан белән,
Нишләп йөрисез соң сез анда?
Үз җырыңның бугазыннан буып,
Сулый алмый, шуңа тончыгып,
Таушаласыз нинди бәхет өчен,
Кайсы халык өчен борчылып?
Хакыйкать бар, какшатырлык түгел
Утка-суга хәтта салып та.
Түрәләргә үпкә адым саен,
Тик үпкәләп булмый халыкка.
Әйе, кем дә тик үзенчә хаклы,
Йөртә сезне ихлас теләкме?
Читләр төреп, читләр читтән керткән
Бу «хакыйкать» безгә кирәкми.
Барын бирдек инде. Һаман җитми.
Ипле, имин тормыш кайда соң?
Кем тыкшынып тынгы бирми икән,
Димәк, эзли тик үз файдасын.
Яманы да хәтта тик безнеке.
Җир таланган. Нигә бу киртә?
Килер вакыт – һәркем җавап тотар,
Без үзебез хаким бу җирдә.

Әй, якташлар, нинди уйлар белән,
Нишләп йөрисез соң сез анда?
Һаман безнең күзне ачасызмы?
Тик без сукыр түгел Казанда.
Төпле тормыш корган ирләрне дә
Аямыйдыр вөҗдан газабы.
Күпме генә йомгак сүтелсә дә,
Тәүбә аның, тәүбә азагы.
Ләкин бүген артык иртә әле.
Тәүбә «бөек халык» эшеме?
Телсез, илсез милләт ясап кына
Тигезлиләр монда кешене.
Өмет сүнә, җылы җилләр тына,
Килеп кердек урыс кышына.
Муендагы дүрт гасырлык элмәк

Көн дә ныграк, ныграк кысыла.

Иркен сулыш алып, бер селкенсәң,
Каланчадан усал эт өрә.
Вакыт уза. Вакыт безне боза.
Ул әкренләп безне үтерә.

Ихлас тәүбә кылып,
Бер җилләтсәң
Җәбер тулы тынчу һаваны,
Бәлки, килер иде
Бөек Русиянең
Бөек халыклары заманы...

**Бу – безнең җир!**

«Ник ачтыгыз безне?!»
*Исерек чукчаның җимерек торагы янында әйткән сүзләре.*

«Бу – безнең җир!»
*Байрак тоткан Кырым татарының ОМОНчыларга әйткән сүзләре.*

Намаз укып, сәҗдә кылып,
Мунча кереп, уйнап-көлеп,
Иген игеп, без көн иткән,
Бу безнең җир иде элек!
Тау астыннан яу керәсен
Булмый икән алдан белеп.
Алла диеп без яшәгән,
Бу безнең җир иде элек!
Илләр, җирләр, халыкларны
Асып, кисеп, турап, телеп,
Башка илдән патша килгән,
Бу безнең җир иде элек!
Күпер бауда, Казан тауда,
Түгелде кан, кипте җелек.
Бау өзелде, яу тезелде,
Бу безнең җир иде элек!
Катлам-катлам кан укмашкан,
Тимер кебек утта эреп.
Кызыл елга булып аккан,
Бу безнең җир иде элек!
Катлам-катлам казылган җир –
Гасырларның өнсез теле.
Көл астында канлы кала,
Бу безнең җир иде элек!
Кара катлам – бусы каны,
Соры катлам – бусы көле.
Яшел үлән – бусы җаны,
Бу безнең җир иде элек!
Ник бастыгыз? Ник бастыгыз?
Юлбасардай бәреп кереп.
Шаулап-гөрләп дәүләт корган
Бу безнең җир иде элек!
Янды кала, кырды патша
Мөслимнәрне суеп, сөреп.

Без куылган, без сөрелгән,
Бу безнең җир иде элек!
Иле дә юк, теле дә юк,
Бетә инде татар череп.
Ник бастыгыз? Ник бастыгыз?
Бу безнең җир иде элек!
Җавап булмас. Урам буйлап
Читләр йөри уйнап-көлеп.
Өзелде көн, тезелде төн,
Бу безнең җир иде элек!
Тел яшереп йөргән халкым
Куйсын муенына элеп –
Дога кебек изге сүзләр:
Бу безнең җир иде элек!
Көн дә безне кимсеткәннәр,
Ирек бирми җанны телеп, –
Монда безнең Дәүләт булыр,
Бу безнең җир иде элек!
Үч итмәбез, кимсетмәбез,
Тик йөрегез шуны белеп:
Без беркайчан онытмабыз:
Бу безнең җир иде элек!

**Аң йокысы**

Аң йокысы хәшәрәтләрне тудыра.
*Гравюра. Франсиско Хосе де Гойя, испан рәссамы*

Башсыз калган гәүдәнең йокысы ничек тәмле!..
*«Тауның ыңгырашуы». Ясунари Кавабата, япон язучысы*

Мин уяндым. Ләкин мин юк.
Мин – югалган аң төбе.
Аң төбендә минем Тарих
Атмый калган таң кебек.
Таңнар ата, ни булса да,
Җир әйләнә барыбер.
Тәрәзәгә, таш шикелле,
Язмыш безгә бәрелер.
Көтмәгәндә бәреп егу
Акылга сыямы соң?
Кара җәймә алыштырды
Тәрәзә пыяласын.
Мин уяндым. Кара бүлмә.
Табалмыйм үз-үземне.
Мин юк монда! Мин юк монда!
Белмим, көнме бу, төнме?
«Без исән! Без монда!» диеп,
Хәбәр сала кемнәрдер.
Күреп булмый. Безнең өчен
Барысы да төн хәзер.
Кем аерып чәчте безне
Бу битараф дөньяга?
Таңны каплап, аңны каплап,
Һаман кара төн ага.
Мин уяндым. Ләкин мин юк!
Моннан да хәтәр ни бар?
Кая гына борылсам да,
Алдымда кара дивар.
Бәргәләнү дә файдасыз.
Ятам тешемне кысып.
Вакыт туктап калды кебек,
Күренми таң яктысы.
Мин булырга тиеш монда...
Көнме бу, әллә төнме?
Кемнәрне генә тапмадым,

Табалмыйм тик үземне.
Селкенмә, диләр, селкенмә,
Ваемсызларга елыш.
Уянганның уе хәтәр,
Уянмаганнар тыныч.
Кемдер уяу. Никтер елый.
Иңенә куям иңне.
Бәхеткәме, кайгыгамы,
Тик мин уяндым инде.
Берни күрми, кулым сузып,
Киләм тын гына басып.
Йөзләр... Йөзләр... Йомык күзләр...
Бу бит йокы дөньясы!
Кагылганны беркем сизми,
Ишетелми сүзем дә.
Мине беркем күрми икән,
Димәк, юк мин үзем дә.
Кая гына борылсам да,
Алдымда кара дивар.
Уянганнар һаман елый,
Ваемсызлар йоклыйлар.
Мин уяндым. Ләкин мин юк.
Ни бар моннан да хәтәр?
Кара упкынга убыла
«Без исән!» дигән хәбәр.
Кара дөнья, кара бүлмә,
Булмый гына ут элеп.
Кемдер елый, кемдер йоклый,
Башка берни юк кебек.
Моннан да куркыныч ни бар –
Киләм тын гына басып.
Йомык күзләр... Салкын йөзләр...
Бу – мәетләр дөньясы!
Сискәнеп бер кычкырсаң да
Уянмыйлар мәетләр.
Дөнья беткәч, бу үлемдә
Ходай кемне гаепләр?
Тарихны булмый үзгәртеп,
Узылган тик бер юл бар.
Табут кадагына суга
Тәрәзә ваткан куллар.
Мин уяндым! Ләкин мин юк!
Ишетегез сүземне!

Мин булырга тиеш монда!
Тик югалттым үземне...

**Кардәшләр**

2002 елда, халык санын исәпкә алганда, ярты миллионнан артык татарны башкорт дип яздыралар... 2007 елда Башкортстан җитәкчеләре төзелеп бетеп килгән татар гимназиясен бульдозерлар белән җимертәләр...

*Матбугаттан*

...җирле матбугаттан татар проблемасын эзләдем. Юк икән андый проблема! Бары тик зур бәйрәмгә – Русиягә кушылуның 450 еллыгын бәйрәм итүгә әзерләнү генә бар.

*«Уфаларга баруларым...». Искәндәр Сиражи*

Башкорт туган, газиз кардәш,
Бу синең чын теләкме?
Йортка кергән ир бәйрәме –
Бу сиңа бик кирәкме?
Вакладың да ирегеңне,
Сакладыңмы халкыңны?
Тының буып кысып кочкан
Мәскәү кулы салкынмы?
Чит яудан куркып кердеңме?
Җан сакларга теләпме?
Җан саклана, тик ваклана,
Ә бу сиңа кирәкме?
Туганыңнан урлап, хәзер
Төзәтәсең саныңны.
Кем шулай бозды, ваклады
Бөркеттәй хөр җаныңны?
Кем сиңа, татар – дошман, дип
Күрсәтә юк өрәкне?
Башкорт туган, бу түбәнлек
Чынлап сиңа кирәкме?
Тамырлар безнең береккән,
Аны ялган өзалмый.
Туган туганны кичерер,
Тик Тарих бит төзәлми!
Кабер әзер. Кем кулында,
Күрәсеңме, көрәкне?
Күпме милләт бу кабердә,
Ә бу безгә кирәкме?
Саның кими, даның кими,
Булышмады кушылу.

Бәйрәм түгел, бу – упкынга,
Җәһәннәмгә убылу.
«Ә?» дигәндә «Мә!» дип, синдә
Шундый куштан йөрәкме?
Бу мәгънәсез пәри туе
Чынлап сезгә кирәкме?
Оялмадың, күп урладың,
Арттырдыңмы халкыңны?
Кем сүндерде җаныңдагы
Вөҗдан дигән ялкынны?
Бу бәйрәмнең чын әҗере
Сиңа, миңа эләкми.
Үтәр бу коры куаныч,
Ә бу сезгә кирәкме?
Түрәләр бәйрәм итә, тик
Акыллылар качалар.
Котылганнар кире кайтмый,
Тотылганны асалар.
Аек аңлы зиһенлеләр
Әллә сездә сирәкме?
Башкалардан уңайсыз бит,
Ә бу сезгә кирәкме?
Үзең теләп богау кию –
Тузга язмаган бәет.
Гүрдә әйләнеп яткандыр
Күпме гаепсез мәет.
Ярый... Кердең... Кирәк иде...
Аңламыймдыр мин бүген.
Кайгы булмаса да, бу бит,
Һәрхәлдә, бәйрәм түгел.
Башкорт туган, әллә чынлап
Бу Ил сезгә терәкме?
Бу бәйрәм – тик ныграк бәйләү,
Ә бу сезгә кирәкме?
Кемгә терәк, кемгә элмәк,
Болганчык су – халыклар.
Талашабыз да күрмибез –
Анда Алтын Балык бар.
Кемдер тота ул балыкны.
Тарих безне өйрәтми. –
Якабыздан тотып, беркөн
Бирер әле кирәкне.
Кемнәр сезне адаштырып

Йөртә кара урманда?
Ботак саен элмәк, мәет...
Әлегә без юк анда.

Кара урман, хәтәр дөнья,
Ерткычларга кирәк ит.
Асылынган коллар өчен
Бау бердәнбер терәк бит...

**Кайтаваз**
Кем булмас минем кунагым?!
Кунак – хуҗасына күрә!
Шәп пар атка урам эте
Икеләтә каты өрә.
*Ренат Харис*

Күрше йортта бик күңелле –
Хуҗа кунагын сыйлый.
Тик нигәдер эте генә
Чылбырын чәйнәп елый...
*Р. Ш. 1979*

Сүзләрегез охшаш, әрле,
Дәрәҗәле, һавалы.
Нинди иман сезнең аша
Тетрәтә бу һаваны?
Җан өрергә кирәк чакта,
Сулышыгыз салкын бит.
Сүзләрегез – көмеш, ләкин
Дәшмәвегез алтын бит.
Акыл өйрәтү көлкедер,
Урынсыздыр вәгазь дә.
Язасым килми! Карышам! –
Каләм тарта кәгазьгә...
Бәлки, артыктыр каныгу
Вак-төяк бу сүзләргә.
Әйтсәң, тагын чүп сүз чыга,
Әйтми ничек түзәргә?
Көмеш сүзгә төреп сөйлә
Хак, ачы, шомлы хәлне.
Чүп сүз күмә, яба, каплый
Хакыйкать дигән мәлне.
Кунакка йөрү бәйрәм бит!
Кунак итү савап бит!
Кардәш кунак, бердәм куәт
Кяфергә шәп җавап бит!
Шулай булса иде! Бәлки,
Шулай булыр да әле.
Утырып бер еларлык бит
Бүген кардәшлек хәле.
Аерып, бүлеп талауның
Рәтен белгән залимнәр.

Гасырлар аша шомарган,
Әле дә шундый алым бар.

Бүлеп була тел буенча,
Мал биреп, бүләк биреп,
Ялагайрак кулларга
Саллырак күсәк биреп.
Тирәнгә китте бүленеш,
Хәтта табигый кебек.
Кемдер шат, кулларын уа,
Ерактан гына көлеп.
Урам буйлап атлар чаба,
Этләр өрә ниндидер.
Безне кабергә тыгалар,
Кунакка йөри кемдер.
Кемдә үләт, кемдә мәҗлес –
Бүлгәлә дә буйсындыр...
Тик без урам эте түгел,
Безнең муенда чылбыр.
Кунаклар йөри урамда,
Сыйлашып, чәйләп-мәйләп.
Без өрәбез йортны саклап,
Елыйбыз чылбыр чәйнәп.
Гамьсез, купшы сүз агыла
Утырып елар мәлдә.
Кардәшлек тә, азатлык та
Үләрлек авыр хәлдә.
Ә дәвасы сездән тора,
Вакыты аның уза,
Хуҗасына күрә кунак,
Кунагына тиң хуҗа!
Сезнең кебек зур әдипләр
Мохтаҗ түгел вәгазьгә.
Мин теләмим. Тик бу юллар
Үзе ага кәгазьгә.
Ә шулай да өмет яши,
Булыр әле савап эш –
Кардәш кунак, бердәм куәт,
Милли кодрәт, күмәк көч!
Ә әлегә ачы җилләр
Җанны, канны өшетә.
Йокламый эт, елап өрә,

Ат кешнәвен ишетә...

**Ике күрше**

Казан йорты илә Нугай йорты борынгыдан бирле үзара орышып яшәделәр...

*Һади Атласи*

Сугышырга җитеп, хәтта
Күралмыйча берсен берсе,
Тигезли алмый ызанны,
Талашты гел ике күрше.
Икесе дә төпле хуҗа,
Баш күтәрми эшли торган.
Юктан башлап, җирен ашлап,
Үз тормышын үзе корган.
Эшләделәр, ызгыштылар,
Тормады берсе дә җебеп.
Көн артыннан көн узганны
Күрми дә калдылар кебек.
Шулай узды гомерләре,
Юкка түгел берничек тә.
Бәби арты бәби үсте
Матчага элгән бишектә.
Балаларын борчымады
Бакчаның бер карышы да.
Вакыт җиткәч, берәм-берәм
Читкә очты барысы да.
Бушап калган нигезләрнең
Тышы да юк, эче дә юк.
Ызан аша бер-береңә
Сүз әйтерлек кеше дә юк.
Элек ялт иткән бакчада
Шаулап үсә кыргый үлән.
Китеп бетте бала-чага,
Үлеп бетте күрше-күлән.
Капкалар күптән ачылмый.
Шомлы тынлык буш нигездә.
Әҗәл чалгы белән үткән,
Кыек ызанны тигезләп.
Тәрәзәләр кара, җансыз,
Юк анда гөл, юк анда ут.
Беркемгә берни кирәкми,
Бакча да юк, ызан да юк.

Нәрсә эзләп тырыштык соң?
Нинди тормыш булды соң бу?
Бәрәкәт китә нигездән...
Нинди ым бу? Нинди шом бу?
Кардәшләрнең чардуганын
Якын куеп бер-берсенә,
Вакыт үткәч, соңлап безне
Тигезләрме кабер генә?
Юктан башлап, эшне ташлап,
Үпкәләшү чиктән ашкан.
Гомер узган, бакчабызны
Чүп үлән, чит үлән баскан...

**Шәйнур**

Тираннарга каршы тору – Аллага буйсыну ул.
*Томас Джефферсон, Америка мәгърифәтчесе*

Кеше нидер эзләп дөнья гизәр,
Ә эзләгәнен өенә кайткач табар.
*Томас Мур, инглиз шагыйре*

Алтмыштан соң, ахры, тәүбә кылдың,
Мәскәүдәге мишәр туганым.
Тәүбә кылу – чын егетләр эше,
Тәүбәнең бит ояты юк аның.
Кара, пычрак, фани дөнья бит бу,
Кем дә булса берчак карала.
Каралыкта, фәхеш куенында,
Нәфес, сугыш, каргыш ярала.
Ә син читтә йөрдең күпме еллар,
Ныклы, таза тормыш төзедең.
Ныклы, төпле бер фикергә килдең
Уртасында гомер көзенең.
Туган җирең онытылып бара,
Туган телең юктыр исеңдә.
Казаныңа ашкынасың һаман
Газиз халкым бар бит дисең дә.
Газиз телем бар дип кайтасың да,
Килмешәктәй булмый бит үлеп, –
Онытылган татар авазларын
Өйрәнәсең хәзер тир түгеп.
Газиз илем бар дип кайтасың да,
Әләм тотып таза кулыңа,
Милләтчеләр белән бер рәттә син,
Татар өчен көрәш юлында.
Дөнья куып онытылган сүзләр
Энҗе-мәрҗәннәргә тиң хәзер.
Акча түләп, хәтта үз телеңне
Өйрәнергә бүген син әзер.
Тел бөрешкән. Ияләшкән инде
Чит авазлар, сүзләр көенә.
«Ө» дип әйтү кыен, тик, өйрәнгәч,
Сабыйларча җаның сөенә.
Сабыйларча саф күңелдән, ахры,
Синдәге бу сәер омтылыш.
Башкаларны вөҗдан борчымый бит,

Бик ваемсыз алар, бик тыныч.

Ничә еллар буйлап кара эштә,
Иңдә йөрткән кара тубалдан,
Җаныңның ак, олы куанычы
Төшеп калган юлда, югалган.
Караңгыда кинәт, шуны аңлап,
Каерып ак хәтер келәсең,
Еллар буйлап, изге эзләр буйлап,
Шуны эзләп, ахры, киләсең.
Күзләреңдә балкый иман нуры,
Шуңа мәллә көннәр яктырак?
Син кайтканда изге эзләр буйлап,
Кара йөзләр тора аптырап.
Соң булса да уң булсын бу юлың,
Тәүбә өчен әле соң түгел.
Шаулы кара карга төркемендә
Яктылык, ак өмет син бүген.
Көннәр, эшләр бераз яктырдылар,
Мал кайгысы кая югалган?
Маңкортларның коры куанычы
Сыймый хәзер синең тубалга.
Тик шулай да якты киләчәккә
Барасы да әле барасы.
Исем китә кайчак, ничек ерак
Татар белән татар арасы.
Хак Тәгалә күрәдер бу эшне, –
Иман нуры балкый йөзеңдә, –
Алып чыгар сине якты юлга,
Җан биргәндә гомер көзендә.
Бетәбез дип, көн дә күңелләрдә
Аянычлы, кара уй яна.
Сине күргәч, Шәйнур, көн яктыра,
Аз булса да өмет уяна...

**Ак Бүре**
Кызыл чүпрәкле бау – безнең чик бу.
Аучы халкы, тотып колгалар,
Һәр куакның эчен савып, имеш,
Безне түгел – бүре сугалар...
*Айдар Хәлим*

Болгар-татар нәселе Ак бүре имезеп ач үлемнән коткарган Болгардан башлана,имеш...
*Риваять*

Ак Бүре җан биреп ята,
Һавада кара тилгән, –
Җирдә аучыларны күреп,
Үләксә эзләп килгән.
Капкында Бүре. Сизенә,
Бу – Әҗәл куйган тозак.
Җибәрми торган богаулар,
Ачылмый торган йозак.
Азатлык теле, бары тик
Кошлар, җәнлекләр теле.
Аңлый Бүре: азатлыкның
Бүген иң соңгы көне.
Каракош аны күзәтә.
Икенче дөнья күктә –
Барысы да күз алдында
Тамаша кебек үтә.
Ак Бүре капты тозакка,
Таркалды ыруг-төркем.
Тозакта булса да, аңа
Якын килалмый беркем.
Сизенә Бүре, сызланып –
Бу инде соңгы тозак.
Мондый үлем хурлык түгел,
Газабы гына озак.
Куе урман, тыгыз божра,
Иң шәбе – качып тору.
Газабы бетәр әле, тик
Яшәсен нәсел-ыруг.
Аерылган бүреләрне,
Текә ярларга терәп,
Өерелеп өлгергәнче,
Аталар берәм-берәм.

Ишетелә барысы да,
Шартлау... Чинаган тавыш...
Хет үткен тешләрең белән
Үз аягыңа ябыш.
Дары төтене тарала.
Барысын күрә тилгән –
Бу аучылар азык түгел,
Тамаша эзләп килгән.
Бары бердәм өер белән
Божраны була өзеп,
Көчлегә көчең күрсәтеп,
Җәберсез дөнья төзеп.
Өерелеп ябышмасаң
Аучылар бугазына,
Җәзасыз калган явызлык
Котырына, азына.
Ялгыз Бүре тып-тын ята,
Аучылар кайтып бара.
Этләре сизә Бүрене,
Ерак булса да ара.
Хәлсез, кыргый туганына
Котырып өрә этләр.
Бүредә, эт язмышында –
Кемдә, нинди гаеп бар?
Аңламый Бүре берни дә,
Аңын югалта инде, –
Нигә бу тигез көрәштә
Астыртын мәкер җиңде?
Нигә яралы Бүрегә
Торалар мылтык терәп?
Бай йортларның тук этләре
Нигә котырып өрә?
Сугышып та булмый хәзер,
Котылырга җай да юк.
Телгәләнгән аяк белән,
Азатлыктан файда юк.
Бүреләр генә beләдер
Чын азатлыкның хакын.
Тешен ыржайтып, беркемне
Китерми һаман якын.
Ишетте тилгән барсын да,
Шартлау... Чинаган тавыш...

Табигать өчен җәрәхәт –
Аучылар өчен табыш.
Ак Бүре җан биреп ята,
Һавада кара тилгән.
Бу юлы ул монда юкка
Үләксә эзләп килгән.
Затлы табышны күтәреп,
Аучылар кайтып бара.
Этләре шыңшып калтырый,
Ерак булса да ара.

Күпме азат җан иясен
Каптырып алган тозак,
Җибәрми торган богаулар,
Ачылмый торган йозак.
Тел очыма сорау элеп,
Еракка карап торам.
Тәүбәгәме, хәйләгәме,
Кая илтә бу урам?
Исертәме, тилертәме
Сине дары төтене?
Син өй сакчысымы тугры,
Котырган ау этеме?..

**Йолдызлар**

Хыялдагы камиллекне таба алмагач, без көндәлек фәкыйрьлеккә сыенабыз...

*Гюстав Флобер, француз язучысы*

Шыгыр-шыгыр шигырь чыгырына басып,
Шул чыгырга төпсез чиләк, чылбыр асып,
Кое түгел, тормыш төпләренә төшеп,
Ярты-йорты җыр әвәләп ашык-пошык,
Авылымны бик сагындым, бер кайтам дип,
Күлдәвектә давыл ясап, яратам дип,
Әштер-өштер әсәр-мәсәр язып-сызып,
Чиле-пешле дөбер-шатыр аваз тезеп,
Оештырып орыш-талаш, этеш-төртеш,
Мәдәният-сәнгать дигән булып йөрмеш.
Йомры башлы тукмак тотып беләк буе,
Сәхнәләрдә әлҗе-мөлҗе өрәк туе.
Аллы-артлы, чуар чуклы, бәйләм-бәйләм,
Арлы-бирле, пыран-заран, әйлән-бәйлән.
Иләс-миләс әтрәк-әләм үлә-үлә,
Узып барган йолдызларның эзен үбә.
Катнашмасаң үрле-кырлы кул чабуда,
Тиң була бу үз-үзеңә кул салуга.
Шик-шөбһәле сүзең чыкса әгәр, җаный,
Шырды-бырды, ыбыр-чыбыр фанат яный.
Өрәк туе, әфсен-төфсен, ырым-шырым,
Әйле-шәйле денсез чорым, үксез җырым.
Үлем-җитем, бәла-каза булмаса да,
Үлә-бетә иксез-чиксез чүп ясала.
Көне-төне яңа йолдыз туа килә,
Иске-москылары арттан куа килә.
Йолкып алып, селкеп салып күрсәтерлек
Ямьсез-тәмсез, моңсыз йолдызлыкка кердек.
Боз суккандай йолдыз ява шыбыр-шыбыр,
Кәсепчеләр шигырь яза шыгыр-шыгыр.
Эреп ага, суы кара, җирне яра.
Сак булыгыз! Татар моңы китеп бара.
Сак булыгыз! Язмышларның хәтәр чоры,
Китеп бара тып-тын гына татар җыры...

**Төнге сүз, ягъни Соңгы юл**

Ахырын һәм башын белми араларның,
Чик-чамасын, гамен белми дөньяларның,
Әкрен генә Галәм буйлап агып барыш,
Ә күңелдә Галәм кадәр чиксез сагыш...

Караңгы төн, кара еллар, кара урман...
Бу – безнең җыр, бу безнең җыр әле һаман!
Тыңлап ятам күккә карап кара төндә.
Бер уйласаң, Җир язмышы кыл өстендә.
Бәрелә йә астероид, йә комета,
Яисә аны берәр кара чоңгыл йота.
Юкка чыга барысы да бер мизгелдә,
Тереклек тә, җир дә, су да, ил дә, тел дә.
Ә без шушы нәни тузан бөртегендә
Сугыш ачабыз бер монда, бер тегендә.
Дөнья куа табыш, мал-мөлкәт дип кемдер,
Һәр килмеш көн шуны уйлап үткән көндер.
Кемдер яза, кемдер милләт дип сызлана.
«Күрсәтәм милләт!» дип, кемдер җиң сызгана.
Кемгә кирәк бу милләтче, бу малтабар?
Тузан кебек бу бөртектә ни мәгънә бар?
Иксез-чиксез дөнья бит бу, без кечкенә,
Җирдә тормыш бер мизгеллек бер төш кенә.
Нигә, борып, яңа тарих корып булмый?
Һәм, гомумән, без барган юл дөрес юлмы?
Юкка түгелдер Җирдә бу тере җисем,
Чиксез Галәмне кочарлык чиксез зиһен.
Шул зиһеннең исеме бер – Алладыр тик,
Алла диеп, дөнья куып гомер итик.
Гөнаһ түгел мөлкәте дә, табышы да,
Милләтченең халкым дигән сагышы да.
Ә мәгънәсе тик бер генә – гомер итү.
Үле җисем үзе мәгънәсезлек бит ул.
Җир кечкенә, дөнья чиксез, шөкер итәм, –
Димәк, зиһен шулкадәрле чиксез икән.
Кара урман җырын тыңлыйм кара төндә.
Ил язмышы, тел язмышы кыл өстендә.
Бу дөньяның бер почмагы оҗмах кебек,
Тик безнең җир, тик безнең җир иде элек.
Кара еллар, караңгы төн, кара урман...
Бу безнең җыр әле һаман, әле һаман!

Кара урман, кара еллар, караңгы төн,
Галәми көй, тылсымлы җыр, илаһи моң...

**Азатлык теле**

*(Поэма. Өченче кисәк)*

Чигенмә
Тел
Арыслан һәм көчек
Җан юлы
Террор
Җыр
Тәмле Чишмә
Соңгы сүз

**Чигенмә**

Таш атканга аш ат.
*Татар халык мәкале*

Көч кулланмый гына каршы тору ысулы белән Һиндстанны Британия коллыгыннан азат итүдә хәлиткеч роль уйнаган Махатма Ганди турында Лондонда опера куелды...
*Интернет-хәбәрләр*

Аш атсалар сөенәсе түгел,
Аш аталар кайчак аучылар.
Таш атканга таш атасы түгел,
Таш артыннан кыргый яу чыгар.
Аш атсалар сөенәсе түгел,
Таш атсалар тик тор, селкенмә.
Явызлыкка каршы торып була,
Таш күтәрми каршы беркемгә.
Бу дөньяның яме, бәрәкәте
Барыбызга тигез бирелгән.
Таш күтәрмә башсыз баскыннарга,
Тик чигенмә баскан җиреңнән.
Түз, курыкма, килер Сүз вакыты,
Озак яши алмас бу ялган.
Күзләреңдә булсын туры караш,
Тик, береккән кебек, кузгалма.
Күңелеңә – Ходай түземлеге,
Зиһенеңә иңсен Хак Китап.
Күзләреңдә булсын курку белмәс,
Тыелгысыз, ачы Хакыйкать.
Таш күтәрмә, башың күтәрсәң дә,
Бушка күпме кан-яшь агыздык.
Залимнәрнең куәтенә каршы
Чүп кенә ул безнең явызлык.
Котылгысыз булыр Хак Сүз өчен,
Кешелекле, гадел, ачык Чор.
Үз сүзеңдә торып, үз җиреңдә,
Беркетелгән кебек басып тор.
Сүз дә ташны тишә,
Кайчак, ярны ишә,
Тамчы булып тамса, көн саен.
Таш күтәреп капка ватып булмый,
Ә Сүз белә аның мең җаен.

Кан коймыйча, җан кыймыйча гына
Хөр мәмләкәт тими беркемгә.

Кан кирәкми безгә. Таш күтәрмә,
Тик сүзеңнән чыкма, селкенмә.
Атсыннар таш. Хак Сүзеңнән чыкма,
Чигенмичә баскан җиреңнән.
Бу – безнең җир. Аның байлыклары,
Бары безгә, безгә бирелгән.
Күңелеңә иңсен Илаһи Сүз,
Зиһенеңә – Китап сүрәсе.
Кан кирәкми, җан кирәкми безгә,
Һәм кирәкми кяфер түрәсе.
Башың күтәр, ләкин таш күтәрмә.
Күпме кан без бушка агыздык.
Озын-озак Хакыйкатькә каршы
Чыдый алмый хәтта явызлык.
Бу Хакыйкать, ачы сабак булып,
Таш өстенә тамсын көн саен.
Тотынсалар күтәрмәкче булып,
Таш уалыр беркөн, йомшарып.
Баш өстеңдә таш уйнатса кемдер,
Үз сүзеңнән китмә, селкенмә.
Әҗәт-бурычка без яшәмәдек,
Бирәсе юк берни, беркемгә.
Түз, курыкма, уңар озакламый,
Җете кызыл кебек бу ялган.
Күзләреңне күтәр – күпме дөнья
Яшел төскә инде буялган.
Үз сүзеңдә торып, үз җиреңдә,
Беркетелгән кебек басып тор!
Котылгысыз килер Хак Сүз булып,
Кешелекле, гадел, безнең Чор!
Таш күтәрмә, башың күтәрсәң дә,
Тик, береккән кебек, селкенмә!
Аласы күп безнең бу дөньяда.
Бирәсе юк! Берни! Беркемгә!
Кан кирәкми, җан кирәкми безгә.
Илаһи Сүз кирәк, Хак Китап!
Ихлас дуслык, чын Гаделлек кирәк!
Тик шул гына безнең Хакыйкать...

**Тел**

Мәскәү түрәләре Казанга килеп, атаклы
төрек лицейларын тикшереп, ябып йөриләр.
*Вакытлы матбугаттан*

Иң яхшы дәүләт – безне үзебез белән идарә
итәргә өйрәтә торган дәүләт.
*Гёте*

Ах, зәмһәрир суык «урыс» кышы!
Тырмыйм, ертам ишек чыптасын.
Ябыштым да каттым телем белән,
Яладым да тимер тоткасын.
Чирле әнкәм өйдә үлеп ята.
Ә мин ача алмыйм ишекне.
Тел очымны тота салкын тимер...
Тынсыз елыйм.
Беркем ишетми.
Кычкырып та, ычкынып та булмый.
Дөньяның мин чүп бер баласы.
Бөтен телең бозга әйләнгәнче,
Әллә кисәк тартып аласы?..
Җәрәхәте телнең тирәнәя,
Күбрәк түзгән саен, селкенми.
Балачакта эләккәнем булды
Шул тозакка, салкын бер көнне.
Кем ябыша шулай кызык эзләп,
Бирелә дә кайчак коткыга.
Су агызып җылы чәйнектән тик,
Тотка коллыгыннан котыла.

Нигә әле искә төште соң бу?
Дөрес кенә булмый һәр адым...
Бүтән шундый хәтәр «тотка»ларны
Кайвакыт мин ялап карадым.
Ник яладың, димә.
Ахмак идем.
Кыйбласыз җан, денсез, шук идем.
Ятим идем, хәтта фәкыйрь идем,
Хөр күңелем белән тук идем.
Фәкыйрьлегем – дүрт як ятимлектән,
Хөр күңелем – дүрт як кыйбладан.
Ахмак башым, диңгез – тубыктан дип,

Ә Алланы юк дип уйлаган.
Айкап атты диңгез, давыл булып,
Алдымда тик кыя ташлары.
Ачы суы авызыма тулып
Тончыктыра, буа башлады.
Сискәндем дә күтәрелдем кинәт
«Улым! Үләм...» дигән тавыштан.
Кыйбла яктан – әнкәм ягыннан бу...
Тик телемә тотка ябышкан.
Тоташ бозга әйләнәм бит хәзер.
Соң, бу әллә әҗәл көнемме?
Бар хәлемне җыеп ыргылдым да,
Умырдым да алдым телемне.
Ишек ачык.
Мин атылып кердем.
Ә әнкәем инде җан бирә.
Сүзләрем күп.
Тик сөйләшеп булмый,
Авызыма тулып кан килә.

Мин аңладым: әгәр дошман илен
Бетерәсең килсә җимереп,
Аякларын түгел, кулларын да түгел,
Телен бәйлә икән иң элек.
Тел – тамыр ул.
Нәсел-кавемнәрнең
Кендекләре шуңа береккән.
Үз-үзләрен саклар өчен, алар
Телен саклый элек-электән.
Шуннан үсә яме күңелеңнең,
Шуннан үсә гаме җаныңның.
Тел биргәнгә Ходай, җиһанга без
Адәм заты итеп алындык.
Адәм затын бетерәсең килсә,
Телен бетер икән иң элек.
Ә аннан соң телсез адәм үзе
Илен таптар, ватып-җимереп.
Күрәсезме, күпме ятим калган,
Телсез калган апа-абыйлар,
Тотка түгел, телен өзгән кулны
Койрык болгый-болгый ялыйлар...
Ишек ачык.
Әнкәй үлеп ята.

Бәхилләшеп чыгыйк, булмаса.
Тәүбә кылган ихлас адәмнәргә
Ходай тагын бер кат юл ача.
Селкенергә, кычкырырга куркып,
Бозга катып барган көнеңме?
Алла хакы, әнкәң хакы өчен
Ал умырып тизрәк телеңне!
Без ятимнәр кебек барыбыз да,
Салкын тимер тотка ялаган.
Әнкәй үлеп ята.
Телебез юк.
Ә авыздан шаулап кан ага.
Селкенеп тә, ычкынып та булмый.
Без дә бит бу дөнья баласы!
Авыз тулы кан булганда, ничек
Адәм заты булып каласы?
Кузгалырмы кавем беркөн айнып,
«Улым! Үләм...» дигән тавыштан.
Вакыт – бикле.
Көннәр – кадакланган.
Телебезгә еллар ябышкан.
Хезмәт итә Вакыт залимнәргә,
Тарих – үзе ата ялганчы.
Адәм заты булып ничек калыйк,
Адәм көлкесенә калганчы?
Алла хакы өчен, әнкәң хакы өчен
Ал умырып тизрәк телеңне!
Акса аксын каның...
Адәм булып
Яшәп күрсәт калган көнеңне!
Тәүбә кылган ихлас бәндәләргә
Мәрхәмәтле Ходай юл ача.
Ишек ачык.
Әнкәй исән әле.
Бер селкенеп карыйк, булмаса,
Дүрт як ятим булсак, илсезлектән,
Күңел богаулары нәрсәдән?
Бар бит җаннар, билен-телен бирми,
Адәм заты булып яшәгән.
Киң шикелле иде безгә җиһан...
Иксез-чиксез дөнья тар икән.
Дүрт як кыйбла – Ирек түгел икән!
Диңгез – тирән, Алла бар икән!

**Арыслан һәм көчек**
Аю янында йокласаң, кискен хәрәкәтләр ясама...
*Никита Михалков. (Вак илләргә ишарә.)*

Ә алтынчы көнне арыслан үлде...
*ЛевТолстой. «Арыслан һәм көчек»*

Һәркем белә эчтәлеген бу әсәрнең,
Тик шөгыле башка хәзер күп яшьләрнең.
Бардыр укымаган кемдер. Сөйлим әле.
Мәгънәсе бит аның бик тә ишарәле.

Арысланның читлегенә, көлешепме,
Кара йөзләр ыргыталар бер көчекне.
Күзәтәләр: ерткыч хәзер тотып ашый,
Һич югында, йә ботарлап, буып ташлый.
Дер калтырап тора көчек бер почмакта,
Ә арыслан карый, исни, килеп ята.
Ә аннан соң, көтмәгәндә, ялап ала,
Әйтерсең лә көчек аның өчен бала!
Туйдыргандыр арысланны бикле бушлык
Һәм башлана гаҗәп сәер, якын дуслык.
Бергә ашау, бергә йоклау, бергә йөрү,
Ишетелә йә ырылдау, яисә өрү.
Ә көчекне алам дип кул күтәрүгә,
Арысланың җаның алыр бер бәрүдә.
Бары да шат – менә дуслык, менә үрнәк!
Дус яшәгез барыгыз да шуннан күрмәк!

Ә беркөнне бу читлеккә килә бәла –
Бер сәбәпсез чирләп китеп, көчек үлә...
Арысланга кара кайгы, чиксез хәсрәт,
Үле көчекне дә бирми – чыга чәчрәп.
Атна буена йокламый, саклый һаман,
Ашамый да, эчми дә ул, эше яман.
Ялгыз калган аңлы җан иясе сыман,
Үзе дә җан бирә кара кайгысыннан.

Ышанмасаң, кайда димә асыл фикер.
Булмаслыгын күрсәтерлек дәлил китер.
Бар икенче ягы эшнең, күләгәдә...
Аңа инде җавап тапмас күрәзә дә.
Ничек әрәм булды икән мескен көчек?

Ни җитмәде гомеркәен саклар өчен?
Әллә үзе кискен селкенгәнме дисәк,
Арыслан да шулчак борылганмы кисәк?
Сизмәгәндер ул үзе дә йә саташып,
Йә кычыткан берәр бетле җирен кашып.
Беркем белми, нәрсә булды, ничек, нигә...
Көчек бит ул. Күп кирәкме ул нәнигә.
Кысылгандыр, сытылгандыр берәр җире,
Арысланда чукрак колак, калын тире.
Сизмәгәндер. Йоклагандыр ашып чиктән.
Шулай үзен дә үлемгә хөкем иткән.

Кагыйдә бар, асыл затлар өчен генә,
Гаепсез дә, гөнаһсыз да – кем селкенә.
Ләкин әгәр гәүдәң олы икән артык,
Сак йокларга кирәк, сак, селкенми ятып.
Юкса кемнедер сытарсың бик кирәкле,
Синең дуслыкны сыйдырган зур йөрәкле.
Ялгыз калган аңлы җан иясе сыман,
Үзең дә китәрсең шуның кайгысыннан.

Беркайчан да аңламас тик аю моны
Һәм арыслан булмас, булса да ул олы.

Менә шундый, иптәш, бездә дуслык хәле,
Мәсьәләнең шул ягы да бар бит әле...

**Җан юлы**

Рас килде – фаразлар хаклыгын кара син,
Ачып хәтернең тоз сибәр ярасын.
Кан һәм сөякләр түшәлгән бу кала
Котырган этләр кулына каласы...
*Мөхәммәт Мирза*

Төш тә түгел, өн дә түгел,
Сәер дөнья уңда, сулда.
Аң өлешем аңламаган
Җан өлешем һаман юлда.
Яу кырыннан чыгып килеш,
Ләкин орыш истә түгел.
Вакытны да белеп булмый,
Иртә түгел, кич тә түгел.
Ярам да юк, тәнем бөтен,
Тик башымда контузия.
Җаным исән – аңны эзләп,
Зиһен ватыкларын җыя.
Соры кырда соры юл бар,
Читендә юк яшел үлән.
Сәерлеген юлның аңлыйм,
Ләкин атлавымны беләм.
Соры дөнья тирә-якта
Тынып калган нидер көтеп.
Әллә кырылып беткәннәр,
Йөрми кеше, өрми эте.

Күз алдыма килә кайчак
Буш авыллар шомлы, сәер,
Буш йөрәкле вак шәүләләр
Сузып уза миңа хәер.
Таушалгандыр кыяфәтем,
Мескенчәдер эчке хәлем.
Кыйналсам да, талансам да,
Мин теләнче түгел әле.
Аңым белә, җаным сизә –
Алда мине көткән җир бар.
Калып салып, хәлне алып,
Җанны гарип иткән чир бар.
Ерак түгел мин туган җир,
Барам, як-ягыма карап.
Табылыр ул. Китик әле

Яу кырыннан ераккарак.
Хәтер очын чир югалткан.
Бер генә юл минем алда.
Чит дөнья бу, чүп дөнья бу,
Туктап булмый монда ялга.
Аң уяныр. Еллар буйлап,
Яшен булып узар хәбәр.
Күз алдыма килер күптән
Хәтеремнән чыккан хәлләр.
Кузгалыр да беркөн, аңлап
Үзенең кем икәнлеген,
Кушылып җан белән, эзләр
Юл читендә калган йөген.

Көз дә түгел, яз да түгел.
Бире дә юк, ары да юк.
Кояшы да, болыты да,
Яңгыры да, кары да юк.
Төссез дөнья, тып-тын дөнья,
Күрми күз, ишетми колак.
Үтерелгән Вакыт монда
Кузгалалмый ята елап.
Үтерелгән Вакыт буйлап,
Нидер эзләп, җан ашкына.
Адаштым да кебек инде,
Әллә саташа баш кына?
Тәгәрмәчтә тиен чаба,
Тик беркая бара алмый.
Ә бит Вакыт үлгән җирдә
Бернинди дә ара калмый.

Бу чит Вакыт, бу чик Вакыт...
Кабаланып һәм тез чүгеп,
Зиһен ватыкларын җыйдым,
Ләкин инде бу мин түгел.
Үзем һаман атлыйм кебек.
Нинди җирләр тарта мине?
Барысы да күптән беткән,
Мин дә мин түгел бит инде.
Үтерсә дә Мизгел аңны,
Үтелсә дә соңгы ара,
Төштә, өндә, көн дә, төн дә,
Үлемсез җан кая бара?

Мәңге кайтып җитмәм кебек,
Сәер дөнья уңда, сулда.
Ни эзли бу тынгысыз җан,
Туктый алмый һаман юлда?

Ераккарак киткән саен,
Озаккарак бара ялган.
Без туган җир, Вакыт белән,
Яу кырында үлеп калган.
Тәгәрмәчтә җан әйләнә,
Тик беркая бара алмый.
Вакыт үлгән җирдә инде
Шуннан башка чара калмый.
Чит дөнья бу, чүп дөнья бу,
Без түгел бу инде күптән.
Чит Вакыт бу, чик Вакыт бу.
Гомер бездән башка үткән...
Таушалган өс-баш, кыяфәт,
Йөз-битебез мескен, сәер.
Зиһен ваткан юлбасарлар
Суза хәзер безгә хәер.
Алар тере. Алар таза.
Бездә генә контузия.
Мәетләрне тентеп алар
Байлык җыя... Милек җыя...
Аң өлешем аңламаган,
Җан өлешем әле юлда.
Соры дөнья... Юлбасарлар...
Уңда, сулда. Уңда, сулда...

**Террор**
*(Берәү сөйләде)*

Кайбер кеше үтерүчеләр аларны үтерүне тыя торган закон булганга күрә генә исән яшиләр...
*Эдгар Уотсон Хови, Америка язучысы*

Ул да кемнеңдер баласы...
*Равил Фәйзуллин*

Таза егет – мыек асты
Яңа гына кипкән әле –
Сабый кызы күз алдында
Бер фәкыйрьне типкәләде.
Кызык өчен, тик торганда,
Кыйнады ул бер юашны.
Йә китереп суга берне,
Йә яңадан тибә башлый.
Яшь агызып, бер ялгызы
Карап тора мескен сабый –
Ник әтисен шулай итә
Бу әшәке, сәер абый?
Кысылырлык гайрәтем юк,
Булышырлык юк бер бәндә.
Шулай инде, беркем булмый,
Син дигәндә, мин дигәндә.
Көннәр үтте. Тынгы бирми
Шул сабыйның күз яшьләре.
Булышасым килгән иде.
Бик теләдем... Тик дәшмәдем.
Мәгънәсе юк, файдасы юк
Бездән, минем ише юк-бар.
Бәреп егар да җенләнеп,
Икеләтә каты тукмар.
Ә сабыйның елаганы
Күз алдымнан китми һаман.
Җәлләп шуны, оныталмый,
Ахыр чиккә җиттем тәмам.
Торган җирен, йөргән җирен
Белә идем бәдбәхетнең.
Төн йокламый исәп кордым,
Бер почмакка посып көттем.
Һәм, ниһаять, бу хәшәрәт

Кайтып килә алпан-тилпән.
Бераз салмыш... Һәрхәлдә дә,
Чайкалмыйдыр инде җилдән.
Кулда күсәк, җанда исәп,
Сабый бала күз алдымда,
Ордым берне арт ягыннан
Кинәт кенә кузгалдым да.
Туктады да катып калды,
Чайкалып бер мизгел генә.
Җир тетрәтеп, әзмәвердәй
Авып төште юл читенә.
Сөенмәдем. Үкенмәдем.
Уйламадым артын, алдын.
Йокла сабый, оныт барсын –
Әткәң өчен мин үч алдым!

Күрәм кайчак «әзмәвер»не,
Хастаханә – йөргән юлы.
Вөждан кайчак бимазалый –
Ул да кемнеңдер бит улы.
Минем дә бит бар әнкәем...
Тик юаныч шуннан табам –
Сабый кызның елаганы
Күз алдымда тора һаман.
Беләм, аңлыйм. Арттан сугу –
Сөйләмәслек кабахәт эш.
Нишләргә соң? Чара юк бит!
Адым саен золым, фәхеш...
Аң-белемем күп түгелдер,
Берәү әйтер: утыр да түз!
Сез акыллы... Минем өчен
Башка чара юк дигән сүз.
Һәркемнең дә әнкәсе бар,
Һәркем кемнеңдер бит улы.
Үз ишенә иң беренче
Күтәрелә кемнең кулы?
Дөрес! Кизәнә көчлерәк,
Шуннан башлана барысы.
Булмый андыйлар көченә
Шул ук юл белән карышып.
Арттан сугу куркак эштер,
Ләкин аның сәбәбе бар.
Мәрхәмәтсез ерткычларның

Җавап тотар сәгате бар.

Ил башлыгы зур түрәләр,
«Террор!» – дисез. «Террор!» – дисез...
Мин килешәм – кабахәт эш.
Ник сәбәбен тикшермисез?
Әллә шуңамы, үзегез,
Держава, милек сагында,
Туганнарын үтерәсез
Сабыйлары күз алдында.
Мин надандыр... Кемдер әйтер:
Синең акыл эше түгел...
Бомба ташлап йорт яндырган –
Кеше түгел! Кеше түгел!
Һәркемнең дә әнкәсе бар,
Һәркем кемнеңдер бит улы!
Мин надандыр, аңлый алмыйм –
Шулмы Хак Тәгалә юлы?

Сөенмим дә, үкенмим дә...
Сәбәбен мин үзем беләм.
Ходай каршына барырга,
Җавабым да үзем белән.

**Җыр**
Хезмәтеңә лаек соклануны ничек күрсәтергә,
болытларны туктатырлык итеп...
*Синь Цицзи (Кытай, XII гасыр)*

Чишмәләр дә акмый тыңлады...
*«Рамай». (Татар халык җыры)*

Ишеттем мин кичә, чын безнеңчә,
Син өздереп гармун уйнадың.
Нинди моңнар йөртте, кардәш дустым,
Эшләп каткан тупас кулларың.
Башка килә төрле-төрле уйлар...
Әллә нинди моңлы, зарлы көй:
«Хафизәләм иркәм», «Ал Зәйнәбем»,
«Кара урман», «Рәйхан», «Әллүки».
Син уйнадың кичә. Мин уйладым
Яшь гомерем ничек узганын.
Чәчәкләргә кунды олы юлның
Без күтәргән кара тузаны.
Бик еракта идек әле без, әй,
Бер алманы бишкә бүләек.
Донбассларда күмер кискән чакта,
Туган илне сагынып үләек.
Җитмеш чакрым ара үтеп килдек,
Оренбурдан мамык шәл алып.
Ак калфакның табылган чагы ла,
Туганнарның сагынган чагы.
Бер күрешер өчен килдек без, әй,
Җитмеш чакрым якын җир түгел.
Кара да гынай урман, караңгы төн,
Моңлы көй уйнадың син бүген.
Һаваларда йолдыз, суда кондыз,
Газизәкәй, балдыз, елама.
Бик ерактан туганнарың килгән,
Син берүзең түгел дөньяда.
Әйдә барыйк сахраларга бергә,
Гөлләр араларына, кардәшләр.
Әдрән диңгез аръягыннан хәтта
Сагынганнар килми калмаслар.
Безнең нәсел бик еракта калган,
Катлам саен аның катлавы.
Аргы яктан тагын берәү килә,

Хафизәләм иркәм атлавы.
Гөлләр кебек сездәй матурларның
Тамырлары бер шул, Зәйнәбем.
Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем, бәгърем,
Рәхәт үтсен иде җәйләрең.
Фирдәвескәй, кара күзкәй, җаным,
Ай туганда әллә тудыңмы?
Кош тоткандай булам, ялгыш кына
Кулларыма алсам кулыңны.
Әллә кара карлыгачмы, әллә
Сары сандугачмы әнкәсе?
Башын борып бер караса миңа,
Чыңлап ала көмеш тәңкәсе.
Шәмдәлләрдә генә утлар яна,
Җиткән кыз да булды Гөлҗамал.
Кулларыннан киндер җеп үрелә,
Күзләреннән тамчы гөл тама.

Чиксез шулай дәвам итәр идем,
Ләззәтләнеп, исем-җырларны.
Мәңгелеккә үтеп бара алар,
Еллар үтеп, кичеп чорларны.
Нинди җыр бу диеп сорамагыз,
Күңел тулы сагыш булганда.
Бик ерактан бер күрергә килгән,
Алар безнең кардәш-туганнар.

Моңланып, Ай нурларында кичә
Син өздереп гармун уйнадың.
Нинди тылсым йөртте, әйтче, туган,
Кытыршы бу тупас кулларың?
Башка килә төрле-төрле уйлар,
Әллә нинди моңлы, зарлы көй.
«Хафизәләм-иркәм», «Ал Зәйнәбем»,
«Кара урман», «Рәйхан», «Әллүки».
Бик еракта без яшәдек шулай,
Бер алманы бишкә бүләек.
Кайда гына тир түкмәдек без, әй,
Туган якны сагынып үләек.
Ак калфакның табылган чагы ла,
Туганнарның сагынган чагы.
Саубуллашып, бәхилләшеп калыйк,
Күрешмәбез, ахры, без тагын.

Чәчәкләрне күмгән олы юлның
Без күтәргән кара тузаны.
Син уйнадың кичә. Мин уйладым
Чит якларда гомер узганын.
Чыңлаган шул гармун телләредәй,
Бер-бер артлы үтте елларым.
Яңрап үткән еллар авазыннан
Түзмәдем мин, үксеп еладым.
Табылмаган дөнья малы өчен
Каңгырыйдыр егет башлары.
Ил язмышы безне туган җирдән,
Өмет бирми, алып ташлады.
Нинди җыр бу диеп сорамагыз,
Күз яшьләре тынны буганда.
Бәхилләшү җыры шушы инде,
Сау булыгыз, кардәш-туганнар.
Идел бит ул, дускай, Идел бит ул,
Ерак бит ул, тирән, киң бит ул.
Татар күргән михнәт дәрьясына,
Күз яшенә аның тиң бит ул.
Әй, мөкатдәс, моңлы тальян гармун,
Уйнадың син бик аз. Нишләдең?
Үксеп-үксеп елый еракларда
Аерылган кардәш-ишләрең.
Озата барма, дускай, озата барма,
Адаштырмас, бәлки, олы юл.
Без китәбез инде. Сез каласыз.
Татар җыры – матәм җыры ул.
Шәмдәлләрдә генә утлар яна,
Галиябану, Рәйхан, Гөлҗамал,
Мин сагындым сезне... Күзләремнән
Тамчы тама... Сагыш, моң тама...

**Тәмле Чишмә**
*Расим абый Баһавиевка*

Җырлаган булып елау...
*Нәҗибә Сафина*

Урман чите. Тәмле Чишмә. Кечкенә күл.
Баганадан ут кермәгән агач өйдә,
Керосинлы иске лампа яктысында
Җырладык без онытылып барган көйгә.

Табының да искитмәле, Расим абый,
Тик мул табын инде никтер сөендерми.
Күңелләрне телеп-телеп, җанга-тәнгә
Гармуныңнан ташып чыккан көең керде.

Көйсез-моңсыз мул табыннар әллә бозды
Туганнарны, җиребездән таралышкан.
Дус-ишләрен, авылдашын санга сукмый,
Күпләр хәләл-хәрәм малына ябышкан.

Кем начар ди бу макталган тырышлыкны?
Мал табуда, йорт салуда оста татар!
Тик бу юлда, кирәк булса, күп уйламый,
Милләтен дә, туганын да уптым сатар...

Туганнар без, газиз авылдашлар, дуслар.
Сирәк-мирәк бер табынга җыелсак та,
Бер-беребезгә чиксез ерак, чит инде без,
Таянырлык түгел инде кыен чакта.

Әллә нигә бер моңланып алабыз да
Тиз кайтабыз капма-каршы, кире хәлгә.
Әйтерсең лә бик сусаган чакта тик бер
Тамчы гына тама кипкән иреннәргә.

Аңлыйбыз без үзебез дә. Тик беләбез –
Төн узуга барысы да алышына.
Замананың денсез гаме, моңсыз яме
Йота безне болганчык көн агышына.

Аңлыйбыз без. Тик барыбер ерагая
Безне кардәш-туган иткән юл-арабыз.

Чыбыркыга карышмаган көтү кебек,
Чит агымга керәбез дә югалабыз.

Бүген әле Расим абый гармун уйный,
Хәтер белән Вакыт әле тарткалаша.
Яшь аргамак кебек Вакыт алга чаба,
Хәтер аксый гүя хәлсез карт алаша.

Көннәр белән Хәтер тарткалашкан чакта,
Вакыт боза безне, уза-уза җиңә.
Җаныбызга бер могҗиза булып керә
Расим абый саклап килгән бу хәзинә.

Ә ул уйный, уйный белә нәкъ безнеңчә.
Бу мизгелдә барыбыз да башка, бүтән.
Бу мизгелләр тиңсез бәхет, чиксез рәхәт,
Бу мизгелгә гомер сыя күптән үткән...

Рәнҗетсә дә кайберәүләр сабый чакта,
Миңа авылдашлар һаман туган кебек.
Кайчак уйлыйм, ничек ямьле, ничек кызык,
Ничек... авыр булган икән тормыш элек!

Керосинлы лампаларның пыяласын
Сөртә иде бит әниләр көн дә кичен.
Тойдым кебек монда бүген шул көннәрнең
Ерак калган ямен, гамен, тәмен, исен.

...Урман чите. Тәмле Чишмә. Кечкенә күл.
Таш юллардан ерак торган агач өйдә,
Дус-туганнар булып бүген кыланабыз,
Җырлаган булып елыйбыз иске көйгә...

**Соңгы сүз**

Җыгылдык без икөч чакрым да китми, –
Җегетләр! Бездә көч юк, – ахры, булмас!
*Габдулла Тукай*

Ходай явызлыкка түзә, тик озакка түгел.
*Сервантес*

Ике генә чакрым үткән идек,
Туктап калдык сүнеп, ватылып.
Бер кабынып алды өмет уты,
Бетте балкыш, бетте яктылык.
Бушап калды без шаулаган юл да,
Туктаттылар, юлны яптылар.
Ут күренми алда, сүнде дөнья,
Каушап калдык куркып, аптырап.
Дөм караңгы кара еллар килде,
Кабынырмы өмет яңадан?
Кемдер китеп барды, ә кемнеңдер
Авызыннан әле кан ага.
Мәкерле бу тыгыз камалышта
Кем отылып калды, кем отып.
Кемдер дөнья куа, байлык җыя,
Барысын да күптән онытып.
Хәлебез бар... Нигә туктадык соң?
Нинди чир бу? Нинди өянәк?
Нинди сүзләр белән бизәсәң дә,
Исеме бит аның – хыянәт.
Узып бара еллар безнең яннан.
Утырабыз нишләп, ни карап?
Узгынчылар көлеп уза кебек,
Утырганның йөзе битараф.
Ниләр уйлап баш ватабыз әле?
Сибелгәнбез әллә кайларга.
Тормыш бара. Сау-сәламәт һәркем.
Нәрсә кирәк? Нәрсә сайларга?
Безнең эше тынмасларга тиздән,
Яңа буын – денсез исәрләр,
Чигә тирәсенә бармак төртеп,
Сәерсенеп карап китәрләр.
Тик күрсәтер Тарих, тукталуда
Төзәтмәслек ялгыш, хата бар.

Арыганга монда су бирмиләр,
Туктаганны монда аталар.
Бу тукталыш кына түгел инде,
Бу – чигенеш, үлеш, тукмалыш.
Артта калган бер ялгышка хәзер
Куып җитәр безне мең сагыш.
Ә барыбер кемдер хәрәкәттә,
Атламакчы була ничек тә.
Юл читендә шаулый кыргый базар,
Кем аларны күрә, ишетә?
Базар уртасында шаулы сәхнә,
Ә сәхнәдә пәри туедыр.
Килер бер көн, сәхнә урынына
Азатлыкка һәйкәл куелыр.
Пәри туе – таң атканчы гына,
Ә әлегә шундый тамаша –
Туган белән туган, иптәш белән иптәш,
Татар белән татар талаша.
Вакыт бит ул бик мәкерле нәрсә,
Багучысы җирдә юк аның.
Барыбер бер бетә империя,
Күтәрелә милләт уянып.
Сакта торсын милләт асыллары,
Саклау юлын һаман уйласын –
Мөмкин булган кадәр тәүфыйк-моңын,
Мөмкин булган кадәр кыйбласын.
Йоклый милләт, аю оясында –
Селкенергә артык ярамый.
Туктаттылар безне. Үтеп калдык
Ике генә чакрым араны.
Ватылды җан, сүнде күңел уты,
Ләкин кылыч әле сынмады.
Тутыкмасын, кайрап-кайрап алыйк,
Юкса юккамы ул чыңлады.
Онытылыр диеп уйладылар.
Оныттырмыйк, чүп сүз сөйләмик.
Чалгы кайрый белгән тырыш халык
Кылычын да кайрый белә бит.
Көнаралаш типкәлиләр безне
Зур түрәләр әллә кайдагы.
Уяу булыйк. Ахры, күптән инде
Көтә безне Ирек мәйданы.

**Зәйтүнә мәхәббәте**

Зәйтүнә
Габдулла
Ил
Тарих

**1. Зәйтүнә**

Без Чистайга китәчәгебезне, бары күрешү өчен генә килүебезне әйткәч, Тукай: «Бик кызганыч», – диде.

*Зәйтүнә Мәүлүдова*

Очты дөнья читлегеннән, тарсынып күңлем кошы.
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.
*Габдулла Тукай*

Кара төстә дөнья,
Кара төстә һава,
Барлык тирә-ягым кап-кара.
Җаным сизә, тоя,
Мәңгелеккә каршы
Ак пароход суда эз яра.
Артта Казан балкый,
Ләкин миңа түгел,
Ерагая һаман тик ара.
Эз югала суда,
Күздә хәсрәт төсе –
Ул һаман да кара... кап-кара...
Юкса җәй бит әле,
Якты Кояш чагы.
Унбиш яшьлек мин яшь кыз бала.
Күңелемнең хәле –
Артта Казан түгел,
Бик әйтәсем килгән сүз кала.
Борылам да карыйм,
Борылам да карыйм,
Казан инде күздән югала.
Өзгәләнә күңел,
Кыска гомер булып,
Артта моңлы, ярсу җыр кала.
Ходай язган язмыш,
Аны узып булмый,
Күз алдымда дөнья чайкала.
Ишетелә тавыш,
Әллә киләчәктән –
Артта тарих кала, чор кала.
Киләчәкне сизәм,
Тик аңламыйм әле.
Унбиш яшьтә бик яшь кыз бала.

Авыртса да түзәм,
Телеп-телеп, уеп,
Йөрәгемдә тирән эз кала.
Гомер башы әле,
Барысы да алда,
Тик узарлык түгел бу ара.
Күңелемнең хәле –
Бу эз генә түгел,
Төзәлмәслек мәңгелек яра.
Мин көтәрмен хәбәр,
Юкка өметләнеп.
Мин кыюсыз. Мин бит кыз бала.
Тормыш җәе кадәр,
Артта кыска гомер –
Яшәлмәгән алтын көз кала.
Әле кыз бала мин,
Ул бит егет кеше,
Нигә соңгы өмет югала?
Үтмәслек арамы?
Син дәшмисең һаман...
Артта упкын кала, чор кала.
Еллар булса исәп,
Егермедән узган
Мәхәббәтле бер яшь егет бит.
Өзгәләнгән үзәк,
Телгәләнгән йөрәк,
Җитмеш яшьтән узган кебек бит.
Башындагы гамьне,
Җанындагы хәлне
Йөрәгенә якын ул ала.
Сүнеп барган шәмне,
Ташып торган ямьне
Өзеп, артта кара су кала.
Дөрес юлдыр, дөрес,
Шуңа да ул язмыш,
Язмаганы аның югала.
Миңа минем өлеш,
Ә калганы ялгыш,
Ләкин артта моңлы җыр кала.
Ходай шулай язган,
Әллә эсседәнме,
Күз алдымда дөнья чайкала.

Шундый өлеш калган

Безгә бу еллардан,
Артта ярсу, моңлы җыр кала.
Борылам да карыйм,
Борылам да карыйм,
Артта инде Казан югала.
Тик шул моңым-зарым:
Артта Казан түгел,
Ишетәсем килгән сүз кала.
Барысы да алда,
Гомер башы гына,
Тик узарлык түгел бу ара.
Гасырларны ялгап,
Йөрәкләрне уеп,
Артта кала мәңгелек яра.
Ямьле көй ишетәм
Җаным-тәнем белән,
Артта моңлы, ярсу җыр кала.
Китәм, ләкин көтәм
Өметсезлек белән,
Артта Тарих кала, Чор кала.

## 2. Габдулла

Тукай пристаньга безне озатырга килергә вәгъдә бирсә дә, без аны яңадан күрә алмадык.

*Зәйтүнә Мәүлүдова*

И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен – айрылабыз, ахрысы!
*Габдулла Тукай*

Синең әле чәчәк атасың бар,
Син әле тик тулган бер бөре.
Мин сүнәрмен.
Тынымны чир йота.
Чарасы юк, каһәр төшкере.
Бердәнберем минем, тулган бөрем,
Үпкәләмә.
Көтмә.
Елама.
Ник качасың диеп газаплама,
Ник килмисең диеп сорама.
Әйтер идем, күзләреңә багып,
Сине генә, бәгърем, сөям дип.
Тыштан гына салкын, битараф мин,
Ә эчемнән янам-көям бит.
Сөяр идем, кулларыңнан тотып,
Гомерләрнең әле бит башы.
Синең әле чәчәк атасың бар,
Мине эчтән яман чир ашый.
Юләр бала-чага булыр идем,
Күңелеңдә өмет уятсам.
Беркемем юк,
Бернәрсәм юк минем.
Өем дә юк,
Хәтта юк акчам.
Йортны салып була,
Акча табып була.
Тормышның бит әле тик башы.
Ләкин вакыт җитмәс.
Мин сүнәрмен.
Эчтән мине яман чир ашый.
Моңсуланма бер дә.
Тормыш бара бит ул.

Күзләреңдә өмет нуры бар.

Бормалы бу яшьлек юлларыңны
Язмыш беркөн үзе турылар.
Аяк астың якты булсын диеп,
Баш өстеңнән агар яктылык.
Курыкмыйча атла.
Бүтән абынмассың,
Бүгенгедәй, миңа атылып.
Син эзләмә мине.
Сакчы фәрештәсен
Бу дөньяда күрми беркем дә.
Юлларыңа якты моңнар салган,
Мин булырмын башың өстендә.
Мин сүнәрмен тиздән күзләремдә
Синнән балкып калган ямь белән.
Син китәсең бүген.
Мин сынармын.
Аерылышабыз бүген мәңгегә.
Кичер мине.
Озатырга кил дип,
Булган иде синнән үтенеч.
Килалмадым.
Юк, килмәдем юри,
Шунсы гына бераз үкенеч.
Һәр күрешү якынайта бит ул,
Һәр күрешү – тик буш мәшәкать.
Тамырында калсын газаплары,
Бөресендә калсын мәхәббәт.
Кичер мине.
Бик киләсем килде.
Күзләреңә килде багасым.
Чишеләсе түгел серләрнең бу
Үтеләсе түгел арасы.
Син китәсең.
Мин сүнәрмен тиздән.
Аерылабыз бүген гомергә.
Сүнсен өмет.
Идел яры буйлап
Мин түгел ул елап йөгергән.
Мин сынармын тиздән.
Син яшисе.
Сүнеп калсын өмет очкыны.

Сүндерүе җиңел түгел аны,
Дөрләп китсә, кулдан ычкынып.

Болай да бит инде сиздермичә,
Күрсәтмичә янам-көям мин.
Зәйтүнәкәй, бәгърем, Мәҗнүн кебек,
Сине генә бары сөям мин.
Эх, булмады инде.
Эчемдә чир.
Чарасы юк, каһәр төшкере.
Синең әле чәчәк атасың бар,
Син әле тик тулган бер бөре.
Ник качасың диеп газаплама,
Ник килмисең диеп сорама.
Бердәнберем минем, тулган бөрем,
Үпкәләмә, көтмә, елама.
Мин сүнәрмен тиздән.
Син китәсең.
Аерылабыз бүген мәңгегә.
Тик, сүнсәм дә, китәм күзләремдә
Синнән балкып калган ямь белән.

## 3. Ил

Мин кабер янында Коръән укып, бик озак елап утырдым.
*Зәйтүнә Мәүлүдова*

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы.
*Габдулла Тукай*

Кич... Зират... Ямьсез... Караңгы...
Агачлары чайкала.
Бер кабердә елый-елый
Коръән укый кыз бала.
Аз булганмы елаучылар
Бу кабернең читендә?
Бу елаган кыз баланың
Ил сагышы битендә.
Бу кыз бала биш ел йөрткән
Йөрәгендә истәлек,
Китапларга сыймас сүзләр
Озын-озын киштәлек.
Җир кайгысы, Ил кайгысы
Аның моңлы йөзендә, –
Бөек сагыш, мәңгелек сер
Кыска гомер эзендә.
Агачларны сыгып җиргә,
Аның белән җил елый.
Җил түгел ул, җимерелгән,
Бетерелгән Ил елый.
Бу кабердә үтерелгән
Илнең җаны, җәсәде.
Казансуда кан болгатып,
Тәкъдир сурәт ясады.
Бетте халык, калды сурәт,
Кояш баткан төс кебек.
Югалды ил, көймәләрдән
Суда калган эз кебек.
Җан сорады беркөн сурәт –
Күмелмәгән шәһитләр,
Юл табалмый Мәңгелеккә,
Мәхрүм тыныч бәхеттән.
Мең тискәре язмышка да
Килеп чыга бер уңай –

Үле милләт җаны булып,
Дөньяга килде Тукай.
Очкын кебек кыска гомер,
Хәнҗәрдәй үткен каләм –
Үлеп барган халык өчен,
Хушлашу, соңгы сәлам.
Уйнап-көлеп, эшем кырып
Гомер итәргә иде.
Ләкин язмыш аңа күптән
Әҗәл җибәргән инде.
Без инде милләт түгелдер,
Бу – милләтнең газабы.
Зур казанда җан болгатып,
Патша сурәт ясады.
Тәнең генә җитми, ахры,
Көн дә җан сорый сурәт.
Илең генә җитми аңа,
Тагын халкың да кирәк.
Күрмибез генә без аны –
Көн саен бара сугыш.
Сурәткә җан керә, ләкин
Өзелә безнең сулыш.
Кич... Караңгы... Ямьсез... Зират...
Агачлары чайкала.
Бер кырыйда елый-елый
Коръән укый кыз бала.
Агачларны сыгып җиргә,
Аның белән җил елый.
Җил түгел ул, җимерелгән,
Бетерелгән Ил елый.
Бу кабердә үтерелгән
Илнең җаны, газабы.
Патша бездән денсез, гамьсез,
Ямьсез сурәт ясады.
Китапларга сыймас җәбер,
Озын-озын киштәлек.
Онытылган, югалтылган
Һәм сатылган истәлек.
«Көзге төн. Мин йоклый алмыйм.
Тәрәзәдә җил елый.

Җил – хәбәр ул». Җан табалмый,
Үтерелгән Ил елый.

**4. Тарих**

Трамвайның ачык тәрәзәсеннән берәү безгә баш иде, ул – Тукаев иде.
*Зәйтүнә Мәүлүдова*

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә:
Барсы корган, бер генә юк җанлысы, яфраклысы.
*Габдулла Тукай*

Борылам да карыйм –
Ничә еллар инде
Коръән укый елап кыз бала.
Алдыбызда кабер,
Безне Язмыш җиңде,
Әллә нинди уйлар кузгала.
Борылам да карыйм –
Анда кара элпә,
Төтен ерып килгән көннәр ич.
Артта Тукай, Җәлил,
Нәкый, Бакый, Зөлфәт...
Дәшми карап тора Мөдәррис.
Кире кайтып булмый,
Юл бозылган инде.
Тик бер генә алда башкала.
Кабиләне буып,
Безне Вакыт җиңде
Һәм гаме юк аның башкада.
Җибәрәләр төтен,
Ачыттырып күзне,
Күрмәсеннәр диеп үткәнне.
Без бит мондый түгел,
Бу басымга түзми,
Мескенлеккә төштек күптәнме?
Хәреф бирмәделәр,
Мәктәпсез дә калдык,
Адым саен калка киртәләр.
Аңсыз көтү кебек
Без ваемсыз халык,
Ә бит безгә аяк сөртәләр!
Бата-калка көн дә
Тончыгабыз инде
Вакыт шаулап аккан елгада.
Борылам да карыйм –

Безне Тарих җиңде,
Артта Халык кала, Ил кала!
Без – җиңелгән милләт.
Тырыш, ләкин гамьсез.
Бу – нәтиҗә түгел, ә сәбәп.
Чишмәләр дә кибә,
Шешә суы тәмсез.
Артта – Бәхет, Ирек, Мәхәббәт.
Вәгазь – көчсез сабак.
Сүз куәтен белсәк,
Бер тетрәнү үзе мең дәрес.
Артта – Тукай, Җәлил,
Бакый, Нәкый, Зөлфәт,
Карап тора кебек Мөдәррис...
Ятып калганчы дип,
Кемдер кала атып,
Ә Газраил көн дә җан җыя.
Артта калыр шулай
Айдар да бервакыт,
Һәм югалыр беркөн Фәүзия.
Азатлыкка әйдәп,
Мәйдан тота белгән
Батулла да хәлсез тын ала.
Ул да китәр беркөн...
Күтәрелеп көлдән,
Казан урамында кем кала?
Чыгырыннан чыгып,
Бетеп түземлеге,
Зәки йөри анда сүгенеп.
Зәки дөрес сөйли.
Ләкин боза эшне,
Әйтеп кайчак кирәк түгелен.
Гамьсез өерләрен
Кемнәрнеңдер борчып,
Кемнәрнедер, бәлки, кузгатып,
Өер уртасында,
Шигыремне кочып,
Югалырмын мин дә бервакыт.
Тарих Хакыйкате
Югалырмы артта,
Белер-белмәс аны сөйләсәк?
Трамвайдан башын

Кагып безнең якка,
Үтеп китте безнең Киләчәк...
Җиргә ятып тыңлыйм –
Бу көйне кем өзде?
Аста моңсу, моңлы җыр ага.
Борылам да карыйм,
Язмыш җиңде безне,
Артта Тарих кала, Чор кала.
Яшел яфраклар да
Саргаялар инде.
Күзләрендә Илнең җәй сүнә.
Урамда көн шаулый,
Илне Вакыт җиңде.
Сау булыгыз, Тукай, Зәйтүнә!
Артта үле Дәүләт,
Язылмаган Тарих,
Мәңгелекнең дә бар үз яше.
Мәңгелек яшь Тукай –
Өзелгән көй зары,
Ә Зәйтүнә – Илнең күз яше.
Нигә кирәк тормыш,
Халкың үлсә әгәр,
Телсез-денсезләргә калса Ил?
Юк, кыз бала түгел,
Күптән, аңа кадәр
Елап яткан анда Газраил.
Айлар, еллар буйлап
Каерылып карыйм,
Һаман, һаман елый кыз бала.
Тәрәзәдән безгә
Башын гына кагып,
Китеп бара Тарих, югала.
Төн... Караңгы... Салкын...
Йоклый алмыйм һаман.
Илләр елый, җилгә кушылып.
Алар ярдәм сорый...
Килде шундый заман,
Бер елыйсы килә утырып.
Илләр зиратында,
Өер уртасында,
Мин кечкенә кеше – ни кылыйм?
Төн... Караңгы... Салкын...
Җиде Чор чатында,

Ни кылыйм соң диеп, мин елыйм...

**Меңнән бер өлеш**

Кол кирәкми, тол кирәкми, кыз кирәкми, – наз кирәк;
Тән кирәкми, кан кирәкми, сүз кирәкми, – саз кирәк.
*Нәҗип Думави*

Үз чираты белән көннәр уза,
Ким дә булмый язмыш, артык та.
Гомереңә үз вакытын биреп,
Мәхәббәт тә килә, картлык та.
Каерылып әгәр бер карасаң
Яшьлек дигән ерак болынга,
Солдатларның тигез рәте кебек,
Көннәр кала гомер юлында.
Үткән көннәр корган мылтыкларын
Йөрәгеңә төбәп торалар,
Бизәкләре белән төрле-төрле,
Ниятләре белән бер алар.
Мең атмаса, бер ата ул мылтык,
Бер ядрәсе тия барыбер.
Бүгенге көн – ничек үтсә шулай –
Йөрәгеңә килеп бәрелер.
Яшәү яме байлык гаме түгел,
Бәхет дибез, затлы тун кисәк.
Мәхәббәтнең тик бер генә көне
Мең көнеңә сала мең бизәк.
Хәрефләрен үбеп чыгар өчен,
Шул исем дә җитә меңнән бер.
Бар Хакыйкать шул Мәхәббәт кебек,
Ә калганы, белмим, кемнәндер.
Көлемсерәр кемдер. Гаеп түгел.
Чын күңелдән була ялгышу.
Өмете бар эзли, таба аны,
Өметсезләр өчен каргыш ул.
Өметсезне ул әйләнеп уза,
Өметлене куя чиратка.
Бар ул, бар ул синең Мәхәббәтең,
Ул бары тик әле еракта.

Өметеңне өзми яшә генә,
Очратырга аны теләсәң,
Бас чиратка, күр, еракта әнә
Фәрештәләр сөю өләшә.

Уянуга иртән, бер куаныч булып,
Күз алдыңа килсә гүзәл сын,
Килеп җиткән, димәк, синең Чират,
Калганына инде түзәрсең.
Өметлеләр, меңнәр арасыннан
Тигән сиңа меңнән бер өлеш,
Көтеп алган бәхет, тиңсез байлык,
Көтелмәгән кискен борылыш.
Берни күрми, белми йөрибез бит,
Күпме, азмы синең кебекләр?
Кеше җанын казып бер карасаң,
Күпме анда сагыш, өмет бар...

Көтмәгәндә түгел бу күрешү,
Шикләнәсең икән син әгәр,
«Очрак» диеп күпме тукысаң да,
Очраклыгы аның шулкадәр.
Бу дөньяда нәрсә очраклы соң?
Язган язмыштыр бу бүген дә.
Синең ерак, серле елмаюың
Көтеп ятты күңел түрендә.
Килеп җитте серне чишәр вакыт.
Гомеркәйләр узып бара бит.
Ләкин Җирдә үталмаслык ара
Синең белән минем ара бит.
Күпме язмыш, күпме ялгыш аша
Ничек үттек шушы араны?
Дистә еллардан соң бу күрешү
Очраклы хәл була аламы?
Борылыштан килеп чыктың беркөн,
Калган иде меңнән бер адым.
Очып килдең кебек, кочып алдың,
Үбеп алдың, уйлап тормадың.
Миңа таныш серле елмаюда
Барысы да якын, үз иде.
Бу – елмаю гына түгел,
«Барысына,
Риза! Риза!» дигән сүз иде.

Бу мизгелдә дөнья бетте кебек,
Икәү генә калдык Галәмдә.
Аерылдык Җирдән, ә кочакта
Бәхетем дә иде, бәлам дә.

Очулары чиксез бәхет, ләззәт,
Төшүләре Җиргә мең хәтәр.
Куанычы никадәрле булса,
Аянычы аның шулкадәр.
Гөнаһсыз да, никахсыз да идем,
Язык эш бит кискен борылыш.
Мең өлеше Иблис эше булса,
Ходайдан да бардыр бер өлеш.
Мизгелләре тиңсез, тик санаулы,
Ашыгыпмы шуңа йөгердең.
Мәхәббәт тә күтәралмый кайчак
Авыр йөген үткән гомернең.
Бер үк чир бу, сер бу, бер үк ләззәт,
Бер үк газап байга, ярлыга.
Ләззәтеннән күбрәк газап күрдем,
Йә Ходаем, кичер, ярлыка.
Әллә Иблис биргән әче алма,
Әллә Ходай биргән татлы төш,
Әллә дәвасы юк йөрәк чире,
Әллә җитмеш җиде катлы көч.
Әллә бүлмә, әллә дөнья күкри,
Яшен булып, тәнне яра ут,
Тыелгысыз хәлдә якынаеп,
Синең белән минем ара юк...

Без өйләнгәч, төннәр кыска иде,
Без картайгач, җәйләр кыскарды.
Сентябрьдә чыккан Кояш кебек,
Мин күзәтәм хәзер кызларны.
Сөю салып мизгелләре саен,
Без үтәсе калган араның,
Ышык җирдә, битең куеп торсаң,
Җылысы бар әле, бар аның.
Табалмыйча көткән сөйгәнеңне,
Юлда булсаң һаман син әгәр,
Никадәрле туңып, өшеп килсәң,
Җылысы да аның шулкадәр.
Эссе җәйдә, чиксез дала буйлап,
Арып-талып, сусап йөргәндә,
Су иң тәмле ризык икән, диеп
Әйтеп әйткән, ди, бит бер бәндә.

Без белмәгән серләр юк шикелле,

Ирештек тә тиздән оныттык.
Тик Мәхәббәт дигән серне генә
Кемдер чишәр дигән өмет юк.
Чишалмаслык сер иңдергән Ходай
Мәңгелек яз, дәвам хакына.
Гыйшык кергән күңел күбәләктәй,
Утка таба оча, талпына.
Җырлап оча кемдер ут тирәли,
Омтылышы аның бер генә.
Ярый көйсә канат очың гына,
Кемнәндер бит кала көл генә...

Кайчак күрми, белми үтәбез бит,
Тыныч кебек дуслар, танышлар.
Кеше җанын казып бер карасаң,
Анда күпме давыл, сагыш бар.
Көнкүрештә, чүп-чар мәшәкатьтә
Йоклый давыл тирән түбәндә.
Гыйшык уты бер кагылып үтсә,
Кузгала бит кайчак «түбәң» дә.
Кара көннәр килсә, кемнәрнеңдер,
Юк дигәндә, уты-шәме бар.
Бары тик иң бәхетленең генә
Мәхәббәте, яме, гаме бар.
Исәп-хисап, акыл заманында
Чүптәй йөри җилдә тәгәрәп
Исәпне дә, хисапны да белмәс,
Акылын да «җуйган» мәхәббәт.
Кадере юк инде аның күптән,
Кабере юк әле бүгенгә.
Кадере дә, кабере дә юкның
Күпме яме юкка түгелгән.
Бер текәлеп карыйк бу дөньяга –
Юкмы алда кискен борылыш?
Дөнья чүбе меңләп-меңләп йөри,
Мәхәббәт ул меңнән бер өлеш.
Мәшәкатен ерып бу тормышның,
Арып-талып эшләп йөргәндә,
Бик сагындым сөйгәнемне, диеп
Әйтеп әйткән, ди, бит бер бәндә...

Сөю салып мизгелләре саен
Юкка чыккан ике араның,

Аулак җирдә, битең биткә куйсаң,
Җылысы бар әле, бар аның...
Ни кылсак та тәүбә итә-итә,
Ахыры бер байга, ярлыга.
Мин бит синең меңнән бер өлешең,
Йә Ходаем, кичер, ярлыка!

Ахирәттән хәбәр китергәндәй,
Тәрәзәдән салкын көз өрә.
Агачларга кунган бәс шикелле,
Чәчләремә ап-ак төс керә.
Йә, Мәхәббәт, картлыгыма кадәр
Озатып куй мине, өшетмә.
Бөек ләззәтеңә күтәрелик
Тирән серләреңә төшик тә.
Китәсе бар. Еллар алга куа,
Күңелләр яшь әле дисәк тә.
Син ашыкма, син кал әле бераз,
Көннәрең бар әле исәптә.
Еллар аямый шул беркемне дә,
Син дә беркөн юлга чыгарсың?
Яшьлегеңне Вакыт ваткан чакта,
Бәгырькәем, ничек чыдарсың.
Еллар уза. Картлык дигән фасыл
Сылу сыннар өчен бик хәтәр.
Гүзәллегең никадәрле булса,
Аянычы аның шулкадәр.
Син, билгеле, карышырсың инде,
Килеп җиткәч аның чигенә,
Керфек-кашларыңа сөрмә тартып,
Иннек-кершән сөртеп битеңә.
Ләкин күзләр, Кояш баткан кебек,
Төссезләнә, сүнә барырлар.
Җыерчыклар, тәнең телеп-телеп,
Буй-сыныңны меңгә ярырлар.
Көй-авазлар инде ишетелмәс,
Якты төсләр инде күренмәс,
Тулып пешкән татлы җимешләргә
Тын күңелләр инде үрелмәс.
Истәлекләр белән күңел яшәр,
Тән онытыр ерак наз тәмен.

Тын көнләшү, өметсезлек белән
Күзәтербез шаулы яз ямен.

Җәза көткән күндәм тоткын кебек,
Үз итәрбез Вакыт зинданын.
Нинди дару кабып карасаң да,
Чарасы юк инде, юк аның.
Карышырсың. Ләкин иң хәтәре –
Өмет өзәр беркөн күңелең.
Сыгылырсың үксеп, күрерсең дә
Мәхәббәтнең мөмкин түгелен.
Мин көтәрмен. Ходай биргән яшьлек
Ким дә булмый инде, артык та.
Мин янында булмам. Мин көтәрмен,
Мин көтәрмен сине картлыкта.
Мин көтәрмен сине. Син ашыкма.
Син бит миннән бераз яшь әле.
Шулай булды инде, Мәхәббәтем
Гел аерым миннән яшәде.
Юк мәхәббәт белән юлны бутап,
Читләр булды якын-тирәмдә.
Бәгырькәем, сау бул, китә торам
Соңгы әҗәтемне бирәм дә.
Әгәр Ходай мәрхәмәтле булса,
Кушылырбыз тагын йөгереп.
Килер, бәлки, җаннар кушылыр көн,
Соңгы әҗәт – соңгы шигырем.
Бу дөньяда күрдек барысын да,
Теге дөнья бирми бер хәбәр.
Никадәрле татлы булса Сөю,
Җавап тоту авыр шулкадәр.
Йә Ходаем, кичер бу колыңны,
Юлымда бу соңгы борылыш.
Миңа тиеш булган мәхәббәттән
Бу бит бары меңнән бер өлеш.
Ничек яшәсәк тә ятасы бар
Бер үк җирдә байга, ярлыга.
Тик Мәхәббәт иде бар хыялым,
Йә Ходаем, кичер, ярлыка.

Без картайгач, җәйләр кыска инде,
Без кавышкач, гомер кыскарды.
Чит дөньяның чит кояшы кебек,

Мин күзәтәм хәзер кызларны.
Борылыштан килеп чыкты ул Көн, –
Калган инде соңгы бер адым.
Алла сүзен соңгы сүзем итеп,
Мин атладым, уйлап тормадым.

Сагышлы бу серле елмаюда
Барысы да якын, үз иде.
Бу – моңаю гына түгел,
«Барысы да
Уза! Уза!» дигән сүз иде.
Ничек үткән – шулай үткән гомер,
Төзәтерлек аны чара юк.
Гомер белән Хөкем якынлаша,
Тәүбә кылыр өчен ара юк.
Без аңлыйбыз – гомер мизгелләрен
Җирдә ваклап-күпләп сатмыйлар.
Без яшәдек. Без көтәбез җәза.
Ә солдатлар никтер атмыйлар.
Җәза көткән күндәм тоткын кебек,
Барысына әзер инде без.
Бернидән дә инде курыкмыйбыз,
Бернигә дә китми исебез.
Барысын да күрдек бу дөньяда,
Яндык-көйдек, баттык суга да.
Тормыш сәер – кайчак баштан сыйпый,
Күз төбеңә башта суга да.
Без көтәбез соңгы җәза көнен,
Без түзәрбез аңа, без тыныч.
Бернидән дә курыкмасак та бик,
Җавап тотулары куркыныч.
Өметләнәм чәчәк куярлар дип
Кабер ташымдагы шәүләмә.
Бу шигырьне Ходай биргән икән,
Шәфкать иңәр, бәлки, тәүбәмә.
Мин дә аңлыйм, Ходай мәрхәмәтен
Анда ваклап-күпләп сатмыйлар.
Өметле җан әзер барсына да,
Тик солдатлар һаман атмыйлар.

Яшәү яме ләззәт гаме түгел,
Бәхет дибез, килсә Мәхәббәт.
Ләкин бәхет – тәүбә кылып көткән

Соңгы өмет – Олы Мәрхәмәт.
Көлемсерәр кемдер. Гаеп түгел.
Бозыклыктан була ялгышу.
Өметлеләр белә, күрә аны,
Өметсезләр өчен каргыш ул.
Өметсезне күрми узып китә,
Өметлене куя чиратка.

Бар ул, бар ул Мәрхәмәтле Ходай,
Карап тора безгә ерактан.
Уянуга беркөн, Зур Куаныч булып,
Күз алдында булса Гүзәл Сын,
Килеп җиткән, димәк, синең чират,
Хөкеменә ничек түзәрсең?
Ә без монда дөнья җимерәбез,
Адым саен язык ялгышлар.
Күтәрелеп кара Ходайга бер,
Чыраенда күпме сагыш бар...

Бәгырькәем, сау бул, китә торам.
Җәйләр кыска, төннәр озайган.
Кушылырмы – юкмы безнең җаннар –
Моны белми хәтта Ходай да.
Коткарырмы юкмы Мәхәббәтне
Соңга калган ихлас тәүбәләр?
...Чапкан үлән кебек авып төшә
Җан асраган фани гәүдәләр.
Бер мизгелдә дөнья бетте кебек,
Тик берүзем калдым Галәмдә.
Аерылдым Җирдән, ә еракта
Бәхетем дә калды, бәлам дә.
Тагын күрдем – ә солдатлар инде
Өйләренә таба атлыйлар.
Атласыннар. Димәк, бүген инде
Алар беркемгә дә атмыйлар.
Тагын күрдем – төрле булсак та без,
Барыбызның Җирдә зары бер.
Җитәкләшеп йөри
Бәла белән бәхет,
Ләкин миңа инде барыбер.
Барысы да чүп шикелле хәзер.
Мин идемме шулай яраткан?
Сагыш тулы елмаюлы чырай

Карап тора миңа ерактан...

**Бердәнбер өлеш**
*(Поэма. Икенче кисәк.)*

Игелек эткә ташланган сөяк түгел, игелек – эт белән бүлешкән сөяк.
*Ирвинг Стоун*

Аның янында кичкән котлы көндә,
Гаҗәп ләззәтле төшләр күрдем өндә.
*Дәрдемәнд*

Килде бер көн,
Тынды дөнья,
Очты төтен,
Артта калды тынсыз бер адым.
Алла сүзен соңгы сүзем итеп,
Мин атладым, уйлап тормадым.
Бу мизгелдә дөнья бетте кебек,
Үзем генә калдым Галәмдә.
Аерылдым Җирдән. Алда мине
Бәхетем дә көтә, бәлам дә.
Килеп җитте, димәк, минем чират,
Алда көтә бердәнбер өлеш.
Вак тормышның инде хак юлына
Килеп җитте соңгы борылыш.
Гамьсез чак та, ямьсез чак та булды,
Чиксез монда минем кебекләр.
Соңгы борылышка килеп җиткәч,
Һәркемдә дә соңгы өмет бар.
Сагыш тулы елмаюлы чырай
Карап тора сынап ерактан.
Мин тапшырам аңа җан җырымны
Мәңгелеккә баскан чираттан.
Монда килгәч, дөнья ике якка
Үталмаслык булып ярылыр.
Артка юл юк. Алда хөкем көтә.
Ә калганы инде барыбер.
Фани дөнья тулы вак мәшәкать
Убылдымы төпсез коега?
Бәгырькәем, биткә кершән сөртү
Монда хәзер көлке тоела.
Кыйгач-кыйгач каш ясаган чакта,
Иреннәргә иннек сөрткәндә, –

Киселәсе башны бизәү бит бу,
Хак хөкемгә чират көткәндә.
Тормыш гамен чүптән аерырга
Күпме дога, күпме көч кирәк.
Әшәкесе аның диңгез-диңгез,
Ә бәхете бары бер чиләк.
Очрый сирәк бу тормышның серен,
Кадерен дә белгән изгеләр.
Ләкин күпләр күрә Хакыйкатьне,
Килеп җиткәч соңгы мизгелләр.
Бәгырькәем, тән рәхәте үтәр,
Соңгы юлга бар бит чыгасы.
Кыйгач кашлар язык түгел, ләкин
Исеңдәме әнкәң догасы?

Йә Ходаем, инде тәүбә кылып,
Язмышымны Сиңа тапшырам.
Мин сокланып килдем бу дөньяга,
Китәм денсезлектән аптырап.
Раббым, кичер, барлык газабымны
Гөнаһларым белән тигезләп.
Бар хыялым сөю, шәфкать иде,
Кереп баттым ләкин диңгезгә.
Өзгәләнгән җанда газаплы моң,
Бәргәләнгән тәнем яралы.
Мин тырмашып үттем әллә кемнәр
Җырлап-биеп үткән араны.
Мин сөймәдем денсез түрәләрнең
Сукырлыгын, вак мин-минлеген,
Үзем туган бу юлбасар илне,
Аның ялган «күңел киңлеген».
Көн дә күрдем – Җирдә гомер юлы
Гаделсезлек тулы юл икән.
Бу дөньяда тыныч яшим дисәң,
Битараф бул, сукыр бул икән.
Ялган тулы котсыз Ил эчендә,
Файдасыз дип, күпме дәшмәдем.
Телгәләде ятим йөрәгемне
Ач сабыйның саф күз яшьләре.
Ә түрәләр күрми үтә көн дә,
Арада кап-кара пыяла.
Янымда ач кемдер булса, мин бит

Ипи кабарга да оялам.

Күңел күзең әгәр күрми икән,
Маңгай күзең – ботак тишеге.
Күбесенчә, никтер шундыйларга
Байлык килә таудай ишелеп.
Үлмәсен дип сабый,
Кемдер акча эзли,
Оят күреп кесә сайлыгын.
Икенчесе алтын сарай төзи,
Әрәм итеп хәрәм байлыгын.
Хикмәт монда ялкаулыкта түгел,
Бу тик черек байлар ялганы.
Имансызлар хөкем сөргән җирдә
Мәкерсезләр кала алданып.
Бу тормышта бары да киресенчә –
Кашык кына тота белгән кыз
Түрдә йөри фәхши җыеннарда,
Сурәт ясый кемдер тыз да быз.
Сыер савып каткан бармакларның
Кашык тотарлык та хәле юк.
Ләкин көрәк тота, чөнки бездә
Бәрәңгесез йортның яме юк.
Ә мәхәббәт монда мөмкинме соң?
Кирәк булса да бик кемгәдер,
Йә саталар аны җыеннарда,
Йә үтерә аны көн гаме.
Ачыла тик ачы бер хакыйкать,
Тормыш – михнәт тулы юл икән,
Бу дөньяда рәхәт яшим дисәң,
Мәрхәмәтсез, денсез бул икән.
Ә шулай да гөнаһларым таныйм,
Гомеркәем тулы ялгышлар.
Күңелемдә Галәм ялгызлыгы,
Чыраемда чиксез сагыш бар.
Йә Ходаем, кичер барысын да,
Язмышымны Сиңа тапшырам.
Гаҗәпләнеп килдем бу дөньяга,
Китәм котым очып, аптырап.
Ничә тапкыр мине фәрештәләр
Тартып алды әҗәл кулыннан.
Исән калганыма исем китеп,
Уйлап йөргәнем бар соңыннан.

Җитеп килә Ходай язган вакыт,
Күңелемдә соңгы өметем.
Үкенечем-тәүбәм тау кадәрле,
Ә өметем тик бер чеметем.

Фәрештәләр, ахры, сүз иңдерде:
«Җир тормышы – сынау өлгесе».
Аны хурлау синең эшең түгел,
Һәркем алыр тиеш өлешен.
Чын байлыкны күрми сукыр адәм,
Нәфесенең белми чамасын.
Тизәк казып базар чүплегендә,
Фәрештәне ничек табасың?
Затлы мөлкәт җан рәхәте бирми
Таш койманың теге ягында.
Бәхетсезләр алар бу тормышта,
Бәхетсезрәк монда тагын да.
Байлык – мизгел. Барысы да кала
Вакыт кырларында чәчелеп.
Аянычы, куанычы белән
Җанны көтә монда Мәңгелек.
Үз-үзеңне чыршы кебек бизәү,
Алтын сарай төзү әрәмгә
Кирәк түгел кыйбла яктысында
Иман нурын күргән адәмгә.
Ара да юк, Вакыт та юк монда,
Килгән ел да, киткән ел да юк.
Барысы да тыныч диңгез кебек,
Искән җилләр, аккан елга юк.
Беркем белми – нәрсә көтә аны...
Тоташ җәннәт, тоташ газапмы?
Күпме җәбер Җирдә!
Күңел күзең бармы?
Явызлыктан җаның азатмы?
Бисмилла дип башла адымыңны,
Иманыңны сакла һәр эштә.
Нинди генә эшкә тотынсаң да,
Баш очыңда булсын фәрештә.
Исеңдәдер, бер бәхетсез ана
Килеп басты беркөн каршыңа.
Ул сөйләде елап – үсмер кызын
Бәреп качкан җиңел машина.
Берьялгызы сыкрап, хәрәкәтсез,

Түшәктә ул ята, идәндә.
Бик тә кыен Кеше булып калу,
Ярдәм сорап кеше килгәндә.
Вазифасын белгән,
Мөмкинлеге булган,
Төрле үлчәмдәге түрәләр,
Яклаучысыз ярым ятим кызны
Имгәк итеп кенә күрәләр.
Бу бәхетсез ана сиңа килде,
Кайгысыннан кипкән, ябыккан.
Син эшләгән гәҗит аша, бәлки,
Ярдәм сорарбыз, дип, халыктан.
Эссе бер җәй иде. Баласының
Килгән икән карбыз кабасы.
Карбыз базар тулы. Тик акча юк.
Юк акчаны каян табасы.
Син эшләгән гәҗит кыйбла иткән
Алыш-биреш, сәүдә, табышны.
Ишетмиләр монда
Тамагыңны ерткан
«Коткарыгыз!» дигән тавышны.
Яшәү белән Үлем,
Табыш белән Шәфкать,
Хисап белән Хисләр чигендә
Күпме сугыш бара, кан коела,
Җимерелә кайчак зиһен дә.
Күзкәйләрең мөлдерәмә булды:
«Булдыралмыйм... Түрә түгел мин...
Үз-үземне шуңа күралмыйм,
Үз-үземне сөймим бүген мин,
Һич югында, менә... бераз акча...
Балакайга карбыз сатып ал...»
Дөрес иттең. Ятып котылганчы,
Мөмкинлегең хәтле атып кал.
Ходай кинәт, көтмәгәндә сыный,
Хакыйкатьнең була Мизгеле.
Бер ягында аның вак түбәнлек,
Бер ягында Олы Игелек.
Уртасы да була. Иң хәтәре –
Ике йөзле урта әһелләр.
Мизгеленә карап эшкә ярап,
Барысына риза-бәхилләр.
Ә син дөрес иттең, уйламадың,

Соңгы акчаң санап тормадың.
Күп тә түгел. Тик эш анда түгел,
Ихласлыгы тиңсез, бер аның.
Ачлы-туклы яшисең бар иде,
Елап калдың җәлләп баланы.
Шул Мизгелдә үттең Мәңгелеккә,
Мәхәббәткә илткән араны.
Кыз бәхетле иде, аз булса да,
Карбыз ашады ул туйганчы.
Гөнаһсыз, саф, ачык күкрәгенә
Тамды, тамды татлы нур-тамчы.
Тамчыларны сөртеп, әйтте кызы:
Чәчләремне килә үрәсем.
Чәчләремне үреп, матурланып,
Шул егетне килә күрәсем.
Шул сүзләре белән дөнья куйды...
Шул теләге белән бездә ул.
Сине саклап йөргән фәрештә дә,
Хуш китәрлек сылу кыз да ул.
Ә вакытсыз киткән,
Бер гөнаһсыз кызның
Чынга аша монда хыялы.
Син эзләгән сөю,
Сихри ләззәт
Карап тора сиңа оялып.
Җирдә калган мәхәббәтне оныт.
Аның юлы синең юл түгел.
Сиңа гына түгел елмаюы,
Сине көткән бәхет ул түгел.
Ул да килер, ләкин монда түгел.
Син үзең дә яхшы беләсең –
Тән яралган серләр оясының
Бикли белмәде ул келәсен.
Рәнҗеделәр күпме сиңа кадәр
Аны сөйгән синең танышлар.
Гашыйк җанын казып бер карасаң,
Күпме газап анда, сагыш бар.
Гыйшык уты – Ходай бәндәсенең
Сәмави, саф күңел нуры ул.
Гашыйкларны рәнҗеткәнгә монда
Җәһәннәмгә кыска, туры юл.
Күр, кем көтә сине, бәхет итеп,
Күкрәгеңә башын салырга,

Мәхәббәттә чиксезлеккә очып,
Мәңгелектә бергә калырга...»

Иреннәрне иреннәргә сузып,
Кара-каршы бастык тезләнеп.
– Мин бит сине ничек озак көттем!
– Ә мин сине озак эзләдем!
– Артта газап тулы ялгызлыгым.

– Артта ялгыш баскан эзләрем.
– Бер теләгем калды, сине көттем.
– Ә мин сине белми эзләдем.
– Мин бит сине саклап кына йөрдем.
– Мин сизендем, ләкин белмәдем.
– Саклый-саклый сине озак көттем.
– Ә мин сине озак эзләдем.
– Мәхәббәтсез иде гомер язым.
– Синсез иде гомер көзләрем.
– Озак көттем сине, тик сакладым.
– Ә мин һаман сине эзләдем.
– Сиңа илтте мине карбыз тәме.
– Мине сиңа – каләм эзләрем.
– Беркемгә дә бирми, озак көттем.
– Мин бары тик сине эзләдем.
– Күкрәгемә тамды күпме тамчы.
– Күз яшеме түкте күзләрең?
– Карбыз тамды ут тамчысы кебек.
– Ә мин һаман сине эзләдем.
Иреннәргә иреннәрне кушып,
Үбә-үбә карбыз эзләрен,
Рәхәтеннән хушыбызны җуеп,
Гүзәл Сын алдында тезләнеп,
Чиксезлеккә таба адым ясап,
Мәңгелекнең кагып капкасын,
Шуны гына телим:
Алла кушып,
Фәрештәләр сезне сакласын!

**Чокырча тавы***

Безнең тауны тау дип әйткән чакта,
Ак түбәле таулар үпкәләр.
Тау тау була, әгәр күкрәгенә
Ак болытлар кагылып үтсәләр.
Мактанырлык булмаса да аның
Биеклеге, иң һәм буйлары,
Без бу таудан очтык, тәвәккәлләп,
Канат итеп хыял-уйларны.
Болытларга түгел, йолдызларга
Очып җитү безнең хыяллар.
Юлда сынып калган каурыйларны
Яшьрәк, ныграк дуслар җыярлар.
Җыярлар да, яңа канат ясап,
Табар алар бәхет юлларын.
Ләкин онытмаслар безнең тауны
Чокырчаның моңлы уллары.

...Ул сузылган биек дулкын кебек,
Түбәсендә арыш кырлары.
Инеш булып ага чишмәләре,
Итәгендә борма юл ярып.
Таудан бәреп чыккан бу су юлы
Тормыш юлы кебек бормалы.
Су буенда үсә бөдрә таллар,
Чишмәләрдән бетмәс көч алып.
Давыл-бураннардан ышыкланып,
Таллы итәгенә сыенып
Яшәгәнгә авыл, авыр чакта
Күбрәк тауга төшкән кыенлык.
Китүчеләр тауга менеп киткән,
Таудан төшкән – өйгә кайтканнар.
Ил тетрәгән чакта тау тетрәгән,
Еллар аккан, аккан ал каннар.
Соңгы озатучы юлчыларны
Һәм беренче каршы алучы.
Үз авылын күреп хозурланган
Тау башында торган һәр юлчы.

---

* Чокырча – Туган авылым Аман-Оштарманың иске исеме.

Китүчеләр тауга әкрен менгән,

Кайтучылар төшкән йөгереп.
Кайтучылар һәрчак әзрәк булган,
Тауны күргән алар иң элек.

...Тау сукмагын инде чирәм баскан,
Бетеп килә җәяү йөрүләр.
Картайды тау. Онытылды бераз.
Авыл бетә. Тиздән тау үләр.
Авыл кими. Заман шулай куша.
Үзәк утар матур булачак.
Тик танымый мондый матурлыкны
Тау буенда үткән балачак.
Ә алдагы буын яңа җирдә
Таусыз туган ягын яратыр.
Безгә генә шулай авыр булыр
Чокырчаны читкә тарату.
Авыл күчә. Җансыз тау кала тик.
Булмый, булмый тауны күчереп.
Онытмагыз тауны, китүчеләр,
Безнең истә чакта, ул тере.
Әйе, без бу таудан очкан идек,
Тәвәккәлләп, тормыш күгенә.
Югарыдан кырлар чиксез кебек,
Алдагы юл киңрәк күренә.
Дөнья серле, чиксез кебек иде.
Күңел киләчәккә ашкынды.
Бата-калка кичүләр дә булды
Кайгы-хәсрәт тулы ташкынны.
Иң авыры... Әни иртә үлде...
Китек иде күңел, түземле.
Таудан төштем йөгереп, тик соң иде,
Әйтми калдым соңгы сүземне.
Сөймим озак кан-яшь агызырга
Һәм изәргә хәсрәт измәсен.
Шуны телим: әнкәм каберенә
Аяусызлар якын килмәсен!
Яңа очкан бәхет кошчыгының
Бер канатын давыл каерган,
Тормыш төпләп кенә килгән парны
Мәңгелеккә сугыш аерган.

Сыңар канат – сыңар бәхетсезлек,
Күтәралмый бәхет күгенә,

Талпынып та дөнья киңәймәгәч,
Башын салган каен төбенә.
Ул җырлаган җырлар онытылмый,
Аның җаны – сагыш кыясы.
Әгәр дә мин шагыйрь була калсам,
Һәр шигырем – әнкәм мирасы.

...Тау каршында зират каеннары,
Хәтерлисезме сез мине дә?
Ә мин сезне онытачак түгел,
Әнкәм кабере кала бирергә.
Сөймим озак кан-яшь агызырга
Һәм изәргә хәсрәт измәсен.
Шуны телим: әнкәм каберенә
Дуслар чәчәк куймый китмәсен.

Шушы таудан безне кабул итте
Зур мәктәбе күрше авылның.
Таудан читтә сиздек ачылыгын
Кар-буранның, җилнең, давылның.
Кышкы тауга бизәк булып ятты,
Сырлап менгән чаңгы эзләре.
Кайткан чакта, кайчак «очып» төшеп,
Чаңгы сыныкларын эзләдек.
Таудан читтә җилләр каты исә,
Сулар тәмсез, тормыш аяусыз.
Җиңел түгел кырыс бу дөньяда
Яшәү туган яксыз һәм таусыз.
Таудан бергә тәгәрәгән дуслар
Инде күптән үсеп җиттеләр.
Тәннәренә сеңгән тау егәрен
Тормыш арбасына җиктеләр.
Мин үзем дә хәзер таудан ерак,
Башка биеклеккә үрмәлим.
Бизәк булып кала каләм эзе,
Давыллардан, җилдән шүрләмим.
Белмим әле чын бәясен бүген
Үзем сызган «сырлы эзләрнең».
Тик шулай да, әгәр «очып төшсәм»,
Бәхет сыныкларын эзләрмен.

Шушы таудан кабул итте инде
Зур мәктәбе кызу тормышның.

Тик азаплый безне сагыну чире,
Бу авыру, ахры, йогышлы.
Якташларны читтә күп очраттым,
Һәркем безнең тауны сагына.
Мин дә кайтып сихәт алдым бераз
Кукмараның таулы ягына.
Тауны онытмаган дуслар белән
Нәрсә безгә юллар, кыенлык! –
Әнкәм итәгенә сарылган күк,
Мин дә кайтып тауга сыендым.

Ахры, тауның җанын ала инде
Замананың кызу еллары.
Онытмагыз тауны, онытмагыз,
Чокырчаның моңлы уллары.
Җансыз түгел ул тау безнең өчен,
Халык кебек моңлы, түземле.
Һәм ышану моңа авыр түгел,
Киңрәк ачсаң күңел күзеңне.
Авыл кими. Заман шулай куша.
Матур үзәк утар салалар.
Тудырырлар яңа балаларны
Тау буеннан күчкән аналар.
Бу алдагы буын яңа җирдә
Ямьле туган ягын яратыр.
Безгә генә шулай авыр булыр
Чокырчаны читкә тарату.
Еллар имин торсын. Авыл күген
Капламасын сагыш рәшәсе.
Балаларның күңеле кителмәсен
Һәм әниләр озак яшәсен!
Авыл күчәр. Күпме еллар узар.
Иске йортлар череп таркалыр.
Тик, истәлек булып мәңгелеккә,
Авыл шәүләседәй, тау калыр...

**Алмагачлар сагышы**

*Безнең балалар йорты урнашкан һәм, гомеремнең кечкенә генә бер кисәген үзенә алып, гомер буена онытылмаслык хисләр калдырган Субаш-Аты авылына багышлыйм.*

**Балалар йорты**

*– Менә, улым, әтиеңнең өе...*
*– О, шундый зурмы?*

Әйдә, дустым, бер сөйләшик әле,
Хәтер сандыкларын актарып.
Барып кайтыйк күмәк йортыбызга,
Сагындырды Арча яклары.
Еллар үткән саен, хәтерләрдә
Тоныклана ерак мизгелләр.
Бер-беребездән без дә читләшәбез,
Вакыт кыса, хисләр изелә.
Бәхетсезлек безне бергә җыйды,
Ризык, ышык бирде туган ил.
Ә таратты бәхет-хыялларны
Ерак офыкларга куган җил.
Җил генә дә түгел, давыл иде
Ул вакытта безнең күңелдә.
Шул давылда купкан тузан белән
Күпме шашкын уйлар күмелгән.
Чаптык алга, уңны-сулны күрми,
Качкан кошчык кебек читлектән.
Читлек булмады йорт, тик ни чара? –
Юллар ачык, егет җитлеккән...
Булмас, беркем, беркем дә хурламас
Ул чактагы кырыс елларны,
Еласак та кайчак, юрган белән
Башны каплап, кысып тыннарны.
Никтер шулай истә гел яхшылык,
Онытыла үпкә-сагышлар,
Һәм борчыйлар, кайчак искә төшеп,

Бары үзебезнең ялгышлар.
Хәер, кемнәр генә хәтерлидер
Һәр тойгының көнен, сәгатен.
Кем әйтмешли, нигә актарырга?

Яшә күреп дөнья рәхәтен.
Ләкин күңел сулар сибеп саклый
Балачакның гөлле каберен.
Аңлап булмас кебек, гөлләр шиңсә,
Яшәү ямен, тормыш кадерен.
...Ярыйсы ук ерак таралыштык,
Күп хисләрне еллар юдылар.
Һәркемнең дә тормыш урамында
Үзе сайлап алган юлы бар.
Ул елларның ерак тамырлары
Кушылалар тик бер урында.
Әйдә, дустым, җырлыйк бер утырып
Ап-ак алмагачлар турында.
Утыр, дустым, бер сөйләшик әле,
Искә алыйк малай чакларны.
Уйнап җибәр «Алмагачы» көен,
Сагындырды Арча яклары.

**Алмагачлар**

Алмагачы чәчәк ата
Майның унбишләрендә.
*Татар халык җыры*

Ап-ак чәчәк, ап-ак чәчәк –
Алмагачларның бәйрәме.
Язның бакчага бүләге –
Ап-ак чәчәкләр бәйләме.
Бакчалардан ташып керә
Күңелләргә саф яктылык.
Һәрбер бакча – җиргә төшеп
Кунаклаган ап-ак болыт.
Чәчәк исе, чәчәк исе,
Баш әйләнә, йөрәк ярсый.
Бүгенгедән киләчәккә
Уйдан хыял болыт ясый.
Аерыла болыт җирдән,
Хыял җиленә карышмый,

Җир офыгы киңлегеннән
Күңел киңлеге калышмый.
Алмагачлар арасында,
Шушы йортта, шушы якта,

Бу безнең соңгы языбыз,
Соңгы борылыш бу чатта.
Имтиханнар алда, әле
Комнан хыяллар ишәбез,
Түбәләргә менеп ятып,
Тигезләмәләр чишәбез.
Тигезләмәнең бер ягы
Һәрвакытта да нуль була.
Шул нульләрне сыга-сыга,
Белем исемле күл тула.
Ләкин менә... алмагачлар,
Җылы кояш, чәчәк исе,
Какшаталар бар зиһенне,
Сихри җилләр булып исеп.
Иксларның чын йөзләрен
Ачам дисәң ахыр чиктә,
Ап-ак болыт уйларыңны
Үзе белән элеп китә.
Һәркемнең дә уйларында
Алдагы юллары туры.
Һәркем бага, өмет итә
Җирдәге бәхетнең зурын.
Кар сулары күңелдәге
Гамьсезлекне юадыр ул.
Матурлыкка карап кына,
Матур уйлар туадыр ул.
Алмагачлар, алмагачлар,
Сихерләдегез бит тәмам.
Алда соңгы имтиханнар,
Ә мин уйларымда янам.
Табигать дигән җәннәтнең
Бер почмагы – бакчагызда.
Ярый миңа, алма бирми,
Чәчәк кенә атсагыз да.
Чәчәк белән күңелләр тук,
Матди уйлар ялда әле.
Алма кирәк булыр вакыт
Алда әле, алда әле.

Үзебез дә чәчәк әле,
Килер алма булыр чаклар,
Алма булып авырайгач,
Билләребез әле чатнар.

Әчесе дә, баллысы да –
Ул бакчада барысы бар.
Түп-түгәрәк күңелләрне
Язмыш тешләп-тешләп карар.
Матурлыкка карап кына
Матур уйлар туа шул ул.
Яши торгач, тормыш гаме
Хыялларны юа шул ул.

**Субаш-Аты**

Гәрчә анда тумасам да,
Мин бераз торган идем.
*Габдулла Тукай*

Алмагачлар арасында
Гади авыл – Субаш-Аты.
Җәе җылы, кышы салкын,
Төне кара, көне якты.
Туган түгел, үги авыл,
Күңелгә җыр салган авыл.
Туганнарсыз калганнарны
Асрамага алган авыл.
Әллә нәрсә данлы түгел,
Холкы тыйнак, халкы моңлы.
Бар шәп укытучылары
Елмаеп искә алырлык.
Аз үсмәде ул авылда
Шәп егетләр, чибәр кызлар.
Бер чибәрен искә алып,
Ахры, йөрәк озак сызлар.
Кырлай якын ул авылга.
Урманындагы һәр нарат
Хәтерлидер күк Тукайның
Хәл җыйганын күккә карап.
«Тамашалар» куеп йөрдек
Күршедәге авылларда.

Җырладык та, биедек тә,
Сыздырып пар гармуннарда.
Субаш-Атына гыйшкымның
Әллә сәбәбе шул инде:
Аерым-аерым кайгыларны

Күмәк күңеллелек җиңде.
Субаш-Аты, Субаш-Аты,
Назлы авыл, ямьле авыл.
Язгы чәчәкләре белән
Алды күңелемнең явын.
Туган түгел, үги авыл,
Йөрәкләрдә калган авыл.
Асрамага алганнарны
Туган итә алган авыл.

**Этюд**

Кимсетелгәнлек һәм ятимлек хисе,
ахры, мине гомер буена ташламас инде...
*Бер хаттан*

Йөрәгемә үк уелып калган никтер,
Бер карасаң, гади генә бер күренеш:
Мич янында басып тора үксез малай,
Бөрешүдән кулын кулга кушкан килеш.
Беренчеме, икенчеме сыйныфта ул –
Хәтерләмим. Хәер, анысы мөһим түгел.
Нинди болыт каплаган соң ул мескеннең
Иң ваемсыз вакытының якты күген?
Күзләрендә шундый сагыш һәм моңсулык,
Ә йөзендә балалыкның эзе дә юк.
Нигә һаман җылыналмый соң ул бала? –
Мичкә яккан, өсте бөтен, тамагы тук.
Ятыйм дисә, ап-ак чиста урыны бар.
Киим дисә, бүреге бар, бишмәте бар.
Бар шуклыгын эшкә җигеп уйныйм дисә,
Үзе кебек дистәләгән иптәше бар.
Рәхмәт, рәхмәт балаларны багучыга,
Рәхмәт мичкә җылы итеп ягучыга.
Ләкин малай һаман туңа, һаман моңсу
Һәм кулларын һаман җиң эченә тыга.

Мич җылысы, тән азыгы монда көчсез.
Кулы түгел, ә күңеле аның туңа.
Әтисенә, әнисенә ул кирәкми
Һәм җылынмый ул өшегән күңел шуңа.
Ярый, безнең сыенырлык беркем дә юк.
«Юк» дигәнне балалар да яхшы аңлый.

Аңлау авыр, «бар» икәнен белә торып,
Аны шулай үксез иткән бу дөньяны.
Мин хәтерлим: кайчак, аны күрер өчен,
Килә иде тып-тын гына сәер ханым.
Һәм шулай ук тып-тын гына китә иде,
Кузгатып һәм ымсындырып сабый җанын.
Нәрсә соң бу? Аңсызлыкмы? Кансызлыкмы?
Мәҗбүр итте нинди сәбәп һәм авырлык?
Бармыни соң бу дөньяда шундый сәбәп,
Үз балаңны чит кулларга ташлатырлык?
Аңлыйм кебек – тормыш кору җиңел түгел,
Кайчак ташка башны бәрердәй буласың.
Ләкин, басып күз алдыма, теге малай
Бар аңымны таптап, изеп, тукмап ташлый.
Гомер буена күз алдымда ул никтер,
Бер карасаң, гади генә бер күренеш:
Мич янында басып тора үксез малай,
Бөрешүдән кулын кулга кушкан килеш.
Яшьлек үтә, ләззәт бетә, гомер кыска,
Озын бары картлык кына үлем көткән.
Таянырлык байлыклар да табылмаган,
Яшьлек дигән алтын вакыт инде беткән.
Гомер үтә. Карт ятимнәрне өшетеп,
Юанычсыз, салкын, тын ялгызлык кала.
Ә кайдадыр тормыш корып, эшләп йөри
Таза, матур, бөтенләй чит... газиз бала.
Эх, мескеннәр, әти-әниләр «элекке»,
Әйтер сүз дә, хөкем дә юк сезгә никтер.
Бу гаепләү белән хөкем арасында
Шушы юллар үталмаслык, ахры, чиктер.
Уянырсыз, уянырсыз, тик соң булыр.
Җир кечкенә, гомер кыска, таяныч юк.
Тагын нәрсә җитми сезгә җылынырга? –
Өйләр җылы, өсләр бөтен, тамаклар тук...

**Истәлекләр**

Иртән торып тышка чыгам,
Кош куам алмагачтан.
Сезнең хәлегезне сорыйм
Сайраган сандугачтан.
*Татар халык җыры*

Ул бакчаны урап үсә
Койма кебек каеннар.
Шул каеннар белән уртак
Якты серләребез бар.
Өстә каен, аста куак,
Кырыйлары текә яр.
Шул яр буйлап алма урлап
Чапкан чакларыбыз бар.
Мүк шикелле тыгыз үскән
Карлыганга бакча тар.
Җиргә посып, ирен белән
Җиләк өзгәнебез бар.
Алмагачлар ишеткәндер
Күпме шатлык, күпме зар.
Кайгы-хәсрәтләрне шунда
Чыгып түккәнебез бар.
Җилфер-җилфер килә каен,
Телсез түгелдер лә ул.
Ак кәүсәсен ялтыратып,
Көнгә карап көлә ул.
Җилфер-җилфер килә каен,
Җансыз түгелдер лә ул.
Көзгә карап бер елый да
Язга карап көлә ул.
Бакчаны кочып үсә лә
Яшел койма – каеннар.
Шунда чыгып, сөйгәннәрне
Көткән чакларыбыз бар.
Өстә каен, аста куак,
Кырыйлары текә яр.
Шунда посып, иреннәрдән
Сөю өзгәнебез бар.
Сулык-сулык, җилфер-җилфер,
Сыгыла бөдрә каен.
Белүчеләр бармы соң ул
Гомерлек сөю җаен?
Җилфер-җилфер җилләр исә,
Чайкала бөдрә каен.
Чәрдәкләнә ак кәүсәләр,
Бөҗралар арткан саен.

Ай-һай, сыгылулары ла,
Каен түгелдер лә ул.

Тавышын чыгармаса да,
Үз газабын белә ул.
Сыкрап-сыкрап сыгыла ла,
Таштан түгелдер лә ул.
Үткән-беткән, күзләр җиткән,
Үз язмышын белә ул.
...Сыгыла каен салкын җилдә,
Каерылып ял сорый,
Алга карап уйлана да
Үткәнгә карап елый.
Алда еллар. Калды җырлар.
Яшь күңелгә дөнья тар.
Еллар буйлап сөю урлап
Чапкан чакларыбыз бар...

**Уналтыдан узып барганда**
Безнең хәзер тиң чагыбыз, тиң чагыбыз
Былбыл балаларына, Асылъяр.
*Татар халык җыры*

Төнге няня Фагыйлә апа усал иде,
Һәрбер төне безне саклап узар иде.
Уналтыдан узып барган малайларга
Сәгать унда йокларга гел кушар иде.
Безнең язлар гади язлар булмады шул,
Күңел көннәр белән генә туймады шул.
Таң атканда кайтып кереп ятар өчен,
Тәрәзәне дуслар бикләп куймады шул.
Тәрәзәдән тып-тын кереп ятар идек,

Күзне йомып, хыялларга батар идек.
Шулвакытта Фагыйлә апа килеп кереп,
Юрганнарны өстән алып атар иде.
«Каян кердең? Әле монда син юк идең!
Ах, мут егет, ахры, оятың юк синең!»
Әллә чынлап ачулана... Безгә нәрсә,
Киләсе төн буш урыннар шул ук иде...
Алмашчысы Миңниса апа юаш булды,
Елмаюы гашыйкларга кояш булды.
Ул булганда, таң атканчы, сүз беткәнче
Тик үзебез төнебезгә без баш булдык.
Уйламагыз, яшьтән артык без тузмадык,

Кирәкмәгән урыннарга кул сузмадык.
Барыбыз да әйтә алыр иде кебек:
Безнең сөю үбешүдән дә узмады.
Миңниса апа әллә безне аңлый иде,
Әллә безне егетләр дип санлый иде.
Фагыйлә апа гына һаман шулай безне
Күз дә йоммый гөнаһлардан саклый иде.
Теләгем юк, бу яхшы дип, бу начар дип,
Бу сүзләрдән һәркем нәтиҗә ясар дип,
Чагыштырып күрсәтергә. Хәзер уйлыйм
Һәркемнең ерактан үз яме бар дип.
Шунсы дөрес: Фагыйлә апа усал иде,
Һәрбер төне безне саклап узар идее.
Унҗидегә җитеп килгән егетләргә
Сәгать унда йокларга гел кушар иде...

**Соңгы сәлам**
Китәм, бәгърем, китәм, бәгърем,
Каласың Арчаларда.
*Татар халык җыры*

Кимсетмәде Субаш-Аты,
Йөзләп идек, күпсенмәде.
Яраларга кагылмады,
Күп сорашып төпченмәде.
Безнең өчен оекбашлар
Бәйләделәр аналары.
Үлчәп бәйләгән шикелле,
Төгәл иде чамалары.

Карт-карчыкка без дә килеп
Су ташыдык, утын кистек.
Артык сүзсез, бергәләшеп,
Көннәр ердык, еллар кичтек.
Үсеп җиткәч, көзгә кергән
Кошлар кебек таралыштык.
Кияү биреп, килен алып,
Тормыш өчен яр алыштык.
Субаш-Аты, халкың җансыз,
Тупас түгел иде бер дә.
Хет хәзер дә кунакка кайт
Кучтәнәчләреңне төр дә.
Икеләнми әйтәм: һәркем

Кочак җәеп каршы алыр,
Кибеткә чабар, бәйрәм дип,
Ашка итен күбрәк салыр.
Искә алыр саклык белән
Ул тынгысыз елларны да,
Ил буйлап таралган, уртак,
Кызларны да, улларны да.
Юк, кимсетмәс Субаш-Аты,
Йөзләп кайтсак та күпсенмәс.
Онытса да күбебезне,
«Детдум» дисәң, күп төпченмәс.
Онытсаң да, без күп идек,
Син бер генә, Субаш-Аты,
Яныңдагы инешләрдән
Инде күпме сулар акты.
Истәлекләр генә һаман
Сулар белән китми агып,
Сөйләшергә сүз сорыйлар,
Күңел тәрәзәсен кагып.
Ерагайган арабызга
Еллар һаман киртә кора.
Ялваралар җанлы хисләр,
Каләмемнән сурәт сорап.
Матур чыккандырмы-юкмы –
Менә инде сурәт әзер!
Иң мөһиме, еллар корган
Киртәләр юк безгә хәзер.
Бу сурәт сәламем булыр
Сезгә, ерак ак каеннар.

Сәлам сиңа, Субаш-Аты,
Моңлы, үги малаеңнан!

**Саубуллашу**

Нинди генә матур итеп сөйләсәң дә,
Чит-ят илләр туган ил булмый.
*Татар халык җыры*

Ярый инде, саубуллашыйк, Субаш-Аты,
Ахры, озак синең белән күрешмәбез.
Ахры, синең чибәрләрең белән башка
Агачларга сыена-сыена үбешмәбез.

Бүтән төшмәс минем янга, су буена,
Ак тасмасын җилфердәтеп бер акыллың.
Бүтән булмас урамыңда гармун уйнап,
Моңга күмеп, җилкендереп бар авылны.
Һәр заманның үз вакыты, үз кызыгы,
Минем яшьлек алмагачлар белән калды.
Шуңа күрә ул ташландык ялгыз бакча
Сиңа тугры күңелемә сагыш салды.
Хәтер җиле кагылуга яңгырыйлар
Синнән миңа тарттырылган моңлы кыллар.
Кереп чыккан кунак йорты кебек итеп,
Һич онытып булмый сине ничә еллар.
Бәхет килсә, бер кайтырмын синең янга,
Кочаклармын өй янында өч каенны.
Битем куеп чәрдәкләнгән карт кәүсәгә,
Ишетермен безне сагынып шаулавыңны.
Ак тасмасын җилфердәтеп кызчыгының,
Танымыйча, бәлки, мине китәр узып,
Алмагачлар, ак чәчәкләр арасында
Өзелеп-өзелеп сөя белгән кыю кызың.
Танымаса танымаслар, гаеп итмәм,
Үзем генә хәтер утларында яныйм.
Мин үзем дә шул вакыттагы үземне
Еллар аша зур авырлык белән таныйм.
Ярый, сау бул, Субаш-Аты, күп сөйләштек,
Ә хәзергә тәмам итик бу язуны.
Җыйдым татлы һәм шифалы истәлекләр,
Ап-ак, гүзәл чәчәкләргә кунып-кунып.

Мин ышанам: хушлашабыз тик хәзергә,
Бу язмалар синең өчен бик кечкенә.
Ап-ак чәчәк арасыннан эзләп табып,
Чыгарырмын әле сине ил өстенә.

**Ут**

Тынгысыз ут, ник бәйлисең
Минем талгын күз карашым?
Ни сөйлисең, якынайтып
Кеше белән ут арасын?
Мең үзгәреш, мең яңалык
Сөйли безгә кызу телең.
Әллә кысылган Вакытмы,
Ут гомере һәр мизгелең?
Кеше белән ут арасы...
Без бит Кояш тамчысыннан!
Илаһи Җир пәйда булган
Ходай әвәләгән сыннан.
Ясалган чын, түгәрәк сын,
Күкрәгендә уты калган.
Бикләнгән ут читлегеннән
Янар тау булып атылган,
Уттан тормыш ералганда,
Җир-Ананың сулышы бу.
Үле караңгылык белән
Якты тормыш сугышы бу.
Ут гомере булып балкый
Мең яңарыш Җир өстендә.
Яналар һаман учаклар
Көн дә, төн дә. Көн дә, төн дә.
Чор сулышы җансыз, үле
Җисемнәрне утка яга.
Ачыгыз! Утлар эченнән
Җирдә тормыш ишек кага!
Күпме бизәк, күпме төс бар!
Гүя Ходай үзе чиккән.
Ә аннан соң, хозурланып,
Карап торган бераз читтән.
Бизәк саен аның йөзе,
Учак саен аның күзе.
Аның җаны һәр тарафта,
Шуңа күренми дә үзе.
Аның аңы һәр кешедә,
Кеше – иң матур бизәге,
Уттан алып, чорлар буе
Ясаган акыл кисәге.
Кисәге генә бары тик,

Тик Ул гына иң Зур Акыл
Һәм Ул гына яхшы белә
Кеше акылының хакын.
Ходай биргән Акыл дибез...
Күпме тиле бәндә Җирдә!
Җан төбендә янып бетми
Ята яман, бозык чир дә.
Денсездә – ден, җүнсездә – җүн,
Мәнсездә мән уты калса,
Калганы – тик аның эше,
Булдыралса... Булдыралса...
Һәркемнең җанын күрә Ул,
Төбенә үк карап китә.
Беркем өчен җавап бирми,
Ләкин Җавап таләп итә.

Хәтта әле мәҗүсилек тә булмаган
Ерак чорга еллар, уйлар аша багам.
Ярым маймыл, ярым кеше, тирләп-пешеп,
Ауга йөри, агачлардан җиргә төшеп.
Җәнлек куа, балык тота, кош та аулый,
Җиләк-җимеш, үлән-тамырлар да калмый.
Ялт-йолт итеп, кайчак аның башын сарып,
Килгәлиләр гаҗәеп уй чаткылары.
Акыл әле шыта гына һич тәртипсез,
Уй мәгънәсез, эшләр ямьсез, куллар ипсез.
Күңел кыргый, төннәр кара, куыш салкын,
Нидер тота торгынлыкта маймыл халкын.
Менә җәйнең бер төнендә давыл купты,
Корып кипкән тал-тирәкне яшен сукты.
Очкын чәчеп төн буена янды тирәк,
Куыштагы кабиләнең уен биләп.
Бу җылыга алар чыгып сыендылар,
Чаткы-чаткы уйлар утка җыелдылар.
Куркаклыгын шунда җиңде кыргый күңел,
Утка килгән җан иясе җәнлек түгел.
Учак уты аңа илһам бүләк итте,
Очкын уйлар ут янында дөрләп китте.
Кешегә ут икеләтә туган булды –
Башта тәне, аннан җаны уттан туды.
Меңәр еллар – Кешелекнең үткән юлы,
Юл башында учак яна, маяк булып.

Еллар буйлап тарих салмак тартты
Чорлар сәгатенең серләрен.
Сиземләде кебек инде Кеше
Сихри утның гади серләрен.
Ут ул саксыз, кыргый җәнлек кебек,
Холкы кызу, көче чамасыз.
Азык булса яна, ә булмаса,
Җиргә ятып үлә чарасыз.
Мәңге сүнмәс кебек күренсә дә,
Олы утлар сүнә барыбер.
Бар дөньяга нәни очкын да
Кайчак афәт булып сарылыр.
Әле вакыт шашып чапмаган чак,
Табигатьнең әле үз яме.
Кояшка һәм утка карап, Кеше
Чамалады вакыт үлчәмен.
Ут табулар әле мөмкин түгел,
Ут сакчысы – тормыш сакчысы.
Ә бервакыт... күрми калды Кеше,
Сүнде ялгыш учак яктысы.
Ут яктысы – тормыш ышанычы,
Ут югалткан – башын югалткан.
Куылды ул читкә, ялгызлыкка
Куыштагы салкын торактан.
«Йә ут табып кайтсын кабиләгә,
Йә үлсен ул, ялгыз, урманда.
Иң зур гаеп – утны саклый алмау,
Уйлый белгән башың булганда».
Ут табуга өмет юк диярлек,
Тормышлар да шулай сүнәрме?
Бар кабилә, салкын кышка кергәч,
Җылы тапмый туңып үләрме?
Утка мәңге гашыйк хәзер Кеше,
Алга бора тормыш сәхнәсен,
Ут җылысын тоеп, утсыз калгач,
Күрми башлый яшәү мәгънәсен.
Маймыл чыккан тарих күперләре
Вакыт чыккан чакта ватылды.
Элеккечә утсыз яшим дисәң,
Ватып буламы соң акылны?

Артка юл юк. Тормыш алга бара.
Йә ут таба Кеше, йә үлә.
Йә акылы балкып юл күрсәтә,
Йә югала туган кабилә.
Башка якта башка кабиләләр
Ут табарлар әле барыбер,
Һәм Кешелек рухи торгынлыктан
Үз акылы белән арыныр.
Артка юл юк. Ут булырга тиеш.
Тормыш белән ул нык бәйләнгән
Һәм гасырлар буйлап ут – тормышка,
Тормыш утка һаман әйләнгән.
Шулчакта ут акыл учагының
Кисәүләрен тизрәк көйрәтте.
Үзеннән соң килгән варисларын
Кайгыга да үзе өйрәтте.
Ут хәлсез дә, рәхимсез дә була,
Ут тарихы зарны күп белә,
Көн дә сабак бирә кешеләргә –
Акыллы бул, сак бул ут белән!

Менә атлый безнең Кеше
Урманнар буйлап,
Яңа укмаша башлаган
Уйларын уйлап.
Мәш киләләр кош-корт, бөҗәк,
Һәр тараф тулы.
Бар тик җәнлек сукмаклары,
Юк адәм юлы.
Тәлгәшләп, кыргый җимешләр
Авызга тама.
Чишмәдәме, күлдәме су –
Сафлык бер чама.
Җәннәт кебек борынгы Җир,
Бар тереклек тук .
Кеше кеше булсын өчен
Тик ут кына юк.
Атлый кеше. Ничә көннәр
Бер уй башында.
Менеп баса биек кенә
Кыя ташына.

Менеп баса да ялварып

Карый күкләргә –
Эзли куәт иярен,
Җиргә ут бәргән:
«Кайда син, дөнья хуҗасы,
Ут бир юлчыга?!» –
Шулдыр иң беренче тапкыр
Укылган дога.
Ә күктә кара болытлар
Куерып килә.
Ялт-йолт итәләр яшеннәр,
Күк күкри кинәт.
Сорап алган түгел, ләкин
Ява бит яңгыр!
Тик кеше хәзер Аллага
Мәңге ышаныр.
Нидер йөгереп эзли ул,
Бер күсәк таба
Һәм суза аны болытка –
Аллага таба.
Кул тиярлек якын болыт,
Кайный, агыла.
Чытырдап күсәк очына
Яшен кагыла.
Аллаларга сузылган кул
Кирәген алды.
Теләнчене яшен җиргә
Бөтереп салды.
Сизденме утлар дәһшәтен?!
Шәфкать юк монда!
Җир дә, кеше дә чүп кенә
Зур ут алдында.
Һәрбер утка кулың сузма!
Була төрле ут.
Җылысы бар, кылычы бар,
Биге, чиге юк.
Утның да үз дөньясы бар,
Үз тынычлыгы.
Борчысаң, көл итеп ташлар,
Бигеннән чыгып.
Уйла, эзлә, тик, теләнеп,
Сузма кулыңны,

Күкләрдән шәфкать эзләмә,

Тап үз юлыңны.
Сукыр фәкыйрь булсаң, утка
Килмә дә якын,
Белмәсәң әгәр үзең дә
Акылың хакын.
...Билгесез, серле утларга
Кулын сузганда,
Шикләнер кеше, сизенер –
Куркыныч алда!
Куркыныч алда! Сизенер,
Тик чикне узар
Һәм, борынгы кеше кебек,
Кулларын сузар.

Еллар үтә, тормыш кайный, акыл үсә.
Яңа җирләр кеше кул астына күчә.
Шул чорларга караш ташлыйк еллар аша:
Ничек итеп утка явызлык тоташа.
Бер утрауда яши менә өч кабилә,
Һәр төркемгә тиешенчә мәйдан биләп.
Бу утрауның бар мәйданы урман иде,
Урманына кош-корт, җәнлек тулган иде.
Яшәү өчен шалашлар бар, куышлар бар,
Җәнлекләрдән калган мирас – сугышлар бар.
Араларны бүлә бидәмәләр, чикләр,
Чиктән ары яшәүчеләр инде читләр.
Биләмәне чикләр куеп биләгән күк,
Табигатьне бүлгәләрлек киртәләр юк.
Куган җәнлек кайчак чаба чит җирләргә,
Туктау читен ауда кызган чит ирләргә.
Чик бозыла, уттай дөрләп гауга чыга
Һәм кешеләр бер-берсенә ауга чыга.
Кулга керә сөңгеләр һәм җәя-уклар,
Уклар очын чорнап ала кызу утлар.
Җылы биргән утның вазифасы яңа –
Ул аңламый, кая атсаң, шунда яна.
Ул аяусыз, каба дошман шалашына,
Мәрхәмәт юк анасына, баласына.
Очкын чәчеп утлы уклар оча гына,
Урман кереп бара ялкын кочагына.

Гаепсездән ут аермый гаеплене,

Җитте җәннәттәй урманның соңгы көне.
Уттан кача исән калган барлык халык,
Диңгез буенда егыла тынсыз калып.
Атау үлде. Кара тынлык җирдә ята.
Һаман диңгез, һаман диңгез тирә-якта.
Ләкин кеше үлмәс әле, көймә ясар.
Акыл исән. Эзләр, яңа атау ачар.
Акыл исән. Көймәләр бар. Ләкин нигә,
Кемне җәлләп исән җаннар газап чигә?..

Кырык бишенче ел Көнчыгышта.
Август башы. Сугыш ахыры.
Берлиннардан күкрәп килә инде
Тынычлык һәм Җиңү яңгыры.
Тарих сөйләү монда кирәкмидер,
Аны һәркем яхшы беләдер.
Бу минутта, бәлки, самолётка
Тарих яңа бомба эләдер...
Хиросима һич тә уйламады
Таш каберлек булып каласын.
Тыныч хезмәт белән көнен күрде,
Бикләмәде өйдә баласын.
Ә балачак – тынгысызлар иле,
Кул-аяклар җитез, караш шук.
Иң беренче алар күргәннәрдер
Күк йөзендә ап-ак парашют.
Нинди парашют бу кешесез дип,
Торганнардыр, бәлки, аптырап,
Төшкән чакта бу кечкенә бомба,
Кара тышы белән ялтырап.
Ә самолёт ерак инде... Кинәт
Бар дөньяга шартлап ут тулды.
Бер мизгелдә, бары бер мизгелдә
Бөтен шәһәр янып көл булды!
Табигать, син ничек түздең икән
Коточкыч бу вәхши җәбергә?
Ак парашют күргән балаларың
Әле һаман керә кабергә.
Самолётын алып кайтты исән,
Шәп очучы Клод Изерли*.
Җан өшеткеч приказ үтәгәнен

* К. И з е р л и – Хиросимага атом бомбасы алып барган очучы. Соңрак акылдан яза.

Ул әлегә аңлап бетерми.
Еллар үтәр, ул да каргый башлар
Аяусыз һәм дансыз язмышын
Һәм ишетә башлар, төн йокламый,
Янып үлгән шәһәр тавышын.
Күз алдына килер һәр төн саен,
Бомба төшеп киткән минутлар,
Ә аннан соң урам буйлап чапкан,
Ике аяклы, тере, күп утлар.
Кычкырырлар алар ярдәм сорап,
Шәһәр тулы тере күмерләр.
Бу күмерләр аңа йокы бирмәс,
Елап төшләренә кererләр.
Ул минутлар искә төшкән саен,
Үкенергә мең кат өлгерер,
Колакларын каплап, юләрләнеп,
Үлем эзләп чыгып йөгерер...
Кеше юлы һәм ут юлы шулай
Кисештеләр еллар аркылы.
Үзе кылган эшне сыйдыралмый,
Җимерелде кеше акылы...

Табигатьнең хакыйкате үз эчендә,
Һәрбер чәчәк, һәрбер бөҗәк үз төсендә.
Һәр ялгышның, һәр уңышның үз сәбәбе,
Һәрбер эшнең үз Вакыты, үз сәгате.
Ләкин кеше бит сәбәпне кора белә!
Куркынычны кире якка бора белә!
Чорлар аша салып килгән үз юлында,
Үзе тапкан утның биге үз кулында.
Аңа акыл да табигать бераз биргән,
Биргәч-биргәч, нигә аны бик аз биргән?
Күпме әле Җирдә чикләр һәм киртәләр?
Күпме әле канга буялган иртәләр?
Шахталарга яшерелгән корыч уклар,
Ук очында коточыргыч кызу утлар.
Борынгылар ут саклаган кебек, бүген

Коткар, акыл, бу уклардан тормыш күген!
Юк, табигать аз бирмәгән безгә акыл,
Ут белән ул һаман үлчи аның хакын.
Акыл җиңә утны, тормыш алга бара,
Уклар сына, утлар тына, Җир яңара.

Ә башкача һич тә булмас, без – мәңгелек.
Һәм табигать үзе тормыш бит иң элек.
Безне сынап, и Ходаем, ни эзлисең?
Сыный-сыный нинди эшкә әзерлисең?

Яшенгә кул сузган кеше
Исән калды, үлмәде ул.
Очы ут алган күсәкне
Җибәрмәде кысылган кул.
Беренче яңгыр тамчысы
Аны һушына китерде.
Чыланганчы нәни утны
Чыбык-чабыкка ул төрде.
Ә аннан соң саклап кына,
Адым саен эзләп утын,
Алып кайтты кабиләгә
Үзе җуйган яшен утын.
Төннәр буе йокламыйча
Кайткангамы утны саклап,
Вафат булды кайтып җиткәч,
Ләкин үлде, үзен аклап.
Мәңге сүнмәс хәтер булып,
Уты калды бу дөньяда –
Иң беренче мәңгелек ут,
Иң беренче таш ояда.
Тормыш өчен яшеннән ут
Алып, башын салганнарга
Һәйкәл булсын Мәңгелек ут,
Хәтер булсын калганнарга...

**Бакча**

Түбән очта, зират янында ук,
Бар иде бит бакча кисәге.
Бүгенге шул ятим җиргә карап,
Ямьле чагын күрәм кичәге.
Туган якның гүзәл почмагында,
Җирдә аунап безнең шикелле,
Үсте анда сусыл кыярлар да,
Бөртек-бөртек яшел сипкелле.
Ә әниләр анда кыяр җыйды,
Бергә-бергә «әбәт» ясадык –
Урталайга ярып һәм тоз сибеп,
Ипи белән кыяр ашадык.
Зираттагы авыл мәрхүмнәре
Чәчәк булып безгә бактылар,
Шыгырдатып безнең сусыл кыяр
Ашаганны тыңлап яттылар.
Хәтердә тик чаткы гына калган,
Үткән көннәр – сүнгән учаклар.
Ничек тәмле иде ул кыярлар!
Нинди ямьле иде ул чаклар!

Бишекләрдән күтәрелде башлар,
Җиргә очты кысыр имезлек.
Әниләрнең итәгеннән төшеп,
Сукмакларга беркөн сибелдек.
Сукмакларның сәер үзлеге бар –
Түбән очка һәрчак илтәләр.
Күз алдында сусыл кыяр ята,
Бик тәбәнәк кебек киртәләр.
Каравылчы Вәли абзый әнә,
Башын кыңгыр салып, җыр көйләп,
Үз өенә таба менеп бара,
Кайчан төшәр кире, кем белә?..
Кемдер инде койма аша кергән,
Кыяр өзә, ялт-йолт каранып,
Изүенә сала һәм исәпли
Вәли абзый үткән араны.
Дер калтырап кыяр умырганда,
Бар тирә-як шомлы тоела.

Каешсыз буш чалбар бөрмәсеннән
Җыелганы кире коела.

Вәли абзый төшеп килә инде,
Кай арада ашап өлгерә!
Бакчадагы каракларны күреп,
Артларыннан куа, йөгерә.
Ул яшь түгел инде, тыны бетеп,
Куа соңгы барлык көченә.
Ә малайлар черек койма аша
Сикерәләр зират эченә.
Ләкин Вәли абзый – әллә инде
Мәрхүмнәрдән бераз шүрләде –
Юк сәбәптән зират туфрагына
Аяк басуны хуп күрмәде.
Безгә зират ерак төшенчә бит,
Ә ул үләр көнен уйлады,
Хәрәм кыярларның үз бәясен
Зираттан да олы куймады.
Җыеп алды җирдән кыярларны,
Йөгергәндә бездән коелган.
Җыр көйләде тагын. Юкка гына
Безгә усал булып тоелган.

Усал булган ул да, үткән чакта
Европаның утлы юлларын,
Чабар өчен вәхши фәлсәфәнең
Илне буган канлы кулларын.
Бөреләнгән кыярларны ташлап,
Яу кырына алар киткәннәр.
Тыныч, тәмле, йомшак «кыяр» сүзен
Сугыш тәртәсенә җиккәннәр.
«Кыяр кирәк! Кыяр кирәк!» – дигән
Кече сержант мәхшәр көнендә.
Хәтта тормыш кыл өстендә чакта,
Менә шундый сәер элемтә.
«Кыяр кирәк!..» Димәк, озакламый,
Миномётның уты өзелә.
«Кыяр кирәк!..» Димәк, мина кирәк
Ыргытырга дошман өстенә.
Миналар юк, алар чолганышта,
Инде боҗра якын һәм тыгыз.

Соңгы хәбәр: «Тозлы кыяр кирәк!»
Димәк: «Безнең өскә атыгыз!»
Шулай була, иле өчен солдат
Икеләнми сала гомерен
Шул кабергә, әгәр ала алса
Үзе белән дошман өерен.
Хакыйкатькә тарих аяк чалса,
Хакын җуя фани әйберләр.
Европада яисә Азиядә
Аз булдымы андый каберләр?
Үз гомерен чүпкә санап түгел,
Ил гомерен куеп югары,
Каберләрдән күтәрелеп, безнең
Күзгә карый Ватан уллары.
Бурыч таләп итмиләр һич алар,
Зарланмыйлар сару кайнатып.
Тик шулай да, әйе, тик шулай да
Рәнҗиләрдер кебек кайвакыт.
Бер ялвару бары бу күзләрдә,
Булмаса да һичбер үкенеч:
«Онытмагыз безне!» – бу алардан
Безгә соңгы, өнсез үтенеч.

Беркайда да юктыр, ахры, җирдә
Чирәм баскан зират юллары.
Каберләрне барлап, җыештыра
Исәннәрнең җылы куллары.
Ә авылда үлем-китем булса,
Кабер казу төшә ир-атка.
Вәли абзый башка ирләр белән
Төшми калмый иде зиратка.
Күз алдымда һаман ындыр юлы:
Көрәк тоткан олы абзыйлар,
Салмак атлап, түбән очка төшә,
Димәк, бүген кабер казыйлар...
Бу көннәрдә алар күп сөйләшми,
Тынлык саклый таныш каберләр,
Чүп күренә кайбер вак ызгышлар,
Онытыла үпкә-җәберләр.
Вәли абзый башын кыңгыр салган,
Кыяфәте берни сөйләми.
Атлавы да элеккеге кебек,
Җырын гына ләкин көйләми.

Хәтергә дә Вакыт аяк чала,
Онытыла кайчак каберләр.
Хакыйкатьнең хакы истән чыкса,
Баш күтәрә фани әйберләр.
Тормыш өчен гомер биргәннәр бар,
Яннарыннан үтик яланбаш.
Тапталмасын мәрхүмнәрнең рухы,
Уяулыгың җуйма, замандаш!
Тук гамьсезлек җанны алдамасын,
Күңел күзен ябып, йоклатып.
Хәтеренә кеше үзе хуҗа,
Ә кешегә хуҗа тик Вакыт.
Буыннардан буыннарга үтеп,
Йөрәк янсын, күңел моңлансын.
Тынгысыз җан җирдә һәр бөҗәкнең,
Һәр үләннең зарын тыңласын.

...Вәли абзый озак яшәмәде,
Әҗәл килде – өзде сулышын.
Әллә сәбәп ачлык елларымы?
Әллә Бөек Ватан сугышы?
Җыелгандыр, ахры, барысы да,
Һәр ел саен йөрәк кысылган –
Тук еллар да, хәтта, төзәтмәслек
Тирән яра аңа сызылган.
Бушап калды авыр еллар йөген
Тартып килгән ябык беләге.
Туктамады тормыш, тик шулай да
Какшады күк авыл терәге.
Көрәк тотып, ындыр юлы буйлап
Төшеп бара әнә абзыйлар.
Вәли абзый гына юк анда тик,
Димәк, аңа кабер казыйлар...
Ул зиратка керде бөтенләйгә,
Язын чәчәк булып үреләә.
Койма аша аңа аннан башка
Ятим калган бакча күренә.
Авыл инде, шөкер, ярлы түгел,
Өйләр иркен безнең, тамак тук.
Агрономнар, тракторчылар бар,
Кыяр үстерүче генә юк.
Минем хыял агач сука түгел,

Тракторга без дә куандык.
Калды кебек тимер чолганышта
Җир-су белән рухи туганлык.
Коллыгында әрсез чүп үләннең
Бәрәкәтле туфрак тилмерә.
Койма череп ауган, ә малайлар
Хәзер күбрәк кәнфит кимерә.
Авыллар да картаялар икән...
Яңа тормыш кызу һәм әрсез.
Югалсалар әгәр ул кыярлар,
Югалырбыз без дә хәбәрсез.
Кыяр кирәк! Нindidер бер моңлы
Күңел кылы, димәк, өзелә.
Кыяр кирәк! Туры карар өчен
Авыл мәрхүмнәре йөзенә.

Мәрхүмнәрне, зират-каберләрне
Бераз артык, ахры, борчыдым.
Бөтерелеп китсә, туктыймы соң
Хәтер-моңнар, уйлар орчыгы?
Сузыла җеп ерак еллар аша,
Бөтерелә орчык каләмем
Һәм китерә миңа балачакның
Сагынычлы, моңлы сәламен.
Сизми калдык замананың безне
Тормыш тәртәсенә җиккәнен,
Урлап качкан авыл кыярларын
Кайтарырга вакыт җиткәнен.
Һич булмаса, калган орлыкларны
Вакыт инде җиргә салырга,
Карт авылның Олы Тарих йөген
Үзебезнең кулга алырга.
Вакыт инде нәсел-тарихыңны
Балаларың җыеп сөйләргә,
Үз телеңдә үз җырыңны көйләп,
Үз бакчаңа сулар сибәргә.

...Җырлар өздем хәтер бакчасында,
Камиллеккә, моңга ашкынып,
Һәм йөгерәм кызу заман буйлап –
Арттан куа Вакыт ташкыны.
Вакыт куа. Вакыт аяусыз ул.

Мин йөгерәм алга... зиратка.
Мин йөгерәм. Өзгән хатирәләр
Бәреләләр талгын йөрәккә.
Бу замана тоташ йөгерештә,
Күпме байлык җиргә коела.
Хәтерсезләр рухи хәлсезлектән
Егылырлар кебек тоела.
Тарих өчен афәт түгелдер бу,
Ә бары тик Кояш баешы.
Ачык булсын күңел изүләре,
Кысып бәйлик хәтер каешын.
Әйләнүдән Җир туктамас әле,
Иртән Кояш тагын кабыныр.
Без югалткан яшел кыярларны
Җыючылар әле табылыр.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Кирәк булса, уттай балкырлык
Һәм алардан рухи мирас безгә –
Тырыш хезмәт, тыйнак батырлык.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Күпне биреп, азны алучы.
Илнең тере тарих сәхифәсе,
Татар авылының намусы.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Алар бизи тарих сәхнәсен.
Алар белә тормыш хакыйкатен,
Алар аңлый яшәү мәгънәсен.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Яу кырында башын салганнар.
Сугышсыз бу якты көннәр хакын
Белә бары исән калганнар.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Китеп бара алар, үкенеч.
«Онытмагыз безне...» – бу алардан
Безгә соңгы, өнсез үтенеч.

**Фатыйма мәхәббәте**
**1. Фатыйма**

Каян алып, нинди сүзләр белән генә
Ясыйм икән, Фатыймакай, сурәтеңне?
Каләм алып кәгаземә кагылырга
Куркып торам, Фатыймакай, күрәсеңме?
Ничек кенә таушалган сүз, ялган белән
Кагылмаска синең матур исемеңә?
Сүз күп бездә, тик күбесе ясалма моң,
Чүп кичереш, буш хыяллар ише генә.
Шаулы хисләр, гамьсез сөю ялкыннары
Туң җаннарны эретерлек түгел инде.
Ә син авыл юлларыннан килеп кереп,
Сискәндереп, өтеп алдың күңелемне.
Искитәрлек катлаулы бу тормыш җирдә.
Уйлый-уйлый кайчак хәйран каласың да
Бер күрәсең – нинди упкын икән бергә
Гомер иткән ике кеше арасында.
Гаҗәп кайчак кинәт, кискен борылышлар,
Күпме серләр, күпме яшерен агымнар...
Сорауларга җаваплар юк, тик шулай да
Тауларга каршы агарлык бер агым бар.
Серле, шашкын һәм яшерен дә бу агым,
Күпме сорау анда, күпме гади җавап –
Кешеләрнең тазалыгын үлчәп була,
Күңелләрдә булган мәхәббәткә карап.
Фатыймакай, күңелеңнең бөеклеге
Кермәгәндер синең тыйнак уйларыңа.
Тәннәреңне җимерерлек бу кодрәтең,
Сыймагандыр нәзек, зифа буйларыңа.
Син бик ерак инде бездән, чиксез ерак.
Монда хәзер үзгәрешләр, тизләнешләр.
Сезнең авыл да, Фатыйма, бер яшәрер,
Абынмыйча алга барыр тиздән эшләр.
Тик үзгәрми торган әле нигезләр күп –
Моңлы хисләр беркайчан да искермәсләр,
Көз җитмичә агач тизрәк җимеш бирмәс,
Аналар да тизрәк бала китермәсләр.
Хәер, Җирдә нинди генә ачыш булмас,

Тик Кешелек, нигездә, бик мәрхәмәтле –
Кабул итмәс үзгәрешле тиз хәтерне,

Тизләнештә яңартылган мәхәббәтне.

Вакыт житкәч, Фатыймакай, синең янга
Килсәм иде моң илендә сакта торып,
Исемең белән сискәндереп тук җаннарны,
Нигезләрдән аермаслык җыр калдырып.
Ә бу җырны мин язмадым. Үзем түгел,
Каләмемне йөртте сәер, моңлы тылсым.
Ул тырышты, Фатыймакай, үзең төсле,
Сурәтең дә якты, гүзәл сынлы булсын.
Мин бары тик карышмадым сихри көчле
Каләмемне йөрткән якты истәлеккә.
Аянычлы, аянычлы булды бу җыр,
Гомер кайчак сыя икән бер тәүлеккә.
Рәхмәт сиңа, Фатыймакай, көтмәгәндә,
Сискәндереп, өтеп алдың күңелемне.
Бер башлагач, сүз табыла. Ни әйтсәң дә,
Синекедәй йөгем авыр түгел инде.
Кил, илһамым, канатлы ат булып миңа,
Тапталмаган яшел чирәм якын-тирәм.
Гомеремнең тәүлекләрен, икеләнми,
Мәхәббәт һәм хәтер өчен өзеп бирәм.

**2. Фажига**

Болай башланды фаҗиганең тарихы –
Чирләп егылды Фатыйманың Салихы.
Кичкә таба төгәлләп ул барлык эшен,
Капкан иде бер утырып тәмәкесен.
Суырды да катып калды мескен хәлдә,
Бар дөньяны каплап алды кара пәрдә.
Эһ тә итми ул сыгылып төште җиргә,
Хәлсезләнеп, батты юеш, салкын тиргә.
Бөтен тәнен кысып алды утлы кыршау,
Ишетелде агымсудай сәер бер шау.
Бу – шуышып килгән әҗәл шавы иде,
Кыяфәте аның хәсрәт тавы иде.
Күләгәсе – кара пәрдә, килде алдан,
Әҗәлгә бер адым гына ара калган...

Кичке ашка чакырырга чыккандырмы –
Фатыйма бер мизгел һуштан язып торды.

Искә килеп, су китерде Салихына.
Кара күләгә чигенде бераз гына.
Коткарыгыз! Коткарыгыз бу бәладән!
Бар әле, бар алда гомер яшәлмәгән!
Читенсенми күзләренә туры карап,
Көйсез чакларында карышусыз ярап,
Ашлар салып тәлинкәсенә, тутырып,
Кара-каршы чәйләр куертып утырып,
Мәшәкатьтән мәхәббәткә күчкәч төннәр,
Урын җәйгән саен салып ике мендәр,
Тупырдатып балаларын, оныкларын,
Югын бар итеп һәм саклап кына барын,
Бар әле бар алда гомер яшәлмәгән!
Коткар, Ходаем, Салихны бу бәладән!

Бәладән зиһен чуалса, ни кылырсың?
Алла түгел, әллә кемне чакырырсың.
Буш авылда, заман юллары читендә,
Яшәү тыныч, ләкин кайчак бик читен дә.
Кече авыл заман исәбеннән чыккан,
Адәм түгел, Алла да аны оныткан.
Элемтә дә, табиб та юк анда хәтта,
Күпме бәхәс кызып алды бит бу хакта.
Бәхәс булды ләкин, яклап туган җирне,
Нык тамырлар үз йортында кала бирде.
Калды тагын, сукыр күзләр кебек, гамьсез,
Гөл үсмәгән тәрәзәләр җансыз, ямьсез...
Кая гына, кемне генә эзләп барма –
Карт алаша бар авылда, ватык арба.
Фатыймага соңгы өмет – шул ат калды,
Җигә белде, арбага Салихын салды.
«Әйдә, малкай, коткар безне, атла тизрәк,
Әҗәл куа, өлгерергә безгә кирәк.
Соңгы тапкыр коткар безне, эшләр яман,
Игелекле мал, диләр бит сине һаман.
Соңгы булыр сиңа, малкай, бәлки, бу юл,
Шулай кирәк, кичер, зинһар, һәм... бәхил бул.
Кичер, малкай, җаным елый, йөрәк яна,
Суккан саен дилбегә белән аркаңа.

Тынсыз ята иң кадерле кешем минем,
Әҗәл куа, юк башкада эшем минем.

Исән калсак, карт күңелең итмәм китек,
Кадер-хөрмәт белән риза-бәхил итеп.
Коткар, малкай, тик син генә бар терәгем,
Рәнҗеп китмә, чыдамаса карт йөрәгең».
Фатыймакай елый-елый атын куа,
Күз яшьләре белән шул гөнаһын юа.
Карт алаша өркеп дөньясын оныткан,
Киерелгән күзләренең агы чыккан.
Юып була гөнаһларны елый-елый,
Тик әҗәлдән елап кына качып булмый.
Әҗәл куа арттан кара шәүлә кебек,
Өчесенең берсен алачагын белеп...

Картлыктамы, саулыктамы – кайда гаеп?
Ат чайкала башлый тиздән хәлдән таеп.
Газапларның бу әле тик башы гына,
Көтмәгәндә каерылып, тәртә сына...
Нишләр иде монда акыллырак адәм?
Утырыр да елар иде, көтеп ярдәм.
Ләкин туктатып булмады Фатыйманы,
«Юләрлектән» аны акылы тыймады.
Бәла килсә, һәркемдә көч арта диләр,
Тарталмаслык йөкне кеше тарта диләр.
Аты күренми, тик арба алга бара,
Фатыйманың кызу тәнен каеш яра...
Нинди өмет белән үзе җигелгәндер,
Әҗәл дә тетрәнеп бераз чигенгәндер.
Шаккаткандыр хәлсез карт алаша хәтта,
Арба һаман хәрәкәттә, хәрәкәттә!
Әкият һәм юк-бар могҗиза сөйләмим,
Могҗизаның тормыш икәнен беләм мин.
Тормыш шул бу. Сакла, илһам, чүп-чар сүздән!
Фатыйма да хәлсезләнеп туктар тиздән.
Әкрен генә сыгылып төшәр тезләренә,
Кирәк чакта юк машина эзләренә.
Сыгылып төшәр, тик туктамас ул өметсез,
Сырхау иргә кул селтәмәс игелексез.
Җилкәсенә салыр аны ахыр чиктә,
Коткарырга, коткарырга теләр бик тә.
Шул йөк белән әҗәлдән ул качып килә,

Тик әҗәл дә эзләренә басып килә.
Күләгәсе төшеп килә үзләренә,

Фатыйманың тоныкланган күзләренә.
Күңелендә сөйгәне, тик бер ул гына,
Күзләрендә кара пәрдә һәм юл гына.
Көч таба ул мәхәббәткә тугры калып,
Алда калган гомер исәбеннән алып.
Алда әле үтеләсе күпме юл бар,
Җир чайкала, калтырыйлар аяк-куллар.
Юл читендә баганалар... баганалар...
Юлны түгел, гомерне үлчәп калалар.
Кара шәүлә булып арттан кырлар аша,
Әллә әҗәл килә, әллә карт алаша...
Юк, мин һич тә чүп-чар әкият сөйләмим,
Чын бәясен бу могҗизаның beләм мин.
Изге могҗиза бу! Илһам, сакла юк-бар сүздән!
Фатыйма бит бөтенләйгә туктар тиздән...
Шифаханә баскычына йөген салыр,
Ишек шакыр, башын күтәрми тын алыр.
Ишек ачык. Кемгә монда ярдәм кирәк?
Ә Фатыйма һаман шакый: тизрәк! тизрәк!
Соңгы тамчы көчен алган бер ишарә –
Салихына төртеп күрсәткән, бичара.
Һәм тынычлап ятып калган, изрәгән дә,
Йөрәгенең туктаганын сизмәгән дә.
Унбиш чакрым куып килгән әҗәл арттан,
Ә баскычта Фатыйманы гына тапкан...
Сөенечле хәбәр әйтергә чыкканнар –
Фатыйманың гәүдәсенә абынганнар.

**3. Салих**

Таң ата сызылып, таң ата кызарып,
Уяна басулар, урманнар.
Машина артыннан, ургылып-ургылып,
Агыла юлдагы тузаннар.
Машина эченә салынган мәетнең
Ак җәймә ябылган битенә.
Күптәнме әҗәлдән котылган Салих та
Утырган ак җәймә читенә.
Фатыйма янында, моңаеп, уйланып,

Кырларны күзәтеп кайта ул,
Уйлары иркендә. Беркем дә әйталмас –

Якынмы, еракмы – кайда ул?
Бер ватык арба юл читендә күренде,
Янында ауный карт алаша.
Аңламый, танымый үтмәстер, шәт инде,
Көчәнеп хәтерләп караса...

Мәетне юганда, аптырап, шаккатып,
Карчыклар елаган тын гына –
Пар күкрәк арасын сыдырып сузылган
Җәрәхәт алиһә сынына.
Салихның сагышын багарлык дәртем юк,
Күңеле ачылмас йозаклы.
Озакка сузмыйча (татарда шулай бит),
Мәетне зиратка озатты.
Ике көн моңайды... Дүртенче көн үтте...
Биш көннән төзәтте арбаны.
Кичен карт алаша җигелде... Тик Салих
Печәнгә, утынга бармады.
Килделәр ипле бер тол хатын йортына.
Капканы әллә җил ачтымы?
Ашыгып арбага төялде кемнеңдер
Сандыгы, юрганы, ястыгы...
Болытлар җыела. Яңгыры булырмы?
Ә ялгыз каенны җил бөгә.
Каеннан чишелеп, алаша өстенә
Сызгырып төште куш дилбегә.
«Йә, малкай, кузгалыйк, тиз атла, югыйсә
Чыланыр ястыклар, юрганнар!»
Ә артта болытлар, төн кебек күләгә,
Күренми басулар урманнар.
Атлый карт алаша иснәнеп, пошкырып,
Киләме кемнедер таныйсы? –
Фатыйма тәненә ышкылып уелган
Каешта тир исе, кан исе...
Борынын киереп, күзләрен тутырып,
Алаша борылып карады.
Арбада таныш ис хуҗасы күренми,
Караңгы ул якта, караңгы.
Арбада чит хатын, ястыгын кочаклап,
Юрганын ышыклап утыра

Һәм башын күтәреп болытка карый да,
Салихка атны тиз кудыра.

Тузаннар туздырып, урамны тутырып,
Кем кайта Салихның йортына?
Җавап күп көттерми – озын куш дилбегә
Сызгырып төшә ат сыртына.
Чайкала алаша, гәүдәсе калтырый, –
Белмиләр кешеләр чаманы.
Йорт саен ул әрнеп узылган елларын,
Арттагы юлларын санады.
Ташылды ничә ел утыны, печәне,
Капчыклап ташылды икмәге.
Тик әле беркем дә кан исе бөркелгән
Каешка уратып җикмәде.
Авырмы югыйсә ястыклар, юрганнар...
Ә бәлки, ояттыр аңа да?
Егылды ул кинәт, Салихның йортына
Җитәргә өч адым арада.
Әллә бу түзмәслек сызлану булганмы?
Әллә бу әрнүле юл еккан?
Беренче тапкыр ул җигүдә егылды,
Картлыктан булмаса, хурлыктан.
Яшьнәде яшеннәр, күкрәде дөньялар,
Күктән су коелды чиләкләп.
Ә Салих күтәргән яңа мал-мөлкәтен,
Йөгерә кәләшен җитәкләп.
Алаша яңгырда чыланды, хәл алды,
Беркемне дә яшен сукмады.
Тузаннар басылды, игеннәр яшәрде,
Табигать ярсудан туктады.
Кич керде йортларга, кабынды утлар да,
Сузылып төн ята түбәгә.
Буш арба урамда. Алаша юк анда.
Пәрдәгә төшә пар күләгә.

Кызарып-кызарып, оялып таң ата,
Уяна басулар, урманнар.
Салихның йортында бернинди сагыш юк,
Коймада кибә чит юрганнар.
Яңа кич җитүгә, күмәк бу юрганнар
Кыйнала-кыйнала кагылыр.

Фатыйма исеме, тузанга әйләнеп,
Басулар өстенә агылыр.

**4. Хәтер**

Тыныч тормыш телим сиңа, Салих,
Озак яшә, башка чирләмә.
«Шәхси тормышыма тыгылды» дип,
Шагыйрьне син берүк тиргәмә.
Чын күңелдән минем бу теләкләр.
Яраткан бит сине Фатыйма.
Шул хисләргә лаек бәндә булып,
Кайчак, киләсең күз алдыма.
Гомер – яшәр өчен. Ахыр чиктә,
Кемдә кемнең нинди эше бар?
Бар икән шул. Җирдә үз гомерен
Безгә бүләк иткән кеше бар.

Мәңге яшәр өчен килгән кебек,
Нык нигезләр, йортлар салырга.
Соңгы көнне яшәгәндәй, көн дә
Сөйгәннәрне сөеп калырга.
Әйе, безгә! Туган халкыбызның
Хакы бардыр мондый шөһрәткә.
Кемдер кирәк һәйкәл куяр өчен
Күктән төшмәгән бу кодрәткә.
Һәркемгә дә тормыш – соңгы тапкыр.
Беренче һәм соңгы, ахыргы.
Бер гомердә хәлләр була кайчак
Бар дөньяга чаңнар кагарлык.
«Шундый вакыт...» дибез. Вакыт, имеш...
Аның бездә нинди эше бар?
Кешелекне саклап килә Җирдә
Кеше булып калган Кешеләр.

Фатыймакай, еллар узган саен,
Ерагая безнең арабыз.
Ләкин, хикмәт, ерагайган саен,
Сиңа таба без дә барабыз.
Очрашырбыз җирдә туфрак булып,
Якынлашып еллар буена.

Күтәрелеп җитә алмасак та
Синең бөек, зифа буеңа.

Фатыймакай, зиратыңа килеп,
Шаулап үлән үскән урында,
Кабереңә сибәм бу сүзләрне,
Уйлыйм һаман синең турында.
Иңгән кабереңә бу моңнарым
Сары яфрак булып коела.
Һәм юанам – син бу авазларны
Ишетәсең кебек тоела.
Кеше бөек. Син шул бөеклекнең
Җаны булып миңа дәшәсең.
Мин ишетәм сине...
Исемең Җирдә
Мәхәббәтне саклап яшәсен!

**Йорт иясе**
1

Бисмилламны әйтеп башлыйм әле,
Сөйләр сүзем – гыйбрәт маҗара.
Илаһи дәрт һәм таяныч кирәк
Чамадан тыш сурәт ясарга.
Үз күзләрем белән өрәк күрдем,
Ялгыз калган идем бу төндә, –
Боргаланып, күзләремне ачкач,
Айнып киттем кинәт бөтенләй.
Уңга-сулга сыгыла да төшә
Кара шәүлә ап-ак ишектә.
Котсыз калып, җиктем бар көчемне,
Һушым җыяр өчен ничек тә.
Җил-давыллы җәйге кара бер төн,
Күкне каплап болыт агыла.
Ни булды бу диеп, тәрәзәдә
Күренеп китте тонык Ай гына.
Күпне күрдем. Әҗәлнең дә инде
Килеп тотканы бар якадан
Һәм аптырап кире киткәне бар,
Килер өчен тагын, яңадан.
Җен-пәридән курку күптән беткән инде,
Әҗәлне дә алмыйм исәпкә.
Ләкин бүген һушсыз кала яздым,
Кара шәүлә күреп кисәктән.
Ул чайкала, ә мин һушым җыям,
Фикер йөртәм әкрен, кымшанмыйм.
Күптән беләм: хәвеф-мазар килсә,
Куркудан да начар дошман юк.
Тыныч зиһен белән, кабаланмый,
Мизгел буйлап уйлар ашыга
Һәм фикергә килә: куркыныч юк,
Йорт иясе тора каршыда.
Мин таныдым аны, иллә дә хак,
Таныдым да җиңел суладым,
Суладым да, моңсу хәтер белән,
Туган Йорт турында уйладым.

Искә төште күргән-белгәннәрем,
Маҗаралар, дөнья серләре,
Иясез йорт идәненә төшеп,

Аунап яткан сәгать герләре.
Моңсу уйлар... Ерак истәлекләр...
Йорт иясе һаман чайкалды,
Һәм таралды болыт, күк йөзендә,
Китек тәңкә булып, Ай калды.
Бисмилламны әйтеп башлыйм әле,
Игълан өчен түгел базарда,
Савап булсын әби өйрәткән сүз,
Изге илһам булсын язарга.

2

Сиксән яшьлек Хәербанат карчык ялгыз,
Җиңеләйгән бу бераз дип уйламагыз.
Сөйләшә ул кем беләндер, үзе генә,
Кеме белән сөйләшкәнен үзе белә.
Кайчак, кемне тыңлагандай, тынып кала,
Аннан тагын моңын-зарын сөйләп ала.
«Югарочтан тракторчы Габделбарый
Сирәк айный, тик шулай да эшкә ярый.
Бетәмени йомыш-җитешләр вак-төяк,
Бүген менә утын алып кайтты төяп.
Җиде йөз ат көчле тимер тарантаста
Җиде түмгәк утын тәгәрәшеп ята.
Актарылды капка янындагы чирәм,
Җитмәсә, бер ярты сорый теге бирән.
Әйтмәс идем битен ертып, ләкин көн дә
Бу ыштыр бит һаман хайван өммәтендә.
Хатыны да китте күтәреп баласын,
Чыдар әмәлең юк икән, ни кала соң?
Ә бу эчә, кәсеп булгачтын эчәрлек,
Курыкмый да Алла каһәре төшәр дип.
Җитмәсә, шул кибетен дә яптырдылар,
Хәмер белән көрәшүче «акыллылар».
Денсез сәүдәгәрләр хәзер симерәләр,
Күз яшьләре сатып, дөнья җимерәләр.
Күпме кыен ашап монда михнәт чиктем,
Сугыш чыккач иген иктем, урман кистем.

Үз утыным ничек кисим, ничек ярыйм?
Кем янына хәзер башым иеп барыйм?
Оныттылар тук бәндәләр иманнарын,
Бер рәхмәтнең мең бәладән коткарганын.

Торам дисәң, тыныч тормыш күреп булмый,
Үләм дисәң, тиктомалга үлеп булмый...»
Сиксән яшьлек Хәербанат карчык ялгыз,
Җиңеләйгән бу бераз дип уйламагыз.
Кеме белән сөйләшкәнен үзе белә,
Берьялгызы бу дөньяда, үзе генә.
Китеп бара «ахырзаман тарантасы»,
Урамдагы чирәмнәрне изеп-басып.
Авыраеп ярты айлык пенсиягә,
Үргә көчкә менә гүя таш төягән...

3

Сәрхуш Габделбарый беркөн тракторда
Аммиаклы су сибәргә кырга чыккан.
Башы чатнап, кәефе юк чагы икән,
Шуңа күрә Габделбарый бик ашыккан.
Тамак өчен без хәзер бит барыбыз да
Ашламага әсир төштек инде күптән.
Ләкин сәрхүш Габделбарый бик ашыккан,
Аммиаклы суны саф инешкә түккән.
Мәшәкатьле вакыт булган икән кырда,
Кем тикшереп-белеп торган эш барышын?
Исәпләнгән ашламаны Барый, имеш,
Кырга сипкән, калдырмыйча бер тамчысын.
Буй-буй яшел, кызыл канатлы балыклар
Агуланып калкып чыккан берәм-берәм.
Кайберләре судан ярга сикергәннәр,
Нәрсәгәдер соңгы сәер өмет белән.
Тик ул балыкларны Барый күрмәгән дә,
Борчылмаган һич тә ни кылганын уйлап.
Җигүдәге җиде йөз ат көче белән
Төшемле эш эзләп киткән авыл буйлап.

...Инде кичке эңгер-меңгер төшкән булган,
Инде тынган савыт-саба, чүмеч-чиләк,

Инде тәрәзәләр саен ут кабынган,
Инде Барый эчкән булган күпме кирәк.
Түбән очтан Хәниф белән тал төбендә
Очрашкан, ди, югарочның Хәмдиясе.
Күргәннәр, ди, су буйлатып килә икән

Ап-ак яулык япкан бөкре йорт иясе.
Иелә дә нидер җыя, ди, тукталып,
Сөйләшә, ди, үзе белән үзе һаман.
Кара төндә шомлы шәүлә шаукымыннан
Аптыраушта калганнар, ди, яшьләр тәмам.
Тал янына килә икән нидер көйләп,
Әллә елап, әллә җырлап адым саен.
Ишетелгән аңлашылмый торган сүзләр:
«Ләхәүлә вә куәтә... ай, балакаем...»
Баскан җирен күрмәсә дә караңгыда,
Җиңел атлый икән үзе өрәк кебек.
Әйтерсең ул көн дә инеш буйлап йөргән,
Туып моннан берничә йөз еллар элек.
Балкый икән су буенда ак яулыгы,
Әйтерсең ул ак кәфенен ябып чыккан.
Кыяфәте белән үзе охшаган, ди,
Авылдагы бик борынгы бер карчыкка.
Бу шомлыкны күрсә, шүрләр иде,
Якынлашкан чакта шәүлә тал төбенә,
Заман кызы комсомолка Хәмдия дә:
«Әбәү, җаным!..» – дип елышкан егетенә.
Ә егете нишләсен соң, катып калган,
Чытырдатып ябышуга Хәмдиясе,
Ниһаять, бер киерелеп тын алган да,
Дер калтырап пышылдаган: «Йорт иясе...»
Яшьләр янында туктаган таныгандай,
Карап торган авыр сулап, сагыш белән,
Күз яшьләрен сөрткән алъяпкычын селкеп,
Сасы балыклар коелган итәгеннән.
Бер сүз әйтми киткән өрәк. Тал төбендә
Үле балык кына калган, ди, өелеп.
Буш тыкрык буйлап яшьләр йөгергәннәр,
Исән-имин калганнарына сөенеп.
Бер сүз әйтми кулын селтәп киткән өрәк,
Бер сүз әйтми киткән, әллә өмет өзеп.
...Бара торгач, буш мичкәгә терәлгәндер
Сасып яткан үле балыкларның эзе.

4

Көлешә яшьләр урамда –
Бар икән бит Йорт иясе!
Хәниф сөйли, аның сүзен

Җөпләп тора Хәмдиясе.
Алар сөйли, кемдер көлә:
«Кем ышансын уйдырмага!
Әбиеңә сәлам әйт, – ди, –
Килсен, имеш, утырмага!»
Иң кимендә сигез сыйныф,
Кем дип белдегез аларны!
«Әйдә төшеп карыйк, – диләр, –
Котыгызны алган ярны».
Елгыр, тәвәккәл егетләр
Утырдылар матайларга,
Акыртып бер газ бирделәр,
Юл тотып шик тулы ярга.
Төнге тын һаваны ярып,
Атылдылар берәм-берәм.
Кемнеңдер әтәче, куркып,
Вакыт җитми салды сөрән.
Тынып калдылар егетләр
Кисәк бу хәвефле төндә –
Матай утлары кисеште
Үле балык өемендә...

Капка төбендә аптырап,
Утыралар егет-кызлар.
Җемелдиләр, шомга салып,
Күктәге ерак йолдызлар.
Гәп сата яшьләр тын гына,
Сөйләп күргән-белгәннәрен.
Искә төшә серле сүзләр,
Догалары әбиләрнең.
«Күренә, ди, Йорт иясе
Песи булып, кеше булып.
Яши икән йә чормада,
Яки мич башында кунып».

«Сүгенергә дип, бер агай
Ачкан икән, ди, авызын –
Тибеп төшергән, ди, «теге»,
Мич башыннан чәй савытын».
«Кисеп уйганда бер малай
Атын миләш агачына,
Тикмәгә морҗадан кирпеч

Төшә язган, ди, башына».
«Яңа йортка күчә, ди, ул
Үз хуҗасы белән бергә.
Ияләшкән бәндәләрдән
Китми, ди, гомер-гомергә».
«Ни теләсә, шундый аваз
Чыгара, ди, кайберләре.
Күчергәләп йөрткәли, ди,
Өйдә кайчак әйберләрне».
«Мәчет манарасын кискән
Хәй абзый яшь, юләр баштан.
Йорт иясен төштә күреп,
Бу арада бик саташкан.
Килгән, ди, Банат түтигә,
Җыеп юк-бар соңгы көчен,
Сораган намаз укырга
Иске кыйбла юнәлешен».
«Аның белән дуслык булса,
Тими, ди, бернинди чир дә.
Тормыш бөтенләй бетә, ди,
Йорт иясе киткән җирдә».
«Дин өчен дә, фән өчен дә
Ачык түгел әле, ди, ул.
Аракы күп эчкәннәргә
Кайчак күренгәли, ди, ул.
Ярым-йорты шәүлә-сурәт
Әлҗе-мөлҗе килә икән,
Тиле-миле, азгын сәрхуш
Бу чирдән тиз үлә икән...»
...Барысы бар бу сүзләрдә,
Дин дә, җен дә, уйдырма да.
Тып-тын гына сөйләшәләр
Яшьләр төнге утырмада.

5

Инде тәрәзәләр саен утлар сүнгән,
Инде авыл татлы төшләр күргән күптән,
Инде яшьләр таралырга җыенганнар,
Инде төн уртасы чаң уйнатып үткән.
Сөйләшәсе сүзләр бетеп, нидер көтеп
Тыныч кына шулай утырган вакытта,

Бөтен тирә-якны кинәт сискәндереп,
Чәчрәп тәрәзә ватылган күрше йортта.
Тәрәзәдән очып чыккан Габделбарый,
Яшел-зәңгәр, ямьсез авазлар чыгарып,
Төнге тынлык, шомлы сүзләрдән сагайган
Егетләрнең сизгер колакларын ярып.
Кара төндә үтерәләр кемне диеп,
Якын-тирәнең уянган карты-яше.
Габделбарый урам буйлап йөгерә, ди,
Кычкыра, ди: «Йорт иясе! Йорт иясе!»
Башы-кулы канга баткан, ди, суелып
(Шул буладыр инде сәрхушләрнең чире),
Чабып кергән ачык капкалы бер йортка
Һәм шулай ук чабып чыккан аннан кире.
Җылы йокы түшәгеннән торып, өйдән,
Хәвефләнеп, инде һәркем чыгып җиткән.
Авыл буйлап бәргәләнеп йөри торгач,
Хәлдән тайган Габделбарый ахыр чиктә.
Бәласеннән баш-аяк дип, тыгыз бәйләп,
Кертеп салганнар Барыйны үз өенә.
Тыпырчынган әле озак һәм саташкан,
Аяк-кулы бәйле-тышаулы көе дә.
Банат карчык шунда «колһуалла» укып,
Өшкереп тә караган, ди, ул мескенне,
Барый, тынып, тонык күзләрен ачкан да
Сискәндергән, тагын кычкырып, һәркемне.
Иртән сырхауга куркулык кояр өчен,
Куар өчен бимазалы шик-шомнарын,
Банат карчык иртүк торып, намаз укып,
Алып килгән Коръәнен һәм им-томнарын.
Тик тиешле табибларга тапшырырга,
Киселгәнгә кулы-башы, күзе-кашы,
Алып киткән анны, арбасына салып,
Үзенең үк «ахырзаман тарантасы».

Инешне дә кире борып булмагандай,
Савыгу юк диләр инде мондый чирдән.
Ләкин Барый исән чакта, үз аңында,
Күргәннәрен бераз гына сөйләп биргән.
Җилкәсенә кулын салган аның кемдер,
Гырлап йоклап яткан чакта салган баштан.
Әйле-шәйле Барый башта унлык сузган аңа,
Бер «кызыл»га җибәрмәкче булган башта.

Ә биләмче кымшанмыйча тик тора, ди,
Гүя кергән йортка кемнеңдер Әҗәле...
Бу караштан өнсез калып шашкан Барый,
Ватып чыккан өендәге тәрәзәне.
Ә калганын сез беләсез... Ләкин Барый
Өлгермәгән сөйләп барлык күргәннәрен...
Елар кеше табылмаган бу мәхлукка,
Сөйләделәр ашык-пошык күмгәннәрен.

6

Банат карчык яткан үлем түшәгенә,
Күз карашын текәп агач түшәменә.
Үлем-җитем хәстәренең үз җае бар –
Бәхилләшә җыелышып карт-карчыклар.
Хушлашалар, күпме гомер кичеп бергә,
Өметләнеп ахирәттә күрешергә.
Ләкин карчык үлем түшәгендә ялгыз,
«Ялгыз» сүзе ялгыш диеп уйламагыз.
Алла колы ни язганын үзе белә,
Соңгы юл каршында һәркемүзе генә.
Юк хәрәкәт, юк мәшәкать – тик ялгызлык,
Котылгысыз, җан өшеткеч кара тынлык...
Инде күптән алып куеп, үзе теккән
Саф акбүздән кәфенлеген үлемтеккә.
Карап чыгып тыныч кына бар әйберен,
Күтәрергә кушкан кинәт сәгать герен.
Үз көенә яши адәм, үзе генә.
Көе сынса, үз вакытын үзе белә.
Өзелеп җан биргән шулай кичке якта...
Сәгать калган мизгел агымында сакта.
Җирләгәннәр иртәгесен мәрхүмәне,
Тик авылда җәйге мәшәкать күп әле.

Үлгән белән үлеп булмый дигән кебек,
Исәннәрдә дөнья гамедер иң элек.
Калган утынны алырга өйләдән соң
Китергәннәр үле йортка «җен арбасын».
Абзыкайлар утын төягән вакытта,
Кинәт гөрселдәгән нәрсәдер буш йортта.
Һәм ачылып киткән черек тәрәзәдән
Гөл чүлмәге җиргә төшеп тәгәрәгән.

Артыннан ук чабып чыккан ап-ак мәче –
Мәрхүмәнең соңгы бердәнбер иптәше.
Дөнья күргән авыл абзыйларын беләм,
Куркытырлык түгел юк-бар өрәк белән.
Ышанмыйча сихер-тылсым, җен көченә,
Ипләп кенә күз салганнар йорт эченә –
Идәнгә төшкән ычкынып сәгать гере,
Тик шул гына икән сәер аваз сере.
Ә күкесе авыз ачып катып калган,
Соңгы сәлам булып Җиргә сау еллардан.
Кычкыра ул, гүя кемдер буа аны,
Тик тавышы чыкмый, ахры, чыга җаны.
Кычкыра ул, гүя ничә ел буена
Зарлы сүзен әйталмыйча Җир буыла.
Гүя көтә безне бары бер киләчәк –
Ватык чүлмәк уртасында сынык чәчәк...

7

Шактый гына еллар узгач,
Онытылган сәер хәлләр,
Сер мәетләр белән киткән,
Ә зираттан юк бер хәбәр.
Еллар үтә, йортлар бушый,
Үлә-китә карты-яше.
Шуннан бирле күренмәгән
Беркемгә дә Йорт иясе.
Түбәдәге морҗаларны
Кочып елап китеп барган,
Каезланган, каешланган,
Чирәм беткән урамнардан.
Аккан гөрләвекләр булып
Түбәночка югарочтан,

Карлар булып яуган кышын,
Сары яфрак булып очкан.

Юк, әле ул тиз югалмас,
Бераз гына түзәр әле,
Орлык булып җиргә төшәр,
Агач булып үсәр әле.
Җаны барның күзләреннән

Тамчы булып тамар әле,
Тәлгәш-тәлгәш миләш булып,
Тәрәзәләр кагар әле.
Болыт булып кузгалыр да
Яңгыр булып килер әле,
Яшен булып күренер дә
Күкрәп сәлам бирер әле.
Без йокларбыз хәлдән таеп,
Тамак өчен фәхеш кылып,
Җирне талый-талый баеп,
Аракыга чират торып.
Нәрсә инеш? Нәрсә Барый?
Кем ишетә хәлсез зарны? –
Агулыйлар мизгел саен
Олы-олы елгаларны...
Шунсы гаҗәп: аек алар,
Зәгыйфь түгел, фәкыйрь түгел,
Йорт иясен ишетерлек,
Алар Җирдә шагыйрь түгел.
Яман төш күреп, саташып
Уяныр без әле без дә,
Җылынырга дип, үзебез
Ут төрткән үз өебездә.
Чәчрәп чыгар безнең җаннар
Күккә ашкан таш торактан.
Таш урамда мәет калыр,
Туган җирен кочып яткан...

8

Ә мин күргән шәүлә – тик күләгә
Урамдагы яшел агачтан.

Убыр түгел, җен-пәри дә түгел,
Газраил дә түгел адашкан.
Җилле төндә, лампа яктысында,
Чайкала ул ап-ак ишектә,
Кайгысы бар кебек сыгыла да
Турай макчы була ничек тә.
Нигә исә бу җил бертуктаусыз?
Ул мәңгелек түгел! Ул сына!
Ул бит шул ук, шул ук Йорт иясе!

Тик шул гына бары... Шул гына...
Тик шул гына иде әйтәсе сүз:
Безгә шундый тормыш эләгә –
Ишегенә һәркемнең дә инде
Килеп баскан кара күләгә.
Убыр түгел, җен-пәри дә түгел,
Фәрештә дә түгел адашкан –
Тик күләгә, әле кичә генә
Шаулап торган яшел агачтан.
Җил-давыллы, якты заманада,
Сыгыла ул ап-ак ишектә,
Буылып һәм соңгы көчен җыеп,
Тураймакчы була ничек тә.
Нигә исә бу җил бертуктаусыз?
Ул мәңгелек түгел! Ул сына!
Тик шул гына иде әйтәсе сүз...
Тик шул гына бары... Шул гына...

**Җинаять эше**

1

Болытлы кара төн төбендә
Тын калган караңгы авыллар.
Котырып-котырып җил исә,
Кайдадыр, күрәсең, давыл бар.
Җепшек кар кырларда, юлларда,
Кыш ае бит әле югыйсә.
Күкләрдә болытлар тәгәри,
Ыргылып-ыргылып җил исә.
Шаулашып чыршылар сыгыла,
Каеннар бөгелә чайкалып.
Шыгырдый капкалар, коймалар,
Түбәдән тамчылар тамгалый.
Сызгыра да улый – җил исә,
Офыкка, упкынга убылып.
Кайдадыр эт өрә, эт елый,
Җил искән авазга кушылып.
Яз түгел әле бу, кырларга
Юлларын бутаган җил керә.
Адашып йөргәнен белгәндәй,
Аңа да, чит итеп, эт өрә.
Урамнар буш калган. Авылда
Көндезге мәшәкать тиз тына.
Чырасын сүндергән күбесе,
Ут алган бер-ике йорт кына.
Ялгышып адашкан җылы җил
Йортларга сарылып зарлана –
Кышны яз итәрлек хәле юк,
Түбәдән тамчылар тамса да.
Төн үтәр, көн үтәр барыбер,
Киләсе төнгә кыш кузгалыр.
Басылган җылы җил юлында
Тайгак эз, мәкерле боз калыр.
Әлегә җылы җил кар кисә,
Көньяктан болытлар агыла.
Әлегә көн ягы адашкан,
Әлегә агым төн ягына.

Наратлар шаулашып сыгыла,
Тын гына чайкала каеннар.

Кайдадыр эт улый, эт өрә,
Кайдадыр, күрәсең, хәвеф бар.

2

Кырлар белән кырлар, урман белән урман,
Авыл белән авыл арасы.
Төнге юлда соңга калып, әкрен генә
Атлый ике адәм баласы.
Әтисе дә улы. Аркаларда капчык.
Тагын биштәр ята чанада.
Ачыкканнар, талчыкканнар инде шактый,
Икесе дә бер үк чамада.
Җепшек карга батып, җилгә каршы басып,
Сөенделәр күреп авылны.
«Ярый әле безгә итек киптерергә,
Ял итәргә урын табылды».
Әйтте әти кеше: «Түз, улым, түз бераз,
Хәл алырга өмет бар бугай.
Түз бераз, түз, ару гына сәүдә итсәк,
Өйләндерәм сине, кайтуга.
Күрәсеңме алда утлы тәрәзәне?
Ерак түгел, әнә тегендә.
Иплэп кенә койма кагып карыйк әле
Шушы ышык капка төбендә».
Кемдер ишек ачкач, бер тибрәнеп алды
Сөенечле өмет кылы да.
«Кем бар?» «Без һөнәрче юлчыларбыз идек,
Төн кунмак келибез җылыда».
Усал тавыш биргән хуҗа бәндә чыкты,
Ялт-йолт килде шомлы күзләре.
Баштанаяк карап бәя биргәннән соң,
Көтмәгәндә кисәк үзгәрде.
Бер алдында, бер артында юлчыларның:
«Әйдә, әйдә, рәхим итегез!
Мактап кына йөрисез лә икән безне –
Пешеп кенә чыкты итебез!»
Тешләренә тешләр тимәгәнгә инде,
Күзләрне дә күзләр күрмәде.

Йорт хуҗасы куштан Габделәхәт кенә
Үз уеннан үзе шүрләде.

Уйлар белән уйлар, юллар белән юллар,
Язмыш белән язмыш арасы.
Кайнар аштан изрәп, җылы мич башында
Йоклый ике адәм баласы.

3

Таң атканчы сәгать биштә үзе генә
Йөгереп кергән Габделәхәт күршесенә:
«Әй, Әхтәмҗан, тор әле, тор, уян тизрәк,
Аулак сүз бар, әүвәл киңәшергә кирәк!
Куна керде миңа Чистай мишәрләре,
Затлы тауар белән тулган биштәрләре.
Кесә-янчыклары да буш түгел бугай,
Сәгать биштә кузгалдылар тагын юлга.
Саба юлыннан Казанга барышлары,
Беркемгә дә ишетелмәс тавышлары,
Әгәр куып җитсәк урман уртасында,
Каенсарга китә торган юл артында...»
Юк, артык сүз кирәк түгел Әхтәмҗанга,
Барысы да аңлашылды күптән аңа.
Инкыйлабта күп кан койган бозык бәндә,
Большевиклар «яңа тормыш» төзегәндә,
Мәрхәмәтсез, таш йөрәкле, каты куллы,
Авылда да наган тоткан хаким булды –
Рәис иде сәвитләргә бик яраклы.
Чабатасын түргә элгән бу каракны,
Урлап ашамаса туймас иде, диләр.
Чын булганмы, сөйли иде карт әбиләр:
«Оялмыйча күзгә карап көпә-көндез
Мал-туарны алып китә иде денсез.
Ә урлагач мыскыл итеп көлеп тора.
Дәшми беркем. Наган – хуҗа. Закон – ерак.

...Инде менә ат иярләп чыгып чапты,
Бер гөнаһсыз ике башны бәреп ватты.
Утырды да җылы мәет аркасына,
Тәмәкесен тартып алды тыныч кына.

Гел җәзасыз калгач инде кем курыккан,
Аңа кан-яшь диңгезләре дә тубыктан.

Тик ялгышкан – утырганы мәет түгел,
Шөкер, монысы беркемдә дә гаеп түгел...

4

Каян куәт алып узгандыр ул
Урман белән авыл арасын –
Урам буйлап тере мәет килгән,
Кулы белән каплап ярасын.
Берәм-берәм халык җыелышкан,
Йорттан йортка хәбәр таралган.
Бите буйлап мишәр малаеның
Каны аккан ачык ярадан.
Үксеп-үксеп елый икән мескен,
Дер калтырап җылы өйдә дә.
Берәү әйткән: «Йә, тынычлан, улым,
Ни булганын тизрәк сөйлә дә».
Әйткән малай: «Йонлач бүрек тә, күн бишмәт...
Аркылыга куйды ул атын...
Балта тотып безгә каршы килде,
Аннан соң мин аңым югалттым...»
Кемдер тешен, кемдер йодрык кыскан,
Аркалардан суык йөгергән.
Күз яшьләрен сөрткән кайберәүләр,
Вакыт җиткән – хөкем өлгергән.
Талап, изеп, асып, кисеп була,
Эшчән халык юаш, түземле.
Ләкин чик бар. Шушы чикне узсаң,
Таптап, изеп узар үзеңне.
«...Җитте, улым, ял ит, аңлашылды,
Болай да бит инде ап-ачык...»
Бәреп кергән авыл агайлары
Әхтәмҗанның имән капкасын.
Мунча кереп ята икән хуҗа,
Чистарына, имеш, юына.
Күсәк тоткан агайларны күргәч,
Наган тотып чыккан кулына.
«Йә, Әхтәмҗан, ташла коралыңны,
Кан акмасын йортың-бакчаңда.

Соңгы сәгать җитте. Котылу юк,
Хәтта инде туптан атсаң да».

«Соңгы көнең житте. Шәфкать көтмә,
Артык озак түздек болай да.
Күзләренә кара авылыңның,
Урам уртасына чык әйдә!»
Күренә ки, нәфрәт чиктән ашкан,
Өмет тә юк. Булса, бик аздыр.
Атып егасың, ди, берсен йә икесен,
Бар авылны егып булмастыр.
Урам буйлап, капка, койма саен
Яше-карты чыгып тезелә,
Яланаяк килгән Әхтәмжанның
Төкерәләр кара йөзенә.
Чиста күлмәк, чиста ыштан кигән,
Күтәрелә ак пар иңеннән.
Әйтерсең лә үз вакытын белеп
Юынган да, актан киенгән.
Бала-чага, хатын-кызлар артта.
Үтенгән, ди, кырда Әхтәм бик:
«Кем сукса да, берәгәйле суксын,
Бер сугуда эшне төгәллик...»
Һәркайдагы кебек, соңгы теләк
Бу якта да төгәл үтәлгән,
Иң ярсыган, иң куәтле агай,
Тәвәккәлләп, күсәк күтәргән...
Күмәр вакыт житкәч, бәхәс купкан:
«Кайда гына казыйк каберен?
Изге зират сыйдыралмас моның
Бу дөньяда кылган җәберен».
«Юл астына салып күмик аны,
Кабердә дә тыныч ятмасын!»
«Юк, җәмәгать, мәет мәет инде,
Мыскыл итмик, Алла сакласын!»

...Юл читендә ялгыз, үксез кабер,
Авыл белән авыл арасы.
Билге булып, гыйбрәт, хәтер булып,
Үсә анда миләш агачы.
Кояш кызу, җил аяусыз анда,
Такыр аның якын-тирәсе.

Карт-карчыклар сөйли иде: «Менә
Әхтәмҗанның ачы миләше...»

Габделәхәт калды бер җәзасыз,
Шунсы гына менә бик начар.
Караңгыда калды, караңгыда,
Бу әләкче, куркак юлбасар.
Ләкин һаман бер үк сурәт керә
Төшләренә аның төн саен –
Күсәк тоткан кемдер капка шакый:
«Эш синдәдер монда, мөгаен...»
«Ә бит мосафирлар синдә кунган...»
Инде тыныч йокы юк аңа.
Ыңгырашып, чинап саташа да,
Тиргә батып, куркып уяна.
Хәтта көндез ишек шакысалар,
Йөгереп төшкән идән астына.
Инде әзер шуннан чыкмаска да,
Исән булсын бары баш кына.
Ничек шулай гомер итмәк кирәк?
Кайчан да булса бу бетәрме?
Эт тормышы дияр идем, ләкин
Яратам шул бик тә этләрне...

5

Фаҗигале бу тарихны
Сөйләгәннәр иде күптән.
Ерак калган шомлы көннәр,
Инде күпме вакыт үткән.
Мәрхүмнәрнең рухы миңа
Нигә тынгы бирми бүген?
Нигә көн дә нидер эзли,
Тыныч түгел һаман күңел?
Сүзләр җыям, сурәт ясыйм,
Салкын эзләр буйлап киләм,
Очраган бер авылдашка
Һаман бер үк сорау бирәм.
Тыныч кына сөйли алар,
Мине белеп бала чактан.
Эшчән, тупас кулларының
Буыннары шешеп каткан.

Уч төпләре дә кытыршы,
Җелекләре суырылган.

Җил ашаган чырайлары
Кояшларда куырылган.
Әйе, бүген әрни күңел –
Күзләремә авыл бага,
Язмыш аның башын ваткан,
Йөзе буйлап каны ага.
Таладылар илен, җирен
Һөнәрченең, игенченең,
Инде җанын алыр өчен,
Кисүчеләр булды телен,
Кылыч селтәп, мылтык терәп,
Кәгазь тотып, вәгазь укып,
Яу тамгасы – козгын кебек,
Кунган саен башын чукып.
Җылы җилләр алдадылар,
Аяк асты боз иде бит.
Иске тунны утка ягу
Яраларга тоз иде бит.
Бар идек без, бай идек без,
Тик бер генә бездә хурлык –
Телен, динен, илен саткан
Куштаннарга да бай булдык.
Берәгәйле каһарманнар
Шәһит китте берәм-берәм.
Татар башын татар чукый
Җаһил куштаннары белән.
Бурычларны түләүче юк,
Күргәнем юк сораучысын.
Түләп бетерерлек түгел
Күз яшьләрен, тир ачысын.
Авыл һаман билен бөгеп,
Баш күтәрми... Бу нинди эш?
Күзләрендә үпкә-үч юк,
Әйтерсең лә шулай тиеш.
И, авылым, моңлы иттең,
Күңелемә шом салдың да,
Гаебем бар кебек хәзер
Череп тузган йорт алдында.
Әнә чыгып килә аннан
Ялгыз карчык, бик бетәшкән,

Куырылган, суырылган,
Әби булган илле яшьтә.

Ике куллап күрешә дә
Күзләремә карый туры,
Әйтерсең лә күзләрендә
Авылымның соңгы нуры.

Эх, дөньясы! Кузгатырмы
Кемдер бу җинаять эшен,
Үз бәясен үзе белми
Узган гомерләре өчен?
Аерылганны аю ашый,
Шаһитлар, сез ник дәшмисез?
Гарасатта читкә качып,
Нигә бүген берләшмисез?
Тыныч түгел, әрни күңел,
Нидер эзли, нидер көтә.
Җинаятьче табылмаган,
Тикшеренү дәвам итә...

*1992*

Эчтәлек

Беренче бүлек. Азатлык көне
Азатлык көне
Азатлык көле
Азатлык теле

Икенче бүлек. Мәңгелек яра
Зәйтүнә мәхәббәте
Меңнән бер өлеш
Бердәнбер өлеш

Өченче бүлек. Юл башы
Чокырча тавы
Алмагачлар сагышы
Ут
Бакча
Фатыйма мәхәббәте
Йорт иясе
Җинаять эше

Литературно-художественное издание

**Раниф** Шарипов

(Шарипов Раниф)

**День свободы**

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Ђдђби-нђфис басма

Рәниф Шәрипов

**Азатлык көне**

Мљхђррире *Р. Ә. Заһидуллина*

Рђссамы

Бизђлеш мљхђррире *Р. Х. Хђсђншин*

Техник мљхђррире џђм компьютерда биткђ салучысы

Корректоры